# ШУРА

№ 51
2026



# ШУРА

№ 51
2026



# ЭЧТӘЛЕК


Җомга хотбәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4

Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . 9

ВӘГАЗЬЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

Рамазан аена әзерләнәбезме? . . . . . . . . . . . . 14

Мигъраҗ кичәсе һәм аның фазыйләтләре . . . . . . . . 19

Дин һәм мәдәният . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24

Бәраәт кичәсенең фазыйләтләре . . . . . . . . . . . 29

Малыбызда бәрәкәт булсын дисәк… . . . . . . . . . . 34

Рамазанда рухи көч туплап, аны ел буена саклыйк . . . . . . . 40

Хуш килдең, Рамазан! . . . . . . . . . . . . . . . . 45

Рамазан – Коръән иңгән ай . . . . . . . . . . . . . 51

Кадер кичәсенең фазыйләтләре . . . . . . . . . . . . 57

Дин – лотерея түгел . . . . . . . . . . . . . . . . . 64

Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы . . . . . . . . 69

Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе . . . . 71

Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе . . . . . . . . 73

Ураза гаете вәгазе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75

Пәйгамбәребезнең 10 сөннәте . . . . . . . . . . . . . 80

Тәкъва булуның вакыты кайчан? . . . . . . . . . . . . 88

«Күрше хакы – Аллаһы хакы» . . . . . . . . . . . . . 96

НӘРСӘ? КАЙДА? КАЙЧАН? . . . . . . . . . . . . . . . 111

СЕНТЯБРЬ–НОЯБРЬ . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102

**«ШУРА» дини альманах, № 51** **12+**

гыйнвар–март 2026
раҗәб–шәүвәл 1447

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:**

Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
420021, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38 нче йорт

Бушлай таратыла.
2013 елның июленнән чыга.
Басма кварталга бер тапкыр чыга.

**БАШ РЕДАКТОР:**
Хамматов Л. Г.

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Хәмидуллин Р. Ә.
Мөбарәков Б. Р.
Фәизов И. Ә.

**ҖАВАПЛЫ СӘРКАТИП**
Телефон: +7 (843) 598-09-42

**МӨХӘРРИР:**
Маннанова Р. Р.

**ДИЗАЙНЕР:**
Хәйретдинов И. Р.

**БИТКӘ САЛУЧЫ:**
Гарифуллин И. Ф.

**ТЫШЛЫКТАГЫ РӘСЕМ:**
shutterstock.com/ru/g/azat1976

Альманах Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан республикасы буенча идарәсендә 2013 елның 17 нче июлендә ПИ № ТУ16-01077 номеры белән теркәлде.

**РЕДАКЦИЯ**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:
«Хозур» – «Тынычлык» нәшрият йорты» шәхси оешмасы
420111, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27 нче йорт
Тел.: +7 (843) 598-09-42
Электрон почта: izdat@huzur.ru
Сайт: huzur.ru

*Типографиянең адресы:*
*«Карти» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте типографиясендә бирелгән электрон-макетның тулы сыйфатына тәңгәлләштереп бастырылды.*
*Адрес: 420095, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Химград территориясы, 201 нче йорт, 1006 нчы бина.*

Тираж – 2000 данә
Басарга кул куелды: 09.12.2025
Чыгу көне: 25.12.2025

*Редакциягә килгән язмалар кире кайтарылмый.*

*Журналда тәрҗемә итеп бастырылган материалларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.*

*Журнал битләрендә Коръәни Кәримдәге аятьсүрәләр урын алганлыктан, басмага игътибарлы булуыгыз сорала.*

**«СОВЕТ»**

Ежеквартальное печатное издание
на татарском языке

## Җомга хотбәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый.

اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ اَلْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِي هَدَانَا لِهَذَا وَمَا كُنَّا لِنَهْتَدِيَ لَوْ لَا أَنْ هَدَانَا اللّٰهُ. وَمَا تَوْفِيقِي وَاعْتِصَامِي إِلَّا بِاللّٰهِ❁ فَسُبْحَانَ الَّذِي قَالَ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ: وَمَا تَشَاؤُونَ إِلَّا أَنْ يَشَاءَ اللّٰهُ❁ نَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللّٰهُ وَحْدَهُ لَا شَرِيكَ لَهُ❁ شَهَادَةً مُنْجِيَةً مِنْ عَذَابِ اللّٰهِ❁ وَنَشْهَدُ أَنَّ سَيِّدَنَا مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ❁ دَاعِينَا إِلَى اللّٰهِ❁ صَلَّى اللّٰهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى أَوْلَادِهِ وَأَزْوَاجِهِ وَعَلَى خُلَفَائِهِ الرَّاشِدِينَ الْمُرْشِدِينَ الْمَهْدِيِّينَ مِنْ بَعْدِهِ❁ وَوُزَرَائِهِ الْكَامِلِينَ فِي عَهْدِهِ❁ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى الْأَئِمَّةِ بِالْحَقِّ أُمَرَاءِ الْمُؤْمِنِينَ أَبِي بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَعُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ❁ وَعَلَى بَقِيَّةِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ❁ رِضْوَانُ اللّٰهِ تَعَالَى عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ❁ أَمَّا بَعْدُ فَيَا عِبَادَ اللّٰهِ! ❁ اِتَّقُوا اللّٰهَ وَ أَطِيعُوهُ❁ إِنَّ اللّٰهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوْا وَالَّذِينَ هُمْ مُحْسِنُونَ❁

Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:

قَالَ اللّٰهُ عَزَّ وَ جَلَّ فِي كِتَابِهِ الْكَرِيمِ أَسْتَعِيذُ بِاللّٰهِ:

❁ ______________________________

Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:

وَ قَالَ النَّبِيُّ صَلَّي اللّٰهُ عَلَيْهِ وَ سَلَّمْ:

❁ ______________________________

Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:

أَلَا إِنَّ أَحْسَنَ الْكَلَامِ وَأَبْلَغَ النِّظَامِ۞ كَلَامُ اللهِ الْمَلِكِ الْعَزِيزِ الْعَلَّامِ كَمَا قَالَ اللهُ تَبَارَكَ وَ تَعَالَى فِي الْكَلَامِ: وَإِذَا قُرِئَ الْقُرْآنُ فَاسْتَمِعُوا لَهُ وَ أَنْصِتُوا لَعَلَّكُمْ تُرْحَمُونَ۞ أَسْتَعِيذُ بِاللهِ: إِنَّ الدِّينَ عِنْدَ اللهِ الْإِسلَامُ۞

Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.

Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.

بَارَكَ اللهُ لَنَا وَ لَكُمْ۞ وَ لِسَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَ الْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَ الْمُسْلِمَاتِ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَ الْأَمْوَاتِ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ۞

Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:

اَلْحَمْدُ لِلّٰه حَمْدَ الْكَامِلِيْنَ وَالصَّلٰوةُ وَ السَّلَامُ عَلَى سَيِّدِ الْأَوَّلِيْنَ وَ الْآخِرِينَ۞ مُحَمَّدٍ وَآلِهِ وَ صَحْبِهِ أَجْمَعِينَ۞ تَعْظِيماً لِنَبِيِّهِ وَتَكْرِيماً لِفَخَامَةِ شَانِ شَرَفِ صَفِيِّهِ۞ فَقَالَ عَزَّ وَجَلَّ مِنْ قَائِلٍ مُخْبِراً وَآمِراً:

إِنَّ اللهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيماً۞ اَللَّهُمَّ صَلِّ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا صَلَّيْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞ اَللَّهُمَّ بَارِكْ عَلَى مُحَمَّدٍ، وَعَلَى آلِ مُحَمَّدٍ۞ كَمَا بَارَكْتَ عَلَى إِبْراهِيمَ وَعَلَى آلِ إِبْراهِيمَ۞ إِنَّكَ حَمِيدٌ مَجِيدٌ۞

اَللَّهُمَّ وَارْضَ عَنِ الْخُلَفَاءِ الْأَرْبَعَةِ ذَوِى الْقَدْرِ الْجَلِيِّ وَالشَّرَفِ الْعَلِيِّ ۞ سَيِّدِنَا أَبِى بَكْرٍ وَ عُمَرَ وَ عُثْمَانَ وَ عَلِيٍّ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُمْ ۞ وَعَنِ السِّتَّةِ الْبَاقِيَةِ مِنَ الْعَشَرَةِ الْمُبَشَّرَةِ ۞ وَعَنِ الْعَمَّيْنِ الْمُكَرَّمَيْنِ عِنْدَ اللّٰهِ اَلْمُحْتَرَمَيْنِ عِنْدَ النَّاسِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَمْزَةَ وَالْعَبَّاسِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَ عَنِ السِّبْطَيْنِ الْجَلِيلَيْنِ السَّعِيدَيْنِ الشَّهِيدَيْنِ ۞ سَيِّدِنَا الْحَسَنِ وَ سَيِّدِنَا الْحُسَيْنِ رَضِيَ اللّٰهُ عَنْهُما ۞ وَعَنْ سَائِرِ الصَّحَابَةِ وَالتَّابِعِينَ لَهُمْ بِإِحْسَانٍ إِلَى يَوْمِ الدِّينِ رِضْوَانُ اللّٰهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ عَنْ سَائِرِ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ ۞ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ ۞ إِنَّكَ سَمِيعٌ قَرِيبٌ مُجِيبُ الدَّعَوَاتِ ۞ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ، اَللَّهُمَّ انْصُرْ مَنْ نَصَرَ الدِّينَ[1] ۞ وَاخْذُلْ مَنْ خَذَلَ الْمُسْلِمِينَ ۞ وَاكْتُبِ الصِّحَّةَ وَالسَّلَامَةَ عَلَيْنَا وَعَلَى الْحُجَّاجِ وَالْغُزَاةِ وَالْمُسَافِرِينَ وَالْمُقِيمِينَ وَالْحَاضِرِينَ وَالْغَائِبِينَ ۞ فِي بَرِّكَ وَبَحْرِكَ وهَوَائِكَ مِنْ أُمَّةِ مُحَمَّدٍ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞ وَ سَلَامٌ عَلَى الْمُرْسَلِينَ وَالْحَمْدُ لِلّٰهِ رَبِّ الْعَالَمِينَ ۞

Иң соңыннан «Әгууҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:

إِنَّ اللّٰهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَ إِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَى وَيَنْهَى عَنِ الْفَحْشَاءِ وَ الْمُنْكَرِ وَالْبَغْيِ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ۞ وَلَذِكْرُ اللّٰهِ أَكْبَرُ وَاللّٰهِ يَعْلَمُ مَا تَصْنَعُونَ ۞

**Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:**

---

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

Әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһи, әлхәмдүлилләәһил-ләзии һәдәәнә лиһәәзәә вә мәә күннәә линәһтәдийә ләү ләә ән һәдәәнәллаһ. Вә мәә тәүфиикый вәгътисаамий илләә билләәһ. Фә сүбхәәнәл-ләзии каалә фии китәәбиһил-кәриими әстәгыйзү билләәһи: «Вә мәә тәшәә-үүнә илләә ән йәшәә-әллаһ». Нәшһәдү ән ләә иләәһә илләллаһу. Вәхдәһү ләә шәриикә ләһү. Шәһәәдәтән мүнҗийәтән мин газәбилләһи. Вә нәшһәдү әннә сәййидәнә Мүхәммәдән габдүһү вә расүүлүһү. Дәәгыыйнәә иләл-лаһи. Салләллаһу тәгаалә галәйһи вә галәә әүләәдиһи вә әзвәәҗиһи вә галәә хуләфәә-иһир-раашидиинәл мүршидиинәл мәһдиййинә мин бәгъдиһи. Вә үзәраа-иһил кәәмилиинә фии гаһдиһи. Хусуусан минһүм галәәл ә-иммәти бил-хәккый үмәраа-ил мүъминиинә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусмәәнә вә Галиййин. Вә галәә бәкыййәтис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәнин иләә йәүмид-дини. Ридъвәәнуллаһи тәгаалә галәйһим әҗмәгыйнә.

Әмма бәгъде: фә йәә гыйбәдәллаһ! Иттәкуллаһә вә әтыыйгууһу. Иннәллаһә мәгал-ләзиинәт-тәкау, вәл-ләзиинә һүм мухсинүүн.

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Каалә-ллаһу газзә вә җәллә фии китәәбиһил кәриими әстәгыйзү билләһи: ________________________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Вә каалән нәбиййү салләллаһу галәйһи вә сәлләм: ________________

**Вәгазьнең темасына багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәгеләрне укый:**

Әләә иннә әхсәнәл кәләәми вә әбләган низаами. Кәләәмүллаһил мәликил газиизил галләәми, кәмәә каалаллаһу тәбәәракә вә тәгаалә фил-кәләәми. Вә изәә куриәл-куръәәну фәстәмигуу ләһү вә әнсыйтү ләгалләкүм түрхәмүүнә. Әстәгыыйзү билләһи: «Иннәд-диинә гыйндәллаһил Исләәм».

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта Ахирәт өчен һәртөрле дога кылына ала.**

Бәәракәллаһу ләнәә вә ләкүм. Вә лисәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиинә. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә, вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмин.

**Соңыннан, басып, икенче хотбә буларак, киләсе сүзләрне укый:**

Әлхәмдүлилләәһи, хәмдәл кәәмилиинә вәссаләәтү вәссәләәмү галәә сәййидил әүвәлиинә вәл әхыйринә Мүхәммәдин вә әәлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Тәгъзыймән линәбиййиһи вә тәкриимән лифәхаамәти шәәни шәрафи сафиййиһи. Фәкаалә газзә вә җәллә мин каа-илин мүхбиран вә әәмиран:

«Иннәллаһә вә мәләә-икәтәһү йүсаллүнә галән нәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллүү галәйһи вә сәллимүү тәслиимән». Аллаһуммә салли галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә салләйтә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид. Аллаһуммә бәәрик галәә Мүхәммәдин, вә галәә әәли Мүхәммәд. Кәмәә бәәрактә галәә Ибрааһиимә вә галәә әәли Ибрааһиимә, иннәкә хәмиидүн мәҗиид.

Аллаһуммә вәрда ганил хуләфәә-ил әрбәгати ẓәвил кадрил җәлиййи вәш-шәрафил галиййи сәййидинәә Әби Бәкрин вә Гумәра вә Гусм̣әәнә вә Галиййин радыяллаһу ганһүм. Вә ганис-ситтәтил бәәкыйәти минәл гашәратил мүбәшшәрати. Вә ганил гаммәйнил мүкәррамәйни гыйндәллаһи әл-мүхтәрамәйни гыйндән-нәәси сәййидинәл Хәмзәтә вәл Габбәәси радыяллаһу ганһүмәә. Вә ганис сибтайнил җәлииләйнис сәгыйдәйни әш-шәһиидәйни сәййидинәл Хәсәни вә сәййидинәл Хүсәйни радыяллаһу ганһүмәә. Вә ган сәә-ирис сахәәбәти вәт-тәәбигыйнә ләһүм би-ихсәәни иләә йәүмид-диин. Ридъвәәнуллаһи галәйһим әҗмәгыйн. Вә ган сәә-ирил мү’миниинә вәл мү’минәәти, вәл мүслимиинә вәл мүслимәәти. Әл-әхьйәә-и минһүм вәл

әмвәәти. Иннәкә сәмиигун кариибүн мүҗиибүд дәгавәәти. Бирахмәтикә йәә әрхәмәр раахимин.

Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин. Аллаһуммән-сур мән нәсарад-диин[1]. Вәхӟүл мән хәӟәләл мүслимиин. Вәктүбис-сыйххәтә вәс-сәләәмәтә галәйнәә вә галәәл хүҗҗәәҗи вәл гузәәти вәл мүсәәфириинә вәл мүкыыймиинә вәл хәәдыйриинә вәл гаа-ибиинә. Фии бәррикә вә бәхрикә вә һәвәә-икә мин үммәти Мүхәммәдин галәйһим әҗмәгыйн. Вә сәләәмүн галәәл мүрсәлиинә. Вәлхәмдүлилләәһи Раббил гааләмиин.

**Иң соңыннан «Әгууӟү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

«Иннәллаһә йә’мүру бил гадли вәл ихсәәни вә иитәә-и ӟил курбәә вә йәнһәә ганил фәхшәә-и вәл мүнкәри вәл бәгъ-ии, йәгыйзукүм ләгалләкүм тәӟәккәрүүн. Вәләӟикруллаһи әкбәр, вәллааһи йәгъләмү мәә тәсънәгуун».

## Җомга хотбәсенең тәрҗемәсе

Имам-хатыйб азанга кадәр җәмәгатькә йөзе белән карап утыра. Азан тәмамлангач, мөнбәргә басып, тавыш белән түбәндәге доганы укый:

Безне туры юлга күндергән Аллаһыга мактау булсын.[2] Аннан башка безне берәү дә (туры юлга) күндерә алмый.

Коръәни Кәримдә: **«Әмма Аллаһы теләми торып, сез тели алмассыз. Һичшиксез, Аллаһы – Белүче, Хикмәт иясе»**, – дип әйтүче Аллаһы – барлык кимчелекләрдән дә Пакь.

Без бердәнбер булган Аллаһыдан башка илаһның юклыгына һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның Расүле һәм колы булуына шаһитлык итәбез. Без Пәйгамбәребез, аның балалары, хатыннары,

[1] Бу вакытта җәмәгать күңелдән «Әмин» дип әйтә.

[2] Өч тапкыр әйтелә.

элек яшәп киткән изгеләребез һәм һидаять юлында булган һәркем өчен, Аллаһының рәхмәтен сорыйбыз.

Һәм аның турыдан-туры хәлифәләре – мөэминнәрнең хакимнәренә: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәдән Аллаһы риза булсын. Кыямәт көнендә барлык пәйгамбәрләргә һәм табигыйннәргә Аллаһының ризалыгы һәм рәхмәте булсын.

Моннан соң Аллаһыга гыйбадәт кылучылар Аңа итагать итсен.

**«Һичшиксез, Аллаһы –** [гөнаһлардан] **курыккан һәм** [Раббыларының ризалыгын гына өмет итеп] **игелекле гамәлләр кылган кешеләр белән».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:128

**Вәгазь өлеше. Имам вәгазьгә караган төп аятьне укый:**

Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: ______________________

**Имам вәгазьгә караган төп хәдисне укый:**

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән:

______________________________________________________________

**Вәгазьнең эчтәлегенә багышланган аять һәм хәдисләр укылганнан соң, тавыш белән түбәндәге сүзләрне укый:**

Дөреслектә, иң дөрес һәм төзек сөйләм – ул Аллаһының Сөйләме. Коръәндә Аллаһы Тәгалә әйтүенчә:

**«Коръән укылган чакта, аны тыңлагыз һәм дәшми торыгыз, – бәлки, сез** [Аллаһы тарафыннан] **рәхмәт ителерсез»;**

«Әл-Әгъраф / Киртәләр», 7:204

**«Һичшиксез, Аллаһы хозурында** [хакыйкый һәм кабул ителгән] **дин – Ислам** [дине генә]**».**

«Әлү Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:19

**Соңыннан, кулларын дога өчен күтәреп, эчтән генә түбәндәге доганы кыла. Әлеге дога – утырышта укыла торган дога.**

**Гомумән, утырган вакытта һәртөрле дога кылына ала.**

Без Аллаһыдан барыбыз өчен дә рәхмәтен иңдерүен сорыйбыз. Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәм ике дөньяда да булачак. Син – Ишетүче, Якын һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы. Пәйгамбәрләргә сәламнәр һәм Аллаһының рәхмәте булсын. Галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһыга мактаулар булсын.

**Соңыннан басып, икенче хотбә буларак, түбәндәгеләрне укый:**

Аллаһыга мактаулар, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, сәхабәләренә һәм аңа иярүчеләргә сәламнәребез һәм Аллаһының рәхмәте булсын.

Аллаһы Тәгалә Изге Китабыбызда әйткәнчә:

> **«Һичшиксез, Аллаһы һәм фәрештәләре Нәби салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салават әйтәләр. Ий иман китерүчеләр! Сез аңа салават әйтегез һәм** [«Ий, Нәби, сиңа сәлам булсын», – дип] **сәламләү белән сәлам бирегез».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:56

Йә, Аллаһы, тугры хәлифәләр: Әбү Бәкер, Гомәр бине Хаттаб, Госман бине Гаффан, Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһүмәгә һәм җәннәт белән шатландырылган алты сәхабәгә, Расүлебезнең югары дәрәҗәдә булган абыйлары – Хәмзә бине Габделмотталиб һәм Габбас бине Габделмотталибка, шәһит булып киткән сөекле оныклары Хәсән белән Хөсәенгә рәхмәтеңне иңдер. Сәхабәләр һәм табигыйннәр өчен Кыямәт көнендә Аллаһының рәхмәтен, ризалыгын ирештер.

Мөэмин-мөселманнар өчен ярдәмең ике дөньяда да булачак. Дөреслектә, Син – догаларыбызны Ишетүче һәм догаларыбызга җавап бирәсең. Синең рәхмәтең белән, йә, Рәхимле һәм Шәфкатьле Аллаһы!

Йә, Аллаһы, динебез Исламга ярдәм итүчеләргә Син дә ярдәм ит (өч тапкыр әйтелә). Мөэминнәрне җәберләүчеләрне көчсезләндер. Безгә, галимнәргә, юлчыларга, исәннәргә һәм үлеләргә – пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең өммәтенә тынычлык һәм тәртип билгелә.

**Иң соңыннан, «Әгуүҙү» һәм «Бисмилләһ»не эченнән генә әйтеп, түбәндәге аятьне тавыш белән укый һәм хотбә тәмам була:**

**«Һичшиксез, Аллаһы** [һәрнәрсәне аңлатыр өчен, иңдергән китабында] **гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәберзолым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Аллаһыны зикер итегез. Хакыйкатьтә, Ул сезнең ни кылганнарыгызны белә.

# Вәгазьләр

*9 гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 20 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Рамазан аена әзерләнәбезме?

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне барлыкка китерүче Раббыбыз Аллаһы Тәгаләгә барча мактаулар, хәмед-сәналәр булсын! Дөньяларга рәхмәт итеп иңдерелгән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә салаватларыбыз, сәламнәребез ирешсен! Барча мөселманнарга Аллаһы Раббыбызның сәламе, рәхмәте вә бәрәкәте насыйп булсын!

Раббыбыз Аллаһы һәрберебезне бу дөньяга бик зур максат белән китерде. Бу – гыйбадәт кылу:

وَمَا خَلَقْتُ الْجِنَّ وَالْإِنسَ إِلَّا لِيَعْبُدُونِ ﴿٥٦﴾

> **«Мин җеннәрне һәм кешеләрне Миңа гыйбадәт кылсыннар дип яраттым».**

«Әз-Зарият / Таратучылар», 51:56

Нәкъ менә шушы юл аркылы кеше рухи көчен арттыра, күңелен пакьли, шуңа күрә үзен бәхетле итеп сизә башлый. Андый кеше Аллаһы каршында төп бурычын үтәгән булып исәпләнә.

Аллаһы Тәгалә төп гыйбадәтләрне кабатланучан итеп билгеләгән. Вакыт-вакыт аларны яңарту, кабатлау кешене һәм рухи, һәм матди яктан көчәйтеп җибәрә. Мәсәлән, биш вакыт намаз көн буена мөселманны бөтен яктан камилләштереп торырга тиешле гамәл:

إِنَّ الصَّلَاةَ تَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ ۗ

> **«... чөнки намаз** [зина кебек] **әшәкелекләрдән дә,** [шәригатьтә дә, акыл белән дә] **гаеп саналганнардан да саклый».**

«Әл-Ганкәбут / Үрмәкүч», 29:45

Рамазан ае уразасы да ел буена, гомер буена җыелган гөнаһларны пакьләргә, тәкъвалыкны арттырырга юнәлтелгәндер:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

> **«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә** [фарыз булып] **язылган кебек, сезгә дә** [Рамазан аендагы] **ураза** [фарыз булarak] **язылды. Бәлки,** [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] **тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Гыйбадәт көчле, дөрес, ихлас булсын өчен, аңа алдан әзерләнергә кирәк. Бигрәк тә Рамазан ае уразасына. Барыбызга да билгеле: Рамазан башлану белән генә уразага ябышабыз да, уразаның беренче көннәре авырлык белән, аңлашылмыйча китеп тә бара. Кыйммәте югала. Тәнебез генә түгел, хәтта җаныбыз да авырсынып калырга мөмкин. Шундый хаталарга юлыкмас өчен, кайбер бик әһәмиятле мәсьәләләргә игътибар итәргә кирәк.

Һәр гамәлнең кыйммәте күңел багланышыннан, нияттән гыйбарәт. Уразага әзерлек иң беренче чиратта рухи тәрбиядән башлана. Үзеңне дә, якыннарыңны да, бигрәк тә гаилә әһелләреңне, алдан ук ихлас булырга, җанны чистартырга өндәргә кирәк. Моның өчен шундый гамәлләр кылырга була:

- **Күп итеп тәүбә кылу, гел истигъфар сүзләрен әйтеп йөрү.** Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, һич гөнаһсыз булуына карамастан, көненә 70–100 тапкыр «әстәгъфируллаһ» дип әйтә торган булган. Хәсән әл-Басри

рахимәһуллаһи әйтә торган булган: «Өйләрегездә булганда да, ашаганда да, базарда йөрсәгез дә, җыелышларда да – кайда гына булсагыз да, гел истигъфар әйтеп йөрегез! Аллаһының мәгъфирәте кайчан иңгәнен беребез дә белми».

• **Еш дога кылу:** «Аллаһым, безне Рамазанга ирештер, сәламәтлек бир һәм уразаны ихласлык белән үтәргә ярдәм ит!» Хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе әйтүенчә, раҗәб ае керсә, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм еш болай дип әйтә торган булган:

اَللّٰهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِيْ رَجَبٍ وَشَعْبَانَ وَبَلِّغْنَا رَمَضَانْ

«Аллаһым! Раҗәб һәм шәгъбан айларын безгә бәрәкәтле кыл, Рамазанга ирешергә насыйп ит!»

Сәхабәләр ярты ел буена «уразам кабул булсын иде» дип дога кылганнар, ә елның икенче яртысында «киләсе Рамазанга ирештерче» дип тели торган булганнар.

• **Коръән укуга басым ясау.** Рамазан ае – Коръән иңгән ай. Аның һәр мизгелен Коръән белән үткәрү тиешле. Галимнәр әйтүенчә, Рамазанда эшләнерлек иң изге гамәлләрнең берсе – ул Коръән уку, аны тыңлау вә өйрәнү. Тормышның бәрәкәте дә, бәхете дә Коръәндә. Имам Мәлик, Суфьян әс-Сәүри һәм башка мәшһүр галимнәр, барлык дәресләрен калдырып, Рамазан аенда Коръән укыганнар һәм укытканнар. Шактый күп мөселманнар, еллар буе намазда булып, уразалар тотсалар да, Аллаһының Сүзен, хәрефләрен танып укый белмиләр. Нибары 28 хәрефне тоташтырып укырга өйрәнү өчен бер ай вакыт җитә. Бигрәк тә хәзерге заманда. Хәзер бит нинди генә ысуллар, дәресләр, мөмкинлекләр юк…

• **Җәмәгать намазларына игътибарны арттыру.** Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһедән китерелә: «Җәмәгать белән укылган намаз берүзең укуга караганда 25 тапкыр саваплырактыр…»

Рамазан аенда, әлхәмдүлилләһ, мәчетләр тәравих намазына тула. Әмма фарыз намазларына йөрү күпкә саваплырак. Бигрәк тә Рамазанда. Бу гамәлгә

алданрак күнегү изге айда шактый җиңеллек бирә. Аеруча иртәнге һәм ястү намазлары игътибарга лаеклы. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Кем ястү намазын мәчеттә укыса, ярты төн намаз укыган шикелле булыр. Кем иртәнге намазны мәчеттә укыса, төне буе намаз укыган савапка ирешер».

• **Әзерлек дәресләре**. Рамазанның фазыйләте турында укыгыз, үрнәк вәгазьләр тыңлагыз.

*Икенчедән, безгә тәнебезне дә әзерләргә кирәк:*

• **Сәламәтлекне тикшерү**. Мәсәлән, авырулары булган кешегә озын көн буе ач тору ярыймы – сорауларыгыз булса, табибка күренегез.

• **Ризыкларны әзерләп кую**. Сәхәр вә ифтар өчен файдалы ашамлыкларны алдан планлаштырыгыз. Кирәк булачак ризыкларны алдан алып куярга мөмкин. Бигрәк тә хөрмәләрне. Затлырагын табып, кайтартып куйсагыз, тагын да яхшырак. Андый җимешләр Рамазан ифтарларын нык бизи!

• **Йокы режимы**. Иртәрәк йокларга ятарга һәм сәхәргә торырга күнегегез. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шәгъбан аенда ук ураза тота башлаган. Тулы ай тотмаса да, шактый өлешен уразада үткәргән.

*Өченчедән, көнкүрешебезгә караган мондый әзерлек эшләрен кайгыртырга мөмкин:*

• **Акча мәсьәләсендә** – зәкят, садака, ифтар өчен кирәк булачак акчаларны билгеләгез. Әлеге төр изгелекләр – Рамазанның иң күркәм гыйбадәтләреннән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бик юмарт булган диләр. Рамазан ае җитсә, аның юмартлыгы тагын да арта торган булган. Ә изге айның ахыргы 10 көнендә ул чиксез юмартлык күрсәтә торган булган. Сәхабәләр шулай тасвирлый.

• **Вакыт белән идарә итү**. Намаз, Коръән, гаилә вакытларын көн тәртибенә кертегез. Рамазан аена көндәлек планнар билгеләп кую хәерле. Кемнәрне ифтарга чакырасың, кайсы көнне буш, үзең бара аласың, кайчан син гел мәчеттә генә, туганнарны нинди көнне шатландырырга… Алдан ук язып куелганда, Рамазан ае бәрәкәтлерәк булыр.

• **Гаилә әзерлеге**. Гаиләгезне дә айның әһәмияте белән таныштырыгыз. Махсус дәресләр оештырырга, вәгазь кичәләрендә катнаштырырга кирәк.

Һәркем Рамазан аенда гыйбадәтләрен арттыру, камилләштерү өчен үзенә максатлар куйса, бик күркәм булыр. Мәсәлән:

– Коръәнне бер тапкыр укып чыгарга (хатем кылу);

– тәравих намазын көн дә җәмәгать белән үтәргә;

– гөнаһ кылудан тулысынча туктарга, мәсәлән, моңарчы бетерә алмаган берәрсенә бу Рамазанда нокта куярга (тәмәке, гайбәт сөйләү, риба малы);

– көн саен садака бирергә. Бик әз күләмдә булса да. Рамазанда һәр изгелекнең савабы күпкә арта. Бигрәк тә садака даими булса. Чөнки хәдистә әйтелә: «Аллаһы Тәгалә каршында иң сөекле гамәлләр даими кылына торганнары, гәрчә бик кечкенә булсалар да».

Рамазан – рухи яңарыш ае. Аны бары тик ач тору дип санамыйк, ә күңелебезне пакьләргә, мөселманнарга ярдәм итәргә, Аллаһыга якынаерга мөмкинлек дип карыйк.

Аллаһым, безне изге Рамазан аена ирештер, аны гөнаһларыбызны гафу итү сәбәбе ит һәм безне җәннәтеңә якын кыл! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Булат хәзрәт Раупов,*

*Лениногорск районының имам-мөхтәсибе*

*16 гыйнвар вәгазе,*

*раҗәб аеның 27 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Мигъраҗ кичәсе һәм аның фазыйләтләре

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Раҗәб ае бер мөбарәк кичә белән бизәлгән. Ул – Мигъраҗ кичәсе, раҗәб аеның 26 нчы көненнән 27 сенә каршы кичтә була. Мигъраҗ «күккә ашу» дигән мәгънәне аңлата, һәм бу кичә сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышында олы могҗиза булып санала.

Раҗәб аеның 27 нче төнендә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһының кодрәте белән гадәти булмаган бер сәфәр кыла. Бу хакта Аллаһы Раббыбыз «әл-Исра» сүрәсенең 1 нче аятендә болай дип әйтә:

سُبْحَانَ الَّذِي أَسْرَىٰ بِعَبْدِهِ لَيْلًا مِّنَ الْمَسْجِدِ الْحَرَامِ إِلَى الْمَسْجِدِ الْأَقْصَى الَّذِي بَارَكْنَا حَوْلَهُ لِنُرِيَهُ مِنْ آيَاتِنَا ۚ إِنَّهُ هُوَ السَّمِيعُ الْبَصِيرُ ﴿١﴾

> **«Аятьләребездән кайберләрен күрсәтик дип, бер төнне колын Харам мәчетеннән** [алып] **Без тирә-ягын бәрәкәтле иткән әл-Әкъса мәчетенә күчерүче** [булган Аллаһы] **кимчелекләрдән пакь. Һичшиксез, Ул –** [һәрнәрсәне] **Ишетүче, Күрүче».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:1

Риваятьләр буенча, Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәккәи-Мөкәррәмә шәһәрендәге әл-Харам мәчете («Изге мәчет» дигән сүз), ягъни Кәгъбәтуллаһ, янында йоклап ятканда, Җәбраил фәрештә Борак дип аталган хайванны (мәгънәсе – «яшен тизлегендә оча торган») алып килә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Борак белән яшен тизлегендә әл-Харам мәчетеннән әл-Кудс (Иерусалим) шәһәрендәге әл-Әкъса мәчетенә (Ерак мәчеткә) күчә. Шунда Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм башка пәйгамбәрләргә имам булып намаз укый. Шулай итеп Аллаһы Тәгалә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка пәйгамбәрләрдән өстен булуын күрсәтә. Соңрак Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә ике савыт китереп куялар: аларның беренчесендә – сөт, икенчесендә шәраб (хәмер) була. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөт салынган савытны сайлый. Җәбраил фәрештә Пәйгамбәребез галәйһиссәламнең сөт сайлавын күргәч: «Сине пәйгамбәр итеп җибәргән Аллаһыга мактау булсын. Әгәр син хәмер салынган савытны сайлаган булсаң, өммәтең саташыр иде», – дип әйтә[1]. Сөтнең ак төстә булуы хакыйкать, дөреслек, иминлек билгесе булып тора.

Аннары Аллаһы Тәгаләнең әмере килә: Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Җәбраил фәрештә белән күккә күтәрелә. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм, җиде кат күк аша үткәндә, күкнең һәр катында үзенә кадәр җир йөзенә килеп киткән пәйгамбәрләр – Адәм, Яхъя, Гайсә, Йосыф, Идрис, Һарун, Муса һәм Ибраһим галәйһимуссәлам – белән очраша. Алар барысы да Пәйгамбәребезгә сәлам бирәләр[2].

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗ вакытында төрле вакыйгалар күрә. Мәсәлән, ул бер өммәткә күз сала. Ул кешеләрнең иреннәре дөянеке кебек була. Бер төркем хезмәтчеләр, аларның иреннәрен кисеп, авызларына таш салалар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм

[1] Имам Мөслим.

[2] Имам әл-Бохари.

Җәбраил галәйһиссәламнән: «Болар кемнәр?» – дип сорый. Ул: «Алар хаксыз рәвештә ятимнәрнең малларын исраф иттеләр», – дип җавап бирә[1].

Шуннан соң Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм икенче бер өммәтне күрә. Ул өммәтнең кешеләре үз йөзләрен һәм күкрәкләрен бакыр тырнаклар белән тырнаганнар. Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм янә Җәбраилдән: «Бу кешеләр кемнәр?» – дип сорый. Ул: «Алар гайбәт сөйләп, яла ягып кешеләрнең итләрен ашадылар», – дип әйтә[2].

Соңрак Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм мәетләрне һәм үләксәләрне ашаучы зиначыларны, күпергән эчле риба ашаучыларны, башлары белән аска таба асылынган үз балаларын үтерүчеләрне күрә[3]. Шуңа күрә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә: «Әгәр сез мин белгәнне белсәгез, аз көлеп, күп елар идегез», – дип әйткән[4].

Җәбраил фәрештә махсус бер чиккә («Сидрәт әл-мүнтәһә») кадәр генә бара ала. Шул урынга җиткәч, Җәбраил галәйһиссәлам: «Миңа куелган чик шушында бетте, алга таба барырга рөхсәт юк», – дип әйтә. Пәйгамбәребез изге сәфәрне үзе генә дәвам итә. Галимнәр әйтүенчә, Мигъраҗ кичәсендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм биш нәрсәдә сәфәр кылган. Башта ул Боракка утырган, аннары күккә баскычтан менгән. Ул баскыч нурдан булган, дигән фикер бар. Шуннан соң беренче күктән җиденче күккә кадәр фәрештәләрнең канатларында менгән. Җиденче күктән «Сидрәт әл-мүнтәһә» дигән чиккә кадәр Җәбраил фәрештәнең канатында сәфәр кылган. Ахырда Раф-раф дип аталган алтын келәм барлыкка килгән. Шушы Раф-рафта Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Аллаһыга якынайган.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мигъраҗ кичәсендә Аллаһы Тәгаләне күрү һәм Аның белән сөйләшү бәхетенә ирешкән. Аллаһы

[1] Имам әт-Табари.

[2] Имам Әбү Давыд.

[3] Имам әт-Табари.

[4] Имам әл-Бохари.

хозурына баргач, ул: «Әт-тәхиййәтү лилләәһи вәс-саләвәәтү вәт-таййибәәт», – дип сәламли, ягъни: «Тел һәм тән гыйбадәтләребезнең барысы да фәкать Аллаһы өчен генә», – ди. Аллаһы Тәгалә: «Әс-сәләәмү галәйкә әййүһән-нәбиййү вә рахмәтуллааһи вә бәракәәтүһ», – дип җавап бирә, ягъни: «Әй Пәйгамбәр, сиңа Раббыңның сәламе, рәхмәте һәм бәрәкәте булсын». Моңа каршы Пәйгамбәребез: «Әс-сәләәмү галәйнә вә галәә гыйбәәдил-ләәһис-салихиин», – ди, ягъни: «Сәлам безгә һәм Аллаһы Тәгаләнең һәрбер изге бәндәләренә дә булсын». Шуннан соң фәрештәләр: «Әшһәду әл-ләәә иләәһә илләллааһу вә әшһәду әннә Мүхәммәдән габдүһүү вә расүүлүһ», – дип шәһадәт кәлимәсен әйтә, ягъни: «Чын күңелдән шәһадәт китерәбез: бер Аллаһыдан башка һичбер илаһ юк, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – Аның колы һәм илчесе».

Хөрмәтле мөселманнар! Бу сүзләрне без барыбыз да намазда, ягъни кагъдәдә, «әт-Тәхият»кә утыргач әйтәбез. Без өч затның – Аллаһы Тәгаләнең, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һәм фәрештәләрнең – әйткән сүзләрен кабатлыйбыз, шуңа күрә хәдис-шәрифтә: «Намаз – мөэминнең мигъраҗы», – дип әйтелгән. Димәк, намазда без Аллаһы Тәгалә белән сөйләшәбез, Аңа мөрәҗәгать итәбез, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аңа якын булабыз. Шундый олы бәхеткә көн саен биш тапкыр ирешәбез.

Аллаһы Тәгалә шушы кичәдә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә өч бүләк тапшыра:

– биш вакыт намаз фарыз кылына;

– «әл-Бәкара» сүрәсенең ахыргы аятьләре бирелә (285–286 нчы аятьләр);

– ширек кылмаганнарның зур гөнаһлары гафу ителәчәк дигән хәбәр бирелә[1].

Бу мөбарәк төндә таң атканчы тәһәҗҗүд намазын укырга мөмкин. Һәр ике рәкәгатьтән соң сәлам бирелә. Намазны укыганнан соң, Аллаһы Тәгаләнең 99 исемен укып, дога кылырга киңәш ителә.

[1] Имам Мөслим.

Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә намазларыбызны вакытында, дөрес һәм ихлас күңелдән укып, бу дөньяда һәм ахирәттә бәхеткә ирешергә насыйп итсә иде. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*Казанның «Апанай» мәчете имам-хатыйбы*

*23 гыйнвар вәгазе,*

*шәгъбан аеның 4 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Дин һәм мәдәният

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Галәмнәрне юктан бар итеп, безнең тәнебезгә җан индерүче, безне һәрдаим ризыкландырып, Үзенең рәхмәтендә йөртүче Аллаһы Сөбеханәһү вә Тәгаләгә күңелебезнең түрләреннән чыккан хәмед-сәналәребез булса иде! Расүлләрнең ахыргысы һәм Аллаһы Тәгаләнең хак Хәбибенә – пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә – салават-шәрифләребез барып ирешсен.

Газиз дин кардәшләрем, әлеге ел безнең Татарстан өммәтебез өчен генә түгел, бар илебез өммәте өчен үзенчәлекле булып тора. Республикабыз Ислам дөньясы белән, шул исәптән «Россия – Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме юнәлеше буенча да көчле эш алып бара. Һәм бар дөнья буенча, дистәләгән мөселман дәүләтләре арасыннан 2026 елда нәкъ Казан шәһәре Ислам дөньясының мәдәни башкаласы булып сайланды.

Шул форсаттан бүгенге вәгазебезне тирән мәгънәле темага – дин һәм мәдәниятнең үзара бәйләнешенә багышларбыз. Дин һәм мәдәният – кешелек дөньясында иң зур рухи көчләр. Алар милләтнең рухи йөзен билгели, кешеләрнең холкына һәм тормыш рәвешенә йогынты ясый. Дин мәдәниятне рухи яктан баета.

Дин – ул безнең тормышыбызның нигезе. Ул халыкларның мәдәниятен юк итәргә түгел, аны чистартырга, камилләштерергә килгән. Аның аша адәм

баласы дөрес юлга баса, күңелен пакьли, әхлагын тәрбияли. Мәдәниятк ә исә халыкның теле, киеме, йоласы, әдәбе, сәнгате керә. Әлеге ике кыйммәт бер-берсеннән аерым булырга тиеш түгел.

Дин – агачның тамыры кебек, мәдәният – шул тамырдан үсеп чыккан җимеш. Тамыр нык булса, агач та, җимеш тә нык һәм сәламәт була.

Нинди генә динне алсак та, ул изге язмаларга, Аллаһының әмерләренә нигезләнә. Мәдәният исә халыкның тарихы, тормыш рәвеше, көндәлек гадәтләре аша формалаша.

Мәдәни кагыйдәләр дин кануннарына каршы килә башласа, каршылык туарга мөмкин. Кайбер мәдәниятләрдә бәйрәмнәрдә исерткеч эчемлекләр куллану гадәте бар, ә Исламда бу тыела. Заманча кием кайчак диндәге тыйнаклык таләпләренә туры килми. Кайбер җырларда, шигырьләрдә дә дингә каршы булган сүзләр очрый. Ләкин, үз тарихыбызга күз салсак, бу бездә бары динсезлек чорында гына килеп чыккан әйберләр. Безгә хәтта Габдулла хәзрәт Тукай (ул мәдрәсә бетергән, шуңа да хәзрәт дию дә хак булыр) турында бик күп нәрсәләр сөйли иделәр. «Укыдым мин мәдрәсәдә, аңламадым бернәрсә дә» дигән шигъри юлларын сөйләп көлмәгән кеше калмагандыр. Ә хәзер без, җәмәгать, «Туган тел» шигыренең генә түгел, аның бар иҗатының дин белән сугарылганын күрәбез.

Тормыш булгач, кеше үзе дә мәдәни мохите белән дини ышанулары арасында икеләнеп калган вакытлар була. Мисал өчен, дини гаиләдә үскән яшь кеше ирекл ерәк, заманча җәмгыятьтә үзен уңайсыз тоярга мөмкин. Җәмәгать әл-мөслимин, халыкларның мәдәнияте еллар узу белән үзгәрергә, заман рухына яраклашырга мөмкин булуын онытмыйк, ә динебез беркайчан да үзгәрмәс, аның кануннары беренче иңгән көнендәге кебек үк кала.

Без, татар халкы, Аллаһының рәхмәте белән, 1000 елдан артык мөселманбыз. Нинди генә мәдәният юнәлешен алмыйк, барысы да дин белән нигезләнгән. Сөекле Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, үзе дә гарәп булгач, гарәп мәдәниятен белә иде. Татарлар, үзбәкләр, таҗиклар һәм башка

милләт вәкилләре – һәркайсы үз мәдәниятен белергә, аны сакларга һәм рухи үсеш өчен кулланырга тиешләр.

Татар халкы тормышында дин белән милләт гел янәшә, бергә булган. Дин тыелган заманда да, яшьләргә яшерен рәвештә булса да никах укыганнар, бала тугач, гакыйка корбаны чалу, исем кушу кебек гамәлләр милләт буларак сакланырга ярдәм иткән дә инде.

Татар халкында шактый гореф-гадәтләребез динебездән алынган. Шуңа да, гореф-гадәтләребезне кайтарып, динне торгызып була. Әти-әниебезне хөрмәт итү, кечкенәләрне рәнҗетмәү, туган телебездә сөйләшү, никах, бәби туйлары, исем куштыру йолалары – барысы да кадерле гореф-гадәтләребез. Халкыбызның шундый йолаларын кабат популярлаштырырга кирәк. Дин, гореф-гадәт – тәрбия бирү алымы бит ул. Яшь буынга тәрбияне борынгыдан килгән гореф-гадәтләребез аша бирү дә яхшы булыр иде.

Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани дә бу хакта әйтеп калдыра: «Өч әйбер диндә юк, әмма динне саклый. Беренчесе – тел, икенчесе – милли кием, өченчесе – гореф-гадәт». Мәдәният, Аллаһының рәхмәте белән, динебезне сакларга ярдәм итә ала. Татарстаныбызда без моны күреп сөенәбез: соңгы елларда радио-телевидениеләрдә дини тапшырулар чыга башлады, артистларыбыз дини мөнәҗәтләр башкара башлады, үзебезнең милли бизәкләребез белән яулыклар, киемнәр дә барлыкка килә.

Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, кайсы гына халыкның гореф-гадәте, аларның мәдәнияте дингә, шәригатькә каршы килми икән, шуны тыймаска, дин кануннарын аңлатканда истә тотарга киңәш иткән. Ягъни, халыкта борынгыдан булган гореф-гадәтләрне, шәригатькә каршы килмәсә, сакларга, үтәргә рөхсәт ителә. Һәм бөек сәхабәләр, галимнәребез бу кагыйдәне истә тоткан.

Аллаһының рәхмәте белән, безнең мәдәниятебез киләчәктә дә динебезгә каршы булмас, алар бергәләшеп кешелекне рухи асылына кайтарырга, иманын ныгытырга булышырлар, дип ышанасы килә.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

يَا أَيُّهَا النَّاسُ إِنَّا خَلَقْنَاكُم مِّن ذَكَرٍ وَأُنثَىٰ وَجَعَلْنَاكُمْ شُعُوبًا وَقَبَائِلَ لِتَعَارَفُوا ۚ إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلِيمٌ خَبِيرٌ ﴿١٣﴾

**«Ий кешеләр! Һичшиксез, Без сезне** [Адәм исемле] **бер ирдән һәм** [Хавва исемле] **бер хатыннан яраттык. Без сезне танышуыгыз өчен кавемнәр һәм кабиләләр иттек. Аллаһы хозурында иң кадерлегез – бик тә тәкъвалык иясе булганыгыз. Һичшиксез, Аллаһы –** [һәрнәрсәне] **Белүче,** [һәрнәрсәдән] **Хәбәрдар».**

«Әл-Хүҗүрат / Бүлмәләр», 49:13

Бу аять безгә халыкларның төрлелеге – дошманлык өчен түгел, танышу, бер-береңнән өйрәнү өчен җибәрелгәнен җиткерә.

Бүгенге көндә, җәмәгать, мәдәниятебезгә төрле яклардан йогынтылар килә. Кайбер яшьләр, чит мәдәнияткә кызыгып, үз телен, гореф-гадәтен, хәтта динен оныта башлый. Ләкин шуны онытмыйк: чын мәдәният – ул Аллаһыдан ерак түгел, киресенчә, Аңа якын итә торган мәдәният. Мөселман кешесенең мәдәнияте – аның әдәпле булуында, киеменең пакьлегендә, сүзенең йомшаклыгында, ата-анасына ихтирамда.

Җәмәгать әл-мөслимин, яхшы йолаларыбызны күз карасыдай саклыйк: кунакчыллык, сабырлык, мәрхәмәтлелек, туганлык җепләрен саклау… Динебез Исламга каршы килгән гадәтләрдән сакланыйк: ырымнардан, буш бәйрәмнәрдән, рия һәм мактанудан ерак торыйк!

Мәдәниятебез дингә нигезләнгән вакытта гына, ул халыкка бәрәкәт китерә. Динсез мәдәният исә – корыган агач кебек.

Йә Раббым, безнең иманыбызны ныгыт, күңелләребезне пакьлә, безне Ислам мәдәниятенең күркәм үрнәге ит! Ата-бабаларыбызның чиста, әхлаклы гореф-гадәтләрен сакларга ярдәм ит! Балаларыбызны иманлы, әдәпле, милләтенә һәм диненә тугры итеп үстерергә насыйп әйлә!

إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ وَإِيتَاءِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَيَنْهَىٰ عَنِ الْفَحْشَاءِ وَالْمُنكَرِ وَالْبَغْيِ ۚ يَعِظُكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ ﴿٩٠﴾

**«Һичшиксез, Аллаһы гадел булырга, изгелек кылырга һәм** [бигрәк тә] **якын туганнарга** [мохтаҗ булган нәрсәләрен] **бирергә** [һәм туганлык җепләрен ныгытуны] **әмер итә.** [Зина кебек] **Фәхешлектән,** [көферлек, ширек һәм шуның кебек дин кабул итмәгән] **тыелганнан һәм** [кешеләргә] **җәбер-золым кылудан тыя. Сез акылга килерсез дип, сезне үгетли».**

«Ән-Нәхл / Бал кортлары», 16:90

Әлхәмдүлилләһи Раббиль-галәмин!

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рөстәм хәзрәт Хәйруллин,*

*Казанның «Гаилә» мәчете имам-хатыйбы*

*30 гыйнвар вәгазе,*

*шәгъбан аенең 11 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Бәраәт кичәсенең фазыйләтләре

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Шәгъбан аеның 14 нче һәм 15 нче көннәре арасындагы кичә елның иң изге кичәләренең берсе булып санала. Ул кичә гарәпчә «Ләйләтүл-Бәраәт» (Җәһәннәм утыннан азат булу кичәсе) дип атала. Бәраәт кичәсенең фазыйләтләре турында күп хәдисләрдә әйтелгән. Шул кичәдә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте тарала, догалар кабул була, гөнаһлар гафу ителә.

Гайшә анабыз радыяллаһу ганһәдән риваять ителә: «Бервакыт Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм төнге (тәһәҗҗүд) намазын укыды һәм бик озак вакыт сәҗдәдә булды. Мин хәтта ул үлмәдеме икән дип курыктым. Яткан җиремнән торып, аның баш бармагын кузгаттым (аның исән булуына инаныр өчен). Пәйгамбәрнең бармагы кузгалды, һәм мин яткан җиремә кайттым. Аннары аның сәҗдәдә кылган догасын ишеттем: «Мин Синең җәзаңнан мәгъфирәтеңә сыгынам. Синең ризасызлыгыңнан ризалыгыңа сыгынам. Мин Синең Бөек икәнлегеңне беләм, әмма Сиңа тулысынча шөкрана кыла алмыйм. Синнән ярлыкау сорыйм һәм үземә Синнән сыгыну урыны эзлим». Аннары ул сәҗдәдән башын күтәрде һәм намазын тәмамлады. Ул миңа мөрәҗәгать итте: «Гайшә, әллә Пәйгамбәр сиңа хыянәт итте дип уйладыңмы?» Мин аңа: «Юк, Аллаһының Илчесе, мин синең җаныңны бу дөньядан алганнар ахры дип курыктым, чөнки сәҗдәң бик озак булды бит», – дидем. Ул миннән: «Бу кичнең нинди икәнлеген беләсеңме?» –

дип сорады. Мин: «Аллаһы һәм Аның Илчесе моны яхшырак белә», – дидем. Ул миңа болай җавап кайтарды: «Бу шәгъбан аеның яртысы. Һәрнәрсәгә Кодрәт иясе Аллаһы бу кичне Үзенең колларына карады һәм ярлыкау сораучыларны кичерде, аларга Үзенең нигъмәтен ике тапкыр арттырып бирде, әмма мөселманнарга карата начар уйлы булучыларны, үзләренең шул уйларыннан кире кайтканга кадәр, кичерми торды»[1].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә шәгъбан аеның уртасындагы төнне Кәлб кавеме сарыкларының йон төкләре саныннан да күбрәк кешеләрне гафу итә»[2].

Икенче бер хәдис-шәрифтә болай дип әйтелгән: «Шәгъбан аеның унбишенче кичәсе керсә, аны гыйбадәт белән үткәрегез. Көндез исә ураза тотыгыз, чөнки Аллаһы Тәгалә ул кичтә кояшның чыгуына кадәр дөнья галәменә рәхмәтен таратыр һәм: «Тәүбә итүче булса, аны гафу итәм. Ризык сораучы булса, аңа ризык бирәм. Авыруга дучар булучы булса, аңа саулык-сәламәтлек бирәм. Бармы андый кешеләр, бармы?» – дип әйтер»[3].

Имам әс-Сүбки (Аллаһы аңа Үз рәхмәтен ирештерсә иде) үзенең тәфсирендә болай дип әйткән: «Аллаһы Тәгалә җомга көнне бер атна эчендә кылынган гөнаһларны кичерә, Бәраәт кичәсендә бер еллык гөнаһларны гафу кыла. Кадер кичәсендә исә Хак Тәгалә мөэмин бәндәләренең гомер буе кылган гөнаһларын кәффарәт кылып җибәрә».

Имам әш-Шәфигый (Аллаһы аңа Үз рәхмәтен ирештерсә иде) «әл-Үмм» дип аталаган китабында әйткән: «Биш кичәдә догалар аеруча кабул була: җомга алдыннан булган кичтә, ике гает алдыннан булган кичәләрдә, раҗәб аеның беренче кичәсендә һәм шәгъбан аеның уртасында булган кичәдә».

1 Имам Бәйһакый.

2 Имам әт-Тирмизи.

3 Имам әт-Тирмизи, Ибне Мәҗә.

Мөхтәрәм мөселманнар! Бәраәт кичәсенең кадерен белик. Шул кичәдә ихлас күңелдән нәфел (өстәмә) намазларын укыйк, тәүбә, догалар кылыйк, Аллаһы Раббыбызга тәүбә белән мөрәҗәгать итик.

Аллаһы Тәгалә «әт-Тәхрим» сүрәсенең 8 нче аятендә мөэминнәргә болай дип мөрәҗәгать итә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا تُوبُوا إِلَى اللَّهِ تَوْبَةً نَّصُوحًا

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыга ихлас бер тәүбә белән тәүбә итегез».**

«Әт-Тәхрим / Тыю», 66:8

Тәүбәнең файдасы турында Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер мөбарәк хәдисендә болай дип әйтте: «Һәрвакыт үзенең гөнаһлары өчен Аллаһыдан ярлыкау сораган кешегә Аллаһы Тәгалә теләсә кайсы чарасыз хәлләрдән юл күрсәтер, авырлык килгәндә, җиңеллек бирер һәм көтмәгән җирдән ризык бирер»[1].

Әгәр кеше кылган гөнаһлары өчен тәүбә итсә, һәм шул гөнаһларга кайтмаска катгый рәвештә ният кылса, Аллаһы Тәгалә шушы гөнаһларны савапка әйләндерергә вәгъдә бирә:

إِلَّا مَن تَابَ وَآمَنَ وَعَمِلَ عَمَلًا صَالِحًا فَأُولَٰئِكَ يُبَدِّلُ اللَّهُ سَيِّئَاتِهِمْ حَسَنَاتٍ ۗ وَكَانَ اللَّهُ غَفُورًا رَّحِيمًا ﴿٧٠﴾

**«Тик** [көферлектән] **тәүбә иткән, иман китергән һәм изге гамәл кылган кешеләр булмаса гына! Аларның** [тәүбәләре сәбәпле сөртелгән] **начарлыкларын Аллаһы күркәм нәрсәләр белән алмаштырачак. Аллаһы Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әл-Фүркан / Аеручы», 25:70

---

[1] Имам Ибне Мәҗә.

Бервакыт Хәсән әл-Басри (Аллаһы аны Үз рәхмәтеннән аермаса иде) дигән галимгә зарланулар белән дүрт кеше килгән. Берсе – корылыкка, икенчесе – фәкыйрьлеккә, өченчесе – иген (ашлык) уңмавына һәм дүртенчесе балалары булмавына зарланган. Хәсән әл-Басри аларны тыңлагач, барысына да тәүбә кылырга киңәш иткән. Дүртесе дә гаҗәпләнеп: «Хөрмәтле остаз, безнең кайгылар төрле, ләкин сез һәрберебезгә бер үк җавап бирдегез. Моның хикмәте нәрсәдән гыйбарәт?» – дип сораганнар. Хәсән әл-Басри аларга Коръәндәге аятьләр белән җавап биргән:

فَقُلْتُ اسْتَغْفِرُوا رَبَّكُمْ إِنَّهُ كَانَ غَفَّارًا ﴿١٠﴾ يُرْسِلِ السَّمَاءَ عَلَيْكُم مِّدْرَارًا ﴿١١﴾ وَيُمْدِدْكُم بِأَمْوَالٍ وَبَنِينَ وَيَجْعَل لَّكُمْ جَنَّاتٍ وَيَجْعَل لَّكُمْ أَنْهَارًا ﴿١٢﴾

**«Мин әйттем: «Раббыгыздан ярлыкау сорагыз. Һичшиксез, Ул –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче.** [Истигъфар кылыгыз, җитмеш ел дәвам иткән корылык һәм кытлыктан соң Раббыгыз] **Күкне өстегезгә** [чиләктән койган кебек] **мул яуган бер хәлдә җибәрер. Маллар һәм ир балалар белән сезгә ярдәм итәр** [һәм киң мөмкинлекләр бирер], **сезнең** [файдалануыгыз] **өчен бакчалар үстерер һәм сезнең өчен** [ургылып аккан] **елгалар булдырыр».**

«Нух», 71:10–12

Аллаһы Тәгалә барыбызга да изге Бәраәт кичәсендә гыйбадәт кылып, бәхет-сәгадәткә ирешергә насыйп итсә иде. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә

дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нияз хәзрәт Сабиров,*

*Казанның «Апанай» мәчете имам-хатыйбы*

*6 февраль вәгазе,*

*шәгъбан аеның 18 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Малыбызда бәрәкәт булсын дисәк…

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, тәрбияләп торучы Аллаһы Тәгаләгә мактауларыбыз булсын. Галәмнәргә рәхмәт итеп җибәрелгән, динне аңлаткан, өйрәткән, иң яхшы үрнәк булып яшәп күрсәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез ирешсен. Аллаһы Тәгалә изге җомга көнендә мәчеткә килеп кылган гыйбадәтләребезне кабул кылсын. Мәчеткә атлап килгән һәрбер адымыбыз саен Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларын насыйп әйләп, һәрбер адымыбызны гөнаһларыбыз кичерелүгә сәбәп итсен. Ниндидер бик җитди сәбәпләр, авырулар килеп чыгу аркасында гына килеп җитә алмаган мөселман кардәшләребезгә, күңелләрендәге булган ниятләренә, күңелләрендәге булган омтылышларына карап, Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларын насыйп кылсын. Вәгазьләнеп гыйлемебезне арттырырга, дөнья өчен, ахирәт өчен файдалы сүз, файдалы фикер аңларга барчабызга насыйп булсын.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләр! Ислам диненең биш нигезе барлыгын беләбез. Бу: Аллаһы Тәгаләнең берлегенә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең пәйгамбәр булуына ышану, иман китерү; көнгә биш вакыт намаз уку; Рамазан аенда ураза тоту; зәкят бирү; хаҗ кылу. Бүгенге вәгазебездә шушы нигезләрнең берсе булган зәкят турында искә төшерербез.

Зәкят түләү, гомумән садака бирү иманның күрсәткече булып тора. Ягъни чын күңелдән Кыямәт көненә, үлгәннән соң терелүгә, мәңгелек тормышка ышанган кеше генә садака бирә ала, чөнки садака бирү сәүдә кагыйдәсенә каршы килә. Гадәттә без кемгәдер акча бирәбез икән, аның өчен ниндидер товар алабыз, сату-алу башкарыла, акча түләгәч, ниндидер хезмәт күрсәтелә. Ә садакага килгәндә, син тырышып эшләп тапкан хәләл малыңның бер өлешен кемгәдер бушка бирәсең дә, дөньяда аның файдасын күрмисең. Ләкин күңелең белән Кыямәт көнендә сиңа савабы булачагын тоясың, менә бу чын иман күрсәткече булып тора. Бер мең сум акчаң бар иде, шуның йөз сумын садака итеп бирсәң, синең 900 сумың гына кала. Дөнья күзлегеннән караганда, синең акчаң кимеде, син бу акчаны югалттың. Ә ахирәт күзлегеннән карасаң, акчаң артты. Чөнки пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм аңлатып бирә: Аллаһы Тәгалә изгелеккә әҗер-савапны 10 га, 100 гә, хәтта 700 гә кадәр арттырачак. Димәк, синең 100 сум биргән садакаң җәннәттәге хисабыңа 1000 сум, 10 000 сум, 70 000 сум булып күчә ала, ихласлыгыңа карап. Менә бу садака бирү һәм башка изге гамәлләр кылу ахирәткә ышану, иман белән генә ирешеп була торган гамәлләр.

Садакаларның фарыз (мәҗбүри) булганы, нәфел (мәҗбүри булмаган, өстәмә савап бирә торган) төрләре бар. Зәкят яки зәкят садакасы – ул фарыз, мәҗбүри бирелергә тиеш садака. Шушы фарыз булган, мәҗбүри булган зәкят садакасы һәм аның төрләре турында сөйләшербез.

Зәкят сүзе «пакьләү», «арту» дигән мәгънәләргә ия. Аллаһы Тәгалә зәкят бирүче кешенең байлыгын пакьли, күңелен чистарта. Шулай ук Аллаһы Тәгалә зәкят бирүченең байлыгын арттыра, малына бәрәкәт бирә.

Әйе, безнең динебез пакьлеккә нигезләнгән. Акыл пакьлегенә төрле атеистик идеологияләрдән арынып һәм бер Аллаһыга ышану, Аңа буйсыну белән ирешергә була. Тәнебез пакьлеге госел, тәһарәт белән хасил була. Күзләр, колаклар харам булган әйберләрне карамау, тыңламау белән пакьләнә. Йөрәгебез, күңелебез ихлас ният белән изге гамәл аша чистара. Мал-туар

Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен чалган корбан белән пакьләнсә, кешенең акчасын, байлыгын садака бирү пакьли. Димәк, нәтиҗә ясап, шуны әйтә алабыз: садака кешенең малын гына пакьләп калмый, ул күңелне төрле калеб авыруларыннан да чистарта. Зәкят һәм башка төрле садакалар бирүче үз-үзен генә ярату, комсызлык, саранлык кебек сыйфатлардан күңелен чистарта, көнчелек-хөсетлектән арына. Шулай итеп садака бирүче кеше Аллаһыга һәм кешеләргә якын була.

Зәкят Коръәндә бик күп тапкырлар искә алына. Намаз белән зәкят Ислам диненең терәкләре булып тора. Коръәни Кәримдә намаз уку һәм зәкят бирү хакында Аллаһының әмерләре бик еш янәшә килә. Бу зәкят бирүнең намаз кебек бик мөһим гыйбадәт икәнлеген күрсәтә, аңлата. Мәсәлән:

وَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ وَآتُوا الزَّكَاةَ

**«Намазны** [бөтен рөкеннәре белән җиренә җиткереп] **башкарыгыз,** [малларыгыздан] **зәкят бирегез...»**

«Әл-Бакара» / «Сыер», 2:43

Бай кеше (ягъни нисабка ия булган кеше) Аллаһы Тәгалә билгеләгән күләмгә җиткән малыннан Коръәндә билгеләнгән кешеләргә зәкят түләмәсә, мескен-фәкыйрьләрнең кесәсенә кергән кебек була, аның бөтен малы харамга әйләнә, һәм ул җанына, тәненә зыян китерә. Иманы зәгыйфь булган кешеләр генә зәкят түләү мәсьәләсендә карышып, зәкят түләмичә, Раббыларына буйсынмыйлар.

Фарыз булган зәкятнең берничә төре бар:

**1. Байлыктан, акчадан.** Кешенең акчасы нисабка тулса, ягъни 85 грамм алтын бәясеннән артып китсә, һәм шуннан кимемичә 1 ел сакланса (ай календаре буенча 354 көн), шул акчаның 2,5 % фәкыйрьләргә, мохтаҗларга һәм Коръәндә билгеләнгән башка кешеләргә бирелә.

**2. Сәүдә әйләнешендә һәм керем алу чыганагы булган товарлардан.** Алар нисабка тулса (85 грамм алтын бәясе), шул булган сумманың шулай ук 2,5 % бирелә. Нисаб товарны күпләп сатып алу бәясе буенча һәм керемне дә кушып санала.

**3. Җыелган уңыштан.** Бу гошер садакасы дип атала. Бәрәңге, кабак, кишер, суган һәм башкалардан бирелә. Хезмәт кермичә, яңгыр суы белән генә үскән уңышның уннан бере бирелә. Ә инде өстәмә хезмәт, чыгым тотылса, су сибелсә, уңышның егермедән бер өлеше мохтаҗ мөселманнарга бирелә. Балның шулай ук уннан бер өлеше гошер садакасы итеп бирелә.

**4. Хайваннардан, маллардан.** Дөя, сыер, сарык, кәҗә малларыннан. Сыерлар нисабы – 30 баштан арткач, бер бозау зәкят итеп бирелә башлый. Сарык һәм кәҗә нисабы – 40 баштан артканнан соң, зәкят итеп бер сарык яки бер кәҗә бирелә башлый. Шарт булып бу малларның елның күпчелек өлешен көтүлектә үткәрүләре тора. Елның күпчелек вакытын хуҗалыкта, фермада ашатылган маллардан зәкят түләнми.

**5. Керем китерә торган күчемсез милектән.**

**6. Фитр садакасы.** Фитр садакасы да фарыз булган садакадан санала. Ул Рамазан аенда бирелә, аны гает намазына кадәр биреп өлгерергә кирәк. Фитр садакасының күләмен мөфтият билгели. Фитр садакасын азык-төлек белән дә, акчалата да бирергә мөмкин. Гаиләдәге барлык кешеләр исеменнән бирелә. Бу садаканың ике максаты бар: беренче максаты – гает көнендә мохтаҗ, фәкыйрь кешеләр дә яхшы ризыклар ашап сөенсеннәр дигән; икенче максаты – ураза тотучы ялгышып, берәр гөнаһ кылып куйса, фитр садакасы Аллаһының рәхмәте белән кешенең бу гөнаһлардан пакьләнүенә сәбәп була.

Мөхтәрәм җәмәгать, мөселман кешесе яхшылыкны, изгелекне эшләп кенә калмый, ә аны тагын да саваплырак итеп, хәерлерәк вакытны туры китереп эшләргә тырыша. Шуңа күрә күп кенә зәкят бирүче мөселманнар үзләренең зәкятләрен изге Рамазан аенда түләргә тырышалар. Чөнки Рамазан

аенда кылган изгелекләр өчен Аллаһы Тәгалә әҗер-савапларны тагын да арттырып бирә. Рамазан аенда мең айдан да хәерлерәк булган Кадер кичәсе бар.

Әгәр кылган изгелекләребез, биргән садакаларыбыз, зәкятләребез шул кичәгә туры килсә, савабы тагын да арта торган була. Кадер кичәсе мең айдан хәерлерәк, мең айдан өстенрәк, бөегрәк. Бу төндә эшләнгән изгелек, яхшылык, гыйбадәт савабы буенча мең ай дәвамында кылынган изгелекләрдән өстен, мең ай дәвамында кылынган гыйбадәтләрдән өстен. Мең ай 83 ел 4 айга тигез була. 83 ел 4 ай – бер кеше гомере, озак яшәүче бер кеше гомеренә тигез. Аллаһы Тәгаләнең безгә карата булган нинди рәхмәте, юмартлыгы бу! Бер төндә кылган изгелек өчен 83 ел 4 ай буе гыйбадәт кылган савапка ирешү мөмкинлеге бирә. Ягъни шушы төнне туры китереп, 2 рәкәгать кенә намаз укысак, 83 ел 4 ай буе көн саен шушы 2 рәкәгать намаз укыган кебек языла. Дога кылсак, Аллаһыдан дөнья, ахирәт нигъмәтләрен сорасак, 83 ел 4 ай буе шул доганы кылган кебек булабыз. Шушы төнне туры китереп, 100 сум садака бирсәк, 83 ел 4 ай дәвамында көн саен 100 сум садака биргән кебек языла. Димәк, 100 сум садака бирсәң, 3 миллион сум садака биргән кебек буласың.

Менә шулай бу дөнъяда кылган изгелекләребез белән үзебезгә җәннәт нигъмәтләрен арттырабыз, үзебезгә җәннәт төзибез килеп чыга. Шуңа акыллы мөселманнар шушы саваплар күбәйтелә торган Рамазан аенда зәкят садакаларын бирәләр. 20 мең сум зәкят бирсә, савабы 600 миллион сум биргән кебек була, 600 миллион җәннәттәге хисабына күчә. Әгәр мөселман кешесе 100 мең сум бирсә, савабы 3 миллиард сум биргән кебек санала. Бу Аллаһы Тәгаләнең безгә күрсәткән юмартлыгы. Безгә шуны аңлап, шушы форсатны кулланып калырга кирәк.

Аллаһы Тәгалә кылган изгелекләребезне кабул кылсын, аларның файдаларын дөньяда һәм ахирәттә күрергә насыйп итсен. Барчабызга җәннәтләрдә күрешергә, җәннәтләрдә бер-беребезне күреп сөенергә, шатланырга насыйп булсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рифат хәзрәт Ибраһимов,*
*Кукмара районы Зур Сәрдек авылы мәчете имам-хатыйбы,*
*Кукмара мәдрәсәсе мөгаллиме*

*13 февраль вәгазе,*

*шәгъбан аеның 25 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Рамазанда рухи көч туплап, аны ел буена саклыйк

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм хак Илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз ирешсә иде.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәсе, гадел хаким Гомәр радыяллаһу ганһе безгә бик үтемле бер хакыйкатьне әйтеп калдырган: «Сиңа хисап кылганчы, үз-үзеңә хисап кыл. Синең гамәлләреңне үлчәгәнче, үзең гамәлләреңне үлчәп кара». Бу сүзләр күңелебезгә бер чәнечке кебектер, чөнки кешегә башка кешене анализларга, тикшерергә җиңел булса да, үз-үзенә карата гадәттә ул андый ук таләпчән була алмый. Кешедән гаеп тапсак та, үзебезгә карата аклану эзлибез шул. Ни кызганыч…

Хәзрәти Гомәр радыяллаһу ганһенең сүзләрендә зур хикмәт вә гыйбрәт ята. Үлем килеп, Раббыбыз каршына басканчы, син гамәлләреңә хуҗа кебек: кирәк булса, тәүбә кыла аласың, кирәк булса, өстәмә изгелекләр кыла аласың.

Әмма Кыямәт көнендә алар сиңа хуҗа. Авыр Кыямәт көненнән курыксаң, бу дөньяның җиңеллегеннән файдаланып кал: үз-үзеңә хисап кыл да, үзеңне яхшы якка үзгәртә башла.

«Кем үзгәрергә тиеш?» – дип сорау бирүче булса, ул – син! Ул – мин! Ул – һәр мөэмин. Рамазан ае – моны гамәлгә ашыру өчен иң кулай вакыт. Нигә? Чөнки Рамазан – үзгәрү ае. Ул айда шайтаннар чылбырланып (чылбыр белән богауланып) куелган була, җәһәннәм ишекләре ябыла, рәхмәт ишекләре ачыла. Күңел явызлыктан сафлана, изге гамәлләр кылу җиңелрәк бирелә. Ә хисап кылу – бу үзгәрешнең иң төп адымыдыр. Ул адымнан кала икенче адым кылып булмаячак. Кеше үзгәрергә теләсә, ул үзенең бүгенге, хәзерге халәтен белергә тиеш.

Эшмәкәрлек яки ябыгу белән чагыштырып карыйк. Мәсәлән, кеше: «Мин 1 миллион сум керем телим», – дип әйтә. «Ә бүгенге көндә керемең күпме соң?» – дип сорау биргәч, ул белмим дип җавап бирсә, без ул кешене акылсыз дип әйтер идек. Ә бәлки аның кереме 2 миллиондыр инде. Сәер булыр иде, шулай бит. Яки ябыгучы кеше: «Минем 60 килограмм каласым килә», – дип ябыга башлый. Ул үзенең авырлыгының күпме икәнен белмичә яки тикшереп тормыйча, теләгән нәтиҗәсенә ирешә аламы?

Шулай итеп, без үзгәрергә телибез, хисап кылырга җыендык. Үзебезгә түбәндәге сорауларны бирик:

1. Минем Аллаһы Тәгалә белән элемтәм нинди?
2. Намазларым вакытында укыламы?
3. Зикер-тәсбихләрем җитәме?
4. Коръән белән мөнәсәбәтем нинди?
5. Кешеләр белән мөнәсәбәтем нинди?
6. Әти-әниемә хөрмәтем, кардәшләремә ярдәмем тияме, күршеләрем белән мөнәсәбәтем нинди?
7. Үзем белән мөнәсәбәтем ничек? Мин нәфесем колымы әллә нәфесем минем колыммы?

8. Вакытымны файдалы эшләргә багышлыйммынмы? Һәм башка шуңа охшаш сораулар.

Җәмәгать, мондый сорауларны бик күп итеп язып була. Бер атнадан Рамазан ае җитәчәк, шуңа күрә бер дәфтәр алыгыз да, үзегезгә җитди мөнәсәбәттә булып, шунда шушындый сораулар язып чыгыгыз. Алар 10 да, 40 та була ала. Иң мөһиме, уйлап языгыз.

Шуннан бер ай дәвамында, аларга карый-карый, гамәлләрегезне дөресли башлагыз. Бу сүзләрем сезгә генә түгел, үземә дә кагыла. Шуңа, бергәләп төзәлик!

Рамазан ае узгач, һәр сорау буенча үзебезгә хисап кылыйк! Һәм Рамазан ае үтеп, бер-ике ай узгач, кабат бу исемлеккә әйләнеп кайтыйк: Рамазан аенда төзәтелгән гамәлләрнең кайсылары кире әйләнеп кайткан да, хәзер кабат безнең белән?

1. Әгәр дә үзгәрешләр Рамазан аенда гына булса, ул вакытта мин нинди файда алам? Мине Рамазаннан соң да сакларлык яңа гадәтләр калдымы?

2. Минем үзгәрүем ни белән бәйле иде? Үзгәрүем Аллаһы ризалыгы өченме?

3. Минем киләсе адымым нинди булачак? Дин баскычтан күтәрелүгә охшаган. Рамазан – беренче баскыч. Аннан соң икенче, өченче баскычка менәргә тырышаммы мин? Мәсәлән, Рамазанда Коръән уку, нәфел намазлар кылу гадәте арта. Ә Рамазаннан соң алар сакланамы, нәфел уразалар тотыламы?

Шулай итеп, безнең алда бер ай. Нишлибез, җәмәгать?

Һәр кич йоклар алдыннан бер минут вакыт табып, көнне тикшерәбез: «Бүген Аллаһы ризалыгы өчен нәрсә кылдым? Нинди хаталар кылдым? Иртәгә аларны ничек төзәтермен?» Бу кечкенә генә булып күренгән гамәл бездә зур үзгәрешләр булдырырга сәләтле. Әгәр бу эшкә сәләтле булмасак, димәк, Раббыбыздан ярдәм сорап, мөрәҗәгать итик: «Ий Аллаһым! Безне үзебезгә хисап сорарлык кешеләрдән кыл. Үзебезне төзәтергә һәм Сиңа чын

мөэмин-мөселманнардан булып кайтырга ярдәм ит. Безне Син риза булган гамәлләр кылучы мөэминнәрдән кыл. Безне үзебезнең нәфесебезгә калдырма. Ярдәмең белән яхшы якка, хәерле якка үзгәрә алсак иде. Әмин!»

Бүгенге көндә мотивация дигән сүз популяр. Икенче төрле безне канатландыра торган сүзләр, вакыйгалар дип әйтергә була. Без дә, Рамазанның никадәр бүләкләр белән килгәнен аңласак, хәдисләрдә әйтелгәнчә, ел буе Рамазан булсын дип теләр идек. Ягъни, әгәр кеше аны чын аңлау белән аңласа, ул аны шулай булуын теләр дә иде, әмма бу күпләребезгә бирелмәгән…

Рамазан – ул рухи көч туплау вакыты, ә елның калган өлеше – шушы җыелган көчне куллану чоры. Рамазанда җыелачак гадәтләр бихисап:

– начар гадәтләрдән ерак булдык;

– телебезне тыйдык;

– низаглардан ерак тордык;

– гел сабыр булдык;

– садакалар бирдек;

– өстәмә намазлар укыдык;

– кешеләргә күбрәк ярдәм иттек;

– Коръән укыдык һ. б.

Болар барысы да – безнең моңа хәлебез җиткәнен күрсәткән дәлил. Димәк, бер ай булдыра алдык икән, бераз булса да дәвам итү дә көчебездән килә. Рамазаннан соң шушы гамәлләрне үзебезнең гадәтебезгә кертә башлыйк. Аз-азлап, бер гамәл, бер гамәл итеп булса да. Кечкенә адымнар озаграк саклана. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә кечкенә, әмма даими гамәлләр турында әйтеп калдырган.

Ни өчен үзеңне хисап кылып, тикшереп тору мөһим?

1. Гамәлләрне ни сәбәпле кылуыңны (мотивларыңны) һәм хисләреңне яхшырак аңлый башлар өчен. Үз-үзеңне анализлау кешегә нәрсәдән ачу барлыкка килүен, нәрсәнең шатлык китерүен аңларга ярдәм итә. Бу гамәлләрне аңлырак рәвештә башкарырга мөмкинлек бирә.

2. Шәхси үсешне тизләтә. Кеше, үзенең көчле һәм зәгыйфь якларын аңлагач, максат куеп, үзен төзәтә, яңа файдалы гадәтләр булдыра ала.

3. Карарларны уйлап, аңлап кабул итәргә ярдәм итә. Күп вакыт без эшләрне, гыйбадәтләрне автоматик рәвештә кылабыз. Бу көндәлек тормышка гына түгел, намазларыбызга да кагыла ала.

Онытмыйк, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Рамазан аена ирешеп тә, аннан гөнаһлары ярлыканмыйча чыккан кешегә кайгы булсын», – дип әйткән.

Рамазан безгә никадәр көчле була алуыбызны, тырышсак, иренмәсәк, нинди ихлас була алачагыбызны күрсәтә. Без ай буе уразада, тәравихларда булачакбыз. Республика күләмендә бар мәчетләр тулып торачак. Ә аннан соң? Аннан соң мәчетләр кабаттан ятим калачакмы? Без, кими-кими, шул гадәттәге җәмәгатькә әйләнеп кайтачакбызмы? Алайса, син ни өчен үзгәрдең? Рамазан өченме яки Аллаһы Тәгалә өченме?

Бу һәм башка сораулар туганчы, хәзердән үк үзебезгә үзебез хисап кыла башлыйк. Ә Аллаһы Тәгалә Үзе ярдәмче булсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Шамил хәзрәт Әхмәтгалиев,*

*Арча районы Хәсәншәех авылы мәчетенең имам-хатыйбы*

*20 февраль вәгазе,*

*Рамазан аеның 2 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Хуш килдең, Рамазан!

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактау, хәмед-сәналәребез бар галәмнәрне юктан бар кылып, безне тәрбияләп торучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булсын! Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә – күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез, аның сәхабәләренә, табигыйннарга, тәбге-табигыйннарга сәламнәребез ирешсә иде!

Мөхтәрәм җәмәгать, мөбарәк Рамазан аена кердек! Ниһаять бөтен Ислам галәме көтеп алган олы кунак, айларның солтаны булган мөбарәк Рамазан ае да башланды. Бу ай – һәр иманлы йөрәк өчен куаныч, һәр изге гамәл кылучыга шатлык һәм форсат. Олы кунакны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай каршы алган дип риваять ителә: «Сезгә айларның солтаны булган Рамазан ае килде. Хуш килде, мәрхәбә! Ураза ае бәрәкәт алып килде. Килгән кунакларның иң юмартлысы ул»[1].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәм аның сәхабәләре мөбарәк Рамазан аен ашкынып көтеп алганнар, бу айга ирешер өчен догалар кылганнар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый догасы риваять ителә:

اَللّٰهُمَّ سَلِّمْنِيْ لِرَمَضانَ وَسَلِّمْ رَمَضانَ لِيْ وَسَلِّمْه لِي مُتَقَبَّلا

---

[1] Ибне Раҗәб әл-Хәнбәли, «Ләтаифүл-мәгариф».

«Аллаһым! Мине Рамазан ае өчен сакла, Рамазанны минем өчен сакла, һәм аны миннән кабул ит».

Мөгаллә бине Фазыл дигән галим болай дип әйткән: «Сәхабәләр изге айга 6 ай кала Аллаһыдан: «Ий Раббым, бу Рамазан айларын күрергә насыйп итсәң иде», – дип сорый башлаганнар.

Рамазан ае башлану белән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләрне болай дип сөендергән: «Сезгә мөбарәк Рамазан ае килде! Аллаһы Тәгалә сезгә бу айда ураза тотарга кушты. Бу айда күк ишекләре ачыла, ә җәһәннәм ишекләре ябыла, иң азган шайтаннар богаулар белән бәйләп куела. Аллаһы Тәгаләнең бу айда бер кичәсе бар. Ул мең айдан да хәерлерәк. Кем дә кем анда биреләчәк хәерле нәрсәдән мәхрүм калса, ул чыннан да мәхрүм калган кеше була»[1].

Әлхәмдүлилләһ, мәчетләребез җанланды, күбесе тулды. Рамазан аенда ифтар ашларында катнашып, тәравих намазларын башкарып, мөселманнар гыйбадәтханәләргә җан кертә. Тәфсир галимнәре «әт-Тәүбә» сүрәсенең 18 нче аятенә киләсе аңлатма бирәләр:

إِنَّمَا يَعْمُرُ مَسَاجِدَ اللَّهِ مَنْ آمَنَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ وَأَقَامَ الصَّلَاةَ وَآتَى الزَّكَاةَ وَلَمْ يَخْشَ إِلَّا اللَّهَ

**«Аллаһының мәчетләрен Аллаһыга һәм Ахирәт көненә инанган,** [фарыз] **намазын укыган, зәкятен биргән һәм Аллаһыдан башка һичкемнән курыкмаган кешеләр генә җанландырыр».**

«Әт-Тәүбә», 9:18

Мәчетләребездә җыелып, гыйбадәт кылып, Рамазан аеның төп максатларының берсенә – гөнаһлардан пакьләнеп, Аллаһының ярлыкавына ирешәбез. Аллаһы Тәгалә «әт-Тәүбә» сүрәсенең 108 нче аятендә мәчеттә гыйбадәт кылган сәхабәләр турында болай дип әйтә:

[1] Имам Әхмәд, имам ән-Нәсаи.

فِيهِ رِجَالٌ يُحِبُّونَ أَن يَتَطَهَّرُوا ۚ وَاللَّهُ يُحِبُّ الْمُطَّهِّرِينَ

**«Анда – пакьләнергә яраткан ирләр, Аллаһы исә пакьләнүчеләрне сөя».**

«Әт-Тәүбә», 9:108

Мәчетләрдә Аллаһыны зикер итүче мөселманнарны мактап, Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

فِي بُيُوتٍ أَذِنَ اللَّهُ أَن تُرْفَعَ وَيُذْكَرَ فِيهَا اسْمُهُ يُسَبِّحُ لَهُ فِيهَا بِالْغُدُوِّ وَالْآصَالِ ﴿٣٦﴾ رِجَالٌ لَّا تُلْهِيهِمْ تِجَارَةٌ وَلَا بَيْعٌ عَن ذِكْرِ اللَّهِ وَإِقَامِ الصَّلَاةِ وَإِيتَاءِ الزَّكَاةِ ۙ يَخَافُونَ يَوْمًا تَتَقَلَّبُ فِيهِ الْقُلُوبُ وَالْأَبْصَارُ ﴿٣٧﴾

**«Биек итеп корылуына һәм эчләрендә исеме искә алынуына Аллаһы рөхсәт биргән йортларда** [бөтен мәчетләрдә] **– әнә шунда иртән һәм төштән соң** [иртә, өйлә, икенде, ахшам һәм ястү намазларын укып] **Аны тәсбих итәләр. Шундый ирләр, сәүдә дә, сату да аларны** [тел һәм күңел белән] **Аллаһыны зикер итүдән, намаз укудан һәм зәкят бирүдән читкә юнәлдерми.** [Чөнки] **Алар йөрәкләр һәм күзләр әйләнеп торасы көннән куркалар».**

«Ән-Нур», 24:36-37

Рамазан аенда мәчетләребезгә тиешлечә игътибар бирик. Рамазан аенда бөек сәхабә Гомәр бине әл-Хаттаб радыяллаһу ганһе чорында мәчетләрдә Коръән укылган һәм мәчетләр яктырткычлар белән нурланган. Рамазан аеның иң беренче төнендә хәзрәти Гали бине Әбү Талиб радыяллаһу ганһе, мәчетләрдә Коръән укылганын ишетеп, яктырткычларның нурын күреп, болай дигән: «Аллаһы Тәгалә Гомәр бине әл-Хаттабның каберен нурландырсын, ул Аллаһының мәчетләрен Коръән белән нурландырган кебек». Бу яктырткычлар әлеге вакытта «фәвәнис» дип атала.

Аллаһы Тәгалә кешеләр өчен чыгарылган өммәтләрнең иң яхшысына – Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм өммәтенә – әүвәлге кавемнәрдә булган иң яхшы гыйбадәтләрне боерган. Аллаһы Тәгалә «ән-Ниса» сүрәсенең 26 нчы аятендә болай дип әйтә:

يُرِيدُ اللَّهُ لِيُبَيِّنَ لَكُمْ وَيَهْدِيَكُمْ سُنَنَ الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ وَيَتُوبَ عَلَيْكُمْ ۗ وَاللَّهُ عَلِيمٌ حَكِيمٌ ﴿٢٦﴾

**«Аллаһы сезгә** [белмәгән нәрсәләрегезне] **бәян итәргә, сезне дә сездән элгәреләрнең** [пәйгамбәрләрнең һәм изгеләрнең] **юлларына күндерергә һәм сезнең тәүбәгезне кабул итәргә тели. Аллаһы –** [һәрнәрсәне] **Белүче, Хикмәт иясе».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:26

Иң яхшы гыйбадәтләрнең берсе – Рамазан ае уразасы. Аллаһы Тәгалә болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا كُتِبَ عَلَيْكُمُ الصِّيَامُ كَمَا كُتِبَ عَلَى الَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿١٨٣﴾

**«Ий иман китерүчеләр! Сездән алда килеп киткәннәргә** [фарыз булып] **язылган кебек, сезгә дә** [Рамазан аендагы] **ураза** [фарыз буларак] **язылды. Бәлки,** [ачлык ярдәме белән гөнаһлардан сакланып] **тәкъвалык ияләреннән булырсыз!»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:183

Аятьтән күргәнебезчә, уразаның төп максаты – тәкъвалыкка ирешү, булган гөнаһларыбыздан арыну. Димәк, Аллаһы Тәгалә безгә бары тик яхшылык тели, җәһәнннәм утыннан коткарырга һәм җәннәт бакчаларына ирештерергә тели.

Рамазан аеның фазыйләтләре бик күп. Бу мөбарәк айны без тәүлек буе гыйбадәттә үткәрәбез – көндезләрен ураза тотабыз, төннәрен намазалар укыйбыз. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнән риваять ителә: «Әгәр дә кешеләр Рамазан аенда нәрсә бар икәнлеген белсәләр, ел буе Рамазан ае булуын теләрләр иде»[1].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Рамазан аеның беренче кичәсе җитсә, шайтаннар һәм җеннәрнең иң начарлары богаулап куела. Бу айда җәһәннәм ишекләре ябыла һәм аның бер ишеге дә ачылмый, шулай ук анда җәннәт ишекләре ачыла һәм аның бер ишеге дә ябылмый. Ул айда бер фәрештә: «Әй изгелек кылырга теләүче! Күбрәк изгелек кыл! Әй гөнаһлар кылырга теләүче! Гөнаһлар кылудан тукта!» – ди».

Рамазан аенда ураза тоту гөнаһлар кылудан туктарга ярдәм итә. Уразада булган кешенең гөнаһлары гафу ителә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем дә кем Рамазан аенда иман белән, Аллаһының әҗер-савап бирүенә өмет итеп, ураза тотса, аның элеккеге гөнаһлары гафу ителә»[2].

Рамазан аен дөрес рәвештә уздырган мөселман хисапсыз әҗер-савапка лаек була. Кодси хәдистә Аллаһы Тәгалә: «Ураза – Минем өчен, һәм Мин Үзем аңа әҗер-савабын бирәм», – ди[3]. Мөэмин-мөселман кешесенең бу әҗергә лаек булуын галимнәр түбәндәге мәгънәләрдә аңлаталар:

– ураза риядан ерак булган гыйбадәт; тотылган уразаның әҗер-савабы рия сәбәпле югалмый;

– шулай ук ураза – ул сабырлык күрсәтү, ә сабырларга Аллаһы Тәгалә хисапсыз әҗер-саваплар насыйп итә:

إِنَّمَا يُوَفَّى الصَّابِرُونَ أَجْرَهُم بِغَيْرِ حِسَابٍ

---

[1] Әбү Ягълә, Ибне Хәзимә.

[2] Имам әл-Бохари.

[3] Имам әл-Бохари.

> **«Сабыр итүчеләрнең әҗере** [үлчәүләргә салынмыйча] **хисапсыз биреләчәк».**

«Әз-Зүмәр / Төркемнәр», 39:10

Газиз дин кардәшләрем! Аллаһы Раббыбызның кушканнарын үтәп, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең юлында булып, динебездә тугры булырга насыйп булсын! Рамазан аенда тоткан уразаларыбыз, барча кылган хәерле гамәлләребез кабул булсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нурислам хәзрәт Кучкаров,*

*Казанның «Ярдәм» мәчетенең икенче имамы*

*27 февраль вәгазе,*

*Рамазан аеның 9 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Рамазан – Коръән иңгән ай

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча мактау, хәмед-сәналәребез бар галәмнәрне юктан бар кылып, безне тәрбияләп торучы Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә булсын! Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә – күңел түрләребездән чыккан салават-шәрифләребез, аның сәхабәләренә, табигыйннарга, тәбге-табигыйннарга сәламнәребез ирешсә иде!

Рамазан аеның башка айларга карата өстенлеге Коръәнгә бәйле. Бу мөбарәк айда кешелек дөньясына галәмнәрнең Раббысы Аллаһы Тәгаләнең ахыргы мөрәҗәгате – Коръәни Кәрим – иңгән. Аллаһы Тәгалә «әл-Бәкара» сүрәсенең 185 нче аятендә әйтә:

شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۚ

**«Рамазан ае – аңарда кешеләр өчен һидаять, туры юлны күрсәткән ачык дәлилләр, хакны ялганнан аерган Коръән иңдерелгән...»**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:185

Мөбарәк Рамазан аеның Кадер кичәсендә Коръәни Кәрим Ләүхел-Мәхфүздән тулы килеш беренче кат күккә иңдерелгән. Аллаһы Раббыбыз «әл-Кадр» сүрәсенең 1 нче аятендә болай дип әйтә:

إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةِ الْقَدْرِ ﴿١﴾

**«Һичшиксез, Без аны** [мәңгелек могҗиза булган Коръәни Кәримне] **Кадер кичәсендә** [Ләүхел-Мәхфүздән тулы килеш беренче кат күккә] **иңдердек».**

«Әл-Кадр / Кадер киче», 97:1

«Әд-Духан» сүрәсенең 3 нче аятендә болай дип әйтелә:

إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةٍ مُّبَارَكَةٍ ۚ إِنَّا كُنَّا مُنذِرِينَ ﴿٣﴾

**«Без аны мөбарәк бер кичәдә иңдердек. Һичшиксез, Без –** [колларыбызны алларындагы хәвефләрдән] **кисәтүчеләрбез».**

«Әд-Духан / Төтен», 44:3

23 ел дәвамында Коръәни Кәрим беренче кат күктән Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә Җәбраил фәрештә аркылы өлешләп-өлешләп тапшырылып барган. Аллаһы Раббыбыз «әл-Исра» сүрәсенең 106 нчы аятендә әйтә:

وَقُرْآنًا فَرَقْنَاهُ لِتَقْرَأَهُ عَلَى النَّاسِ عَلَىٰ مُكْثٍ وَنَزَّلْنَاهُ تَنزِيلًا ﴿١٠٦﴾

**«Без, син Коръәнне кешеләргә ашыкмыйча укысын өчен, бүлгәләдек һәм аны өлешләп иңдердек».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:106

Шулай ук Коръәни Кәримнең иң беренче аятьләре мөбарәк Рамазан аенда иңгән дип риваять ителә. Бу айда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм Җәбраил фәрештә белән Коръәнне тулысынча укып (кабатлап) чыга торган булган.

Ураза аенда Аллаһы Тәгалә кылган һәр изге гамәл өчен 700 һәм аннан да артык әҗер-савап вәгъдә итә. Димәк, һәр укылган хәрефнең әҗере бу мөбарәк айда 700 гә хәтле арттырыла. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә

сәлләм болай дип әйткән: «Кем дә кем Рамазан аенда Аллаһыга бер нәфел гамәл эшләп якынайса – калган айларда фарыз гамәлне кылган кебек, ә бер фарыз гамәл кылган кеше 700 фарыз гамәл кылган кебек булыр».

Гади көннәрдә Коръәни Кәримнең укылган бер хәрефе өчен 10 әҗер-савап бирелә. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Кем Аллаһының Китабыннан бер хәреф укыса, аңа бер изгелек языла. Ә бу изгелек тагы ун тапкырга арттырылыр. Мин «Әлиф, ләм, мим» бер хәреф дип әйтмим, әмма «әлиф» – ул бер хәреф, «ләм» – ул бер хәреф, «мим» – ул бер хәреф»[1].

Кыямәт көнне ураза һәм Коръән үз әһелләренә шәфәгатьче булыр. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Кыямәт көнендә ураза һәм Коръән адәм баласын яклаучы булырлар. Ураза һәм Коръән, һәрберсе: «Мин бәндәгә шәфәгать кылам», – дип, үзара бәхәсләшерләр. Ураза: «Әй Раббым! Бу бәндәнне көндезләрен ризыктан вә шәһвәттән тыйдым. Миңа аның өчен шәфәгать кылырга рөхсәт ит», – дияр. Коръән: «Әй Раббым! Бу бәндәңне төннәрен йокыдан тыйдым. Миңа аның өчен шәфәгать кылырга рөхсәт ит», – дияр. Шулвакытта ураза вә Коръән ул бәндәгә шәфәгать кылырлар». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янә: «Коръәнне укыгыз, чөнки ул укучыларына Кыямәт көнендә шәфәгатьче булыр», – дигән[2].

Коръән укучы Кыямәт көнендә Кирамән Кәтибин (намуслы гамәлләр теркәүче фәрештәләр) белән бергә була. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кыямәт көнендә Коръәнне оста укучы намуслы гамәлләр теркәүче фәрештәләр белән булыр. Ә кем Коръәнне тотлыгып, авырлык белән укыса, аңа ике әҗер булыр»[3].

Коръән укучының күңеле тынычланыр, һәм аны рәхмәт каплар. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә ссәләм: «Әгәр бер төркем кеше,

---

[1] Имам әт-Тирмизи.

[2] Имам Мөслим.

[3] Имам Мөслим.

Аллаһының йортына җыелып, Аның Китабын укыса һәм өйрәнсә, аларга тынычлык иңәр, аларны рәхмәт каплар, фәрештәләр аларны чолгап алыр, һәм Аллаһы аларны Үзе янындагыларга мактап искә алыр», – дип әйткән[1].

Коръәнне күбрәк ятлаган саен, адәм баласы оҗмахта тагын да югарырак дәрәҗәләргә күтәреләчәк. Бу кешегә болай дип әйтелер: «Фани дөньяда Коръәнне ничек укыган булсаң, ахирәт тормышында да шулай ук укы». Һәм ул һәр укыган аять белән оҗмахта югарырак дәрәҗәләргә күтәрелер.

Коръән әһелләре Коръәннән күңел һәм тән шифасы алалар. Аллаһы Тәгалә әйтте:

وَنُنَزِّلُ مِنَ الْقُرْآنِ مَا هُوَ شِفَاءٌ وَرَحْمَةٌ لِّلْمُؤْمِنِينَ ۙ وَلَا يَزِيدُ الظَّالِمِينَ إِلَّا خَسَارًا ﴿٨٢﴾

**«Без мөэминнәр өчен шифа һәм рәхмәт булган Коръәнне иңдерәбез. Әмма ул** [Коръәни Кәримне инкяр итүдә үҗәтлек күрсәткән] **залимнәргә зарардан башка берни дә арттырмый».**

«Әл-Исра / Төнге күчеш», 17:82

Хөрмәтле дин кардәшләрем, кайбер кешеләр: «Коръәнне өйрәнүе авыр, олыгайдым, хәтерем юк, эшләргә кирәк», – диләр. Һаман да үзен аклый торган сәбәп эзлиләр. Әмма эшләүче мөселманнар арасында да Коръән укучылар бик күп, алар вакыт юк дип зарланмый. Мәдрәсәләрдә кичке бүлектә, мәчетләр каршындагы курсларда укыган олы абыйларның, апаларның оста итеп Коръән укыганын ишетергә була, алар хәтер юк дип зарланмый. Аллаһының Илчесе саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Сезнең иң хәерлегез – Коръәнне өйрәнүче һәм башкаларга өйрәтүче»[2].

Көн дәвамында Коръәнгә аерым вакыт билгеләп кую безнең үзебездән тора. Коръән – ул Аллаһының сүзләре, безгә бөтен галәмнәрнең Раббысы

[1] Имам Мөслим.

[2] Имам әл-Бохари.

мөрәҗәгать итә: «Ий иман китергән бәндәләр!», «Ий кешеләр», – ди. Ничек инде бу очракта жавап бирмәскә?! Коръәнне уку – ул Аллаһыга, Аның чакыруына җавап бирү, сөйләшү.

Коръәни Кәримнең аерым сүрәләрен уку һәм ятлау фазыйләтләре хакында да хәдисләр бик күп. Мәсәлән, гадәттә җомга көнендә укыла торган «әл-Кәһф» сүрәсенең фазыйләтләре турында хәдисләрдә болай дип әйтелә: «Кем дә кем «әл-Кәһф» сүрәсен җомга көнне укыса, ул ике җомга арасында аны нур белән яктыртыр»[1]. Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Кем дә кем «әл-Кәһф» сүрәсенең беренче ун аятен ятласа, Дәҗҗал фетнәсеннән сакланыр»[2]. Икенче бер хәдистә болай диелгән: «Кем дә кем «әл-Кәһф» сүрәсенең ахыргы ун аятен укыса, Дәҗҗалдан сакланыр»[3].

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Кем «әл-Бәкара» сүрәсен еш укып торса, Кыямәт көнендә бу сүрә ул кеше өчен болыт кебек булыр һәм гөнаһларыннан шәфәгать кылыр». Икенче бер хәдистә болай дип әйтелә: «Кем бу дөньяда бик еш «әл-Бәкара» һәм «Әли Гыймран» сүрәләрен укыса, алар ике болыт шикелле килер. Бу ике болытның araларында нур булыр һәм укыган кешегә шәфәгать кылырлар».

Коръән укуның төп максатын онытмыйк – ул аның мәгънәләренә карап фикерләү, Коръән белән гамәл кылу.

Мөхтәрәм җәмәгать! Аллаһы Раббыбыз һәрберебезгә дә Коръән әһелләреннән булырга насыйп итсен, Коръәнне безнең өчен җитәкче, нур, һидаять, рәхмәт итеп кылсын. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым!

---

[1] Имам әл-Хәким.

[2] Имам Мөслим.

[3] Имам Мөслим.

Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нурислам хәзрәт Кучкаров,*

*Казанның «Ярдәм» мәчетенең икенче имамы*

*6 март вәгазе,*

*Рамазан аеның 16 нчы көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Кадер кичәсенең фазыйләтләре

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрнең Раббысы булган, безне Үзенең төрле нигъмәтләре белән нигъмәтләгән Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед һәм сәналәр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләнең Хәбибе һәм хак Илчесе, галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәлам хәзрәтләренә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә сәламнәребез һәм салаватларыбыз булса иде.

Бөтен көннәрнең солтаны, ике гаеттән дә олуграк булган мөбарәк җомга көнне Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә ирешер өчен мәчетебезгә җыелган мөхтәрәм дин кардәшләрем, сезгә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ирешсә иде!

Шөкер, Аллаһы Тәгалә безгә бу Рамазан аен да исән-имин каршы алырга насыйп әйләде. Кемдер, бик бәхетле кешеләр, бу айда ураза тота алды. Шул ук вакытта дөнья буенча ничә кеше өчен бу ай килә алмады: гомерләре өзелде, һәм узган елгы Рамазан алар өчен соңгысы иде! Шуңа да ирешкән һәр көнебез өчен шөкер итсәк иде. Шуларның кадерен белер өчен, ә иң мөһиме – Раббыбыз бүләк иткән бер төндә дә бик күп савапларны кулдан ычкындырмау нияте белән, бүгенге вәгазебездә кыскача гына булса да Кадер киче турында сөйләшеп үтәрбез.

Беренчедән, Ислам галимнәренең барысы да диярлек әлеге төннең һәр елны һәм нәкъ менә Рамазан аенда булуы турында сөйләгәннәр. Икенчедән, Рамазанның кайсы кичәсенең Кадер кичәсе булачагы аның башлануына кадәр үк бары тик галәмнәрнең Хуҗасына гына төгәл билгеле.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләлаланһу галәйһи вә сәлләмнең Сөннәтендә бу бәрәкәтле кичәнең кайчан булырга мөмкин булуын күрсәтүче шактый күп хәдисләр бар. Мәсәлән:

– Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләлалаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кем Кадер кичендә (аның барлык әһәмиятләренә) ышанып һәм (Аллаһыдан гына) әҗерен өмет итеп намазын торгызса, аның элеккеге гөнаһлары гафу ителер».

– Хәзрәти Гобәдә бине әс-Самит риваять кылуы буенча, Пәйгамбәребез салләлалаһу галәйһи вә сәлләм Кадер кичәсе турында хәбәр итәр өчен (сәхабәләре янына) чыккан, ләкин бу вакытта ике мөселман үзара бәхәсләшә башлаганнар, һәм ул: «Мин сезгә Кадер кичәсе турында хәбәр итәр өчен чыккан идем, ләкин фәлән һәм фәлән бәхәсләштеләр, һәм мин бу белемнән мәхрүм ителдем. Бәлки бу сезнең өчен яхшырактыр. Шулай булгач, аны Рамазан ахырына кадәр тугыз, җиде һәм биш кичә калганда эзләгез!» – дип әйткән.

Шулай ук ул галәйһиссәлам мондый хәдисләр әйтеп калдырган:

– «Кадер кичен (дога кылып, намазда торып һәм изге гамәлләр кылып) Рамазан аеның соңгы ун төнендә эзләгез».

– «Кадер кичен Рамазан аеның соңгы ун көненең так төннәрендә эзләгез».

– «Кем Кадер кичен табарга теләсә, ул аны соңгы җиде төн эчендә эзләсен».

Шулай итеп, безнең өчен Кадер кичен эзли торган вакыт булып Рамазан аеның соңгы 10 көне тора. Инде бу төнне ниндидер билгеле бер дата дип түгел, барлык ункөнлек дип кабул итеп, әлеге төннәрне тырышып, гыйбадәттә үткәрергә насыйп булсын.

Кадер кичәсе нинди кич соң? Рамазан аенда гына була торган бөек кичә бар – Кадер киче, Ләйләтүл-Кадр. Бу кичәдә Аллаһыга гыйбадәт кылу, шулай ук теләсә нинди изге гамәл, хәтта иң гади, көндәлек булган эшләребез дә, мең ай дәвамында кылынган кебек булачак. Шуңа күрә бу кичә дәвамында (ә кайчан икәне төгәл билгеле булмагач, һәм 10 көн дәвамында) үзебезнең нинди гамәлләр кылганыбызга аеруча игътибар итәргә кирәктер. Раббыбыз Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә бу кичә турында болай дип әйткән:

إِنَّا أَنزَلْنَاهُ فِي لَيْلَةِ الْقَدْرِ ﴿١﴾ وَمَا أَدْرَاكَ مَا لَيْلَةُ الْقَدْرِ ﴿٢﴾ لَيْلَةُ الْقَدْرِ خَيْرٌ مِّنْ أَلْفِ شَهْرٍ ﴿٣﴾ تَنَزَّلُ الْمَلَائِكَةُ وَالرُّوحُ فِيهَا بِإِذْنِ رَبِّهِم مِّن كُلِّ أَمْرٍ ﴿٤﴾ سَلَامٌ هِيَ حَتَّىٰ مَطْلَعِ الْفَجْرِ ﴿٥﴾

> «**Һичшиксез, Без аны** [Коръәни Кәримне] **Кадер кичәсендә** [Ләүхел-Мәхфүздән тулы килеш беренче кат күккә] **иңдердек. Кадер кичәсенең нинди икәнен син каян белә аласың? Кадер кичәсе** [Кадер кичәсе булмаган] **мең айдан да хәерлерәк. Ул кичәдә, Раббыларының рөхсәте белән, фәрештәләр һәм Рух** [дип тә аталган Җәбраил галәйһиссәлам] **һәртөрле эш өчен иңәләр. Таң атканчы** [фәрештәләр очраткан һәр иманлы ир һәм хатынга сәлам биргәннәре өчен] **ул** [кичә] **иминлек** [булыр]**».**

«Әл-Кадр / Кадер киче», 97:1–5

Раббыбызның әлеге сүзләре безгә Коръәни Кәримнең Ләүхел-Мәхфүздән беренче күк дәрәҗәсенә нәкъ менә бу кичәдә иңдерелгән булуы турында сөйли. Шуңа күрә Рамазан аен икенче төрле «Коръән ае» дип тә йөртәләр. Шушы айда барыбыз да хатем чыгарга (Коръәнне тулысынча укып чыгарга) омтылабыз. Раббыбыз хатем кылучыларга сабырлык һәм рәхмәте белән тәмамлауны насыйп әйләсен.

«Әл-Кадр» сүрәсендә «Ләйләтүл-Кадр» сүзенең өч тапкыр кабатлануы очраклы түгел. Гарәп телендә мондый алым хөрмәт һәм әһәмиятлелекне белдерә. Шулай ук бу кичәдә җир йөзенә бик күп фәрештәләр төшәчәге дә искә алына. Шуңа күрә, мондый вакытта дога кылып торсак, догабызга күпме шаһит табачакбыз, Аллаһы бирсә.

**«Таң атканчы ул** [кичә] **иминлек** [булыр]**»** – бу төннең чикләренә килгәндә, җөп көнне ахшам намазы кергәч, так кичә, төн башланып китә, һәм шул төн иртәнге намазга кадәр дәвам итә. Төнне озын димик, онытмыйк: «Кем Кадер кичендә (аның барлык әһәмиятләренә) ышанып һәм (Аллаһыдан гына) әҗерен өмет итеп намазын торгызса, аның элеккеге гөнаһлары гафу ителер».

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә килгәндә, хәдисләрдә болай диелә: «Аллаһының Расүле Рамазан аеның соңгы ун кичәсендә намазларын тагын да озаграк укый иде (әлеге кичәне «җанландыра» иде), үз гаиләсен намазга уята иде, үзенә карата да (күп итеп игелекләр кылыр өчен) кырысрак була иде». Шуңа күрә дә безнең өчен зур бүләк булган әлеге кичәне кулдан ычкындыру зур хата булыр. Өстәмә намазлар укып, берничә бит булса да Коръән укып, бераз садака биреп куйсак, 80 елдан артык шушы гамәлләрне даими кылган кебек әҗерен алырбыз, иншәАллаһ.

Көн саен бу гамәлләр кылынып барылса, һәр киче Кадер кичәсе булмаса да, гомәмән, Рамазан аеның дәрәҗәсе зур булганга күрә, изгелекләрнең (һәм шулай ук гөнаһларның да) дәрәҗәләре арта, шулай булгач, безнең догаларыбыз әлеге мөбарәк Рамазан аеның бер кичәсендә кылынган булачак. Намазларыбыз – гади нәфел намазлары, садакаларыбыз – көндәлек бирә торган садакалар, догаларыбыз – без көн саен Раббыбыздан ялварып сораган догаларыбыз. Ниндидер аерым бу төннең генә гыйбадәте булмас.

Кадер кичәсендәге догага килгәндә, анабыз Гайшә радыяллаһу ганһәдән килгән хәдис буенча, Пәйгамбәребез салләлалаһу галәйһи вә сәлләм безгә түбәндәге доганы өйрәтеп калдырган:

اللَّهُمَّ إِنَّكَ عَفُوٌّ تُحِبُّ الْعَفْوَ فَاعْفُ عَنِّي

«Ий Аллаһым, дөреслектә, Син – Гафу итүче, гафу итәргә яратасың, минем гөнаһларымны гафу ит».

Шулай ук инде, әйткәнебезчә, үзебез көндәлек кыла торган догаларыбызны кабатларга кирәк: үзебез, гаиләбез өчен, эшләребездә тәүфыйк, бәрәкәт сорарга була. Аларын үзебезнең телдә, үзебез аңлый торган телдә кылу ярый.

Ел да вәгазьләребездә бу кичәнең үзенә генә хас гадәти булмаган билгеләре турында сөйләргә яратабыз, ә аннары, берәр төнне шундыйрак билгеләр күрсәк, Кадер киче үткәндер, дип йөрибез. Шуңа да хәзер андый билгеләр турында искә алмыйбыз, әйдәгез, Рамазанның калган һәр төнен Кадер кичәсе кебек үткәрик.

Нәсыйхәтебез азагында, әлеге төнгә хөрмәтебез тагы да артсын дигән ният белән, тагын берничә хәдис китерик: Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм сәхабәләренә борынгы заманаларда яшәп, 1000 ай буе Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылган Бәни Исраилдән булган бер кеше турында сөйләгән. Моны ишеткәч, сәхабәләр бик борчылганнар, чөнки, үзләренең тырышлыкларына карамастан, яшьләре аркасында мондый дәрәҗәгә ирешә алмаячакларын аңлаганнар. Шуннан соң Аллаһы Тәгалә Кадер кичәсенең бөеклеген аңлата торган сүрәне иңдергән. Һәм аннан бу кичәдә кылынган гыйбадәтнең әҗере 80 ел дәвамында өзлексез гыйбадәт кылудан да күбрәк икәне аңлашыла...

Аллаһының Расүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кадер кичәсендә Җәбраил фәрештә галәйһиссәлам башка фәрештәләр төркеме белән җиргә иңә. Һәм алар бу кичәдә Аллаһыга гыйбадәт кылучы һәрбер Аллаһы колы өчен дога кылалар. Ә Ураза бәйрәме көнендә Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә болай дип әйтер: «Ий фәрештәләрем, эшен яхшы башкарган кешегә нинди әҗер тиеш?» Алар әйтерләр: «Ий Раббыбыз, андый кешегә

тулы әҗер бирелергә тиеш». Шуннан соң Аллаһы әйтер: «Ий фәрештәләрем, дөреслектә, Минем колларым, ирләр һәм хатыннар, ураза тоту бурычларын тиешенчә үтәделәр һәм бәйрәмгә (гаеткә) килделәр, һәм Миңа дога кылдылар. Һәм Мин ант итәмен, Мин бу кешеләрнең догаларына һичшиксез җавап бирәчәкмен», – дип. Аннан соң Аллаһы Тәгалә: «Барыгыз, Мин сезнең гөнаһларыгызны гафу иттем, һәм сезнең начар гамәлләрегезне яхшыларына алыштырдым», – дип кешеләргә мөрәҗәгать итәр. Һәм бу кешеләр бәйрәмнән Аллаһы тарафыннан гафу ителгән хәлдә кайтырлар».

Газиз дин кардәшләрем, шулай ук Рамазан аеның тагын бер бүләге булган гыйбадәт – игътикяф – турында да искә алып үтү кирәк. Чөнки ул Рамазанның соңгы 10 көнендә кылына торган сөннәт гамәл. Игътикяф гыйбадәт кылу өчен мәчеттә өзлексез булу дигәнне аңлата. Игътикяфнең тирән дини мәгънәсе бар: кеше, көннәрен вә төннәрен Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәттә һәм Аны искә алуда (зикердә) булу өчен, дөнья мәшәкатьләре, гаиләсеннән ялгыз кала. Ир-атлар мәчеттә игътикяфтә булсалар, хатын-кызлар исә аны мәчетләрдә түгел, ә үз йортларында, намаз укый торган урыннарында үти алалар.

«Әл-Һәдийә әл-Әләийә» китабында (184 б.) болай диелә: «Әз-Заһиди яза: «Кешенең игътикяфне калдыруы гаҗәп. Аллаһы Расүле кайбер нәрсәләрне эшләде, соңыннан ташлады. Әмма ул, Мәдинәгә күчкәннән алып үлгәнчегә кадәр, игътикяфне беркайчан да калдырмады».

Әлеге гамәл турында, иншәАллаһ, тәравих намазларын укыганда, кичләрен күбрәк сөйләшербез.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм, Рамазанның ункөнлекләре турында сөйләп, соңгы көннәр турында болай дигән: «Рамазанның ахыргы 10 көне – ул җәһәннәм газабыннан котылу көннәре». Шушы көннәрдә уттан котылырга, барыбызга да Кадер кичләрен гыйбадәттә уздырып, аның бәрәкәтләренә ирешергә насыйп булсын! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДНнең Дәгъват бүлеге*

*13 март вәгазе,*

*Рамазан аеның 23 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Дин – лотерея түгел

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Безгә бердәнбер дөрес дин иңдергән, ялганнардан тыеп, акыл белән хәрәкәт итәргә өндәгән Раббыбызга дан, мәдхияләребез булса иде. Күңел түрләребездән чыккан изге догаларыбыз безгә туры юлны аңлаткан, ачыклаган, иң күркәм әхлакны бәян итеп күрсәткән сөекле расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсенә, барча сәхабәләренә һәм аның чакыруына җавап биреп, аңа ияргән һәркемгә ирешсә иде.

Динебез безне дөрес сүзле булырга чакыра һәм моны чынга ашыру юлын да күрсәтә: тәкъва булу һәм дөрес сүзле кешеләр арасында булу. Раббыбыз болай дип әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَكُونُوا مَعَ الصَّادِقِينَ ﴿١١٩﴾

> **«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм** [иманда, вәгъдәгә тугры калуда, тән һәм рух белән үзе һәм сүзе] **тугры кешеләр белән бергә булыгыз».**

«Әт-Тәүбә», 9:119

Бу аятьтә дөрес сүзле булу өчен ике шарт искә алына: Аллаһыдан чын мәгънәсендә курку, Аның каршында һәр әйткән сүзебез, эшләгән эшебез өчен җавап бирәчәгебезне аңлау; һәм икенче шарт – тирә-якта ялган булмавы,

ә дөрес сүзле, изге кешеләрнең булуы. Әгәр дә бу шартлар үтәлсә, кешенең ялган сөйләвен күз алдына китерү бик кыен булыр иде.

Хәдисләрдә дөрес сүзле булу – җәннәткә илтә, ә ялган җәһәннәмгә китерә, дип әйтелә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Ялганнан бик нык сакланыгыз! Чынлыкта, ялган гөнаһларга илтә. Ә инде гөнаһлар исә утка алып бара. Чынлыкта, кеше (еш) ялганласа, Аллаһы каршында ялганчылардан булып языла. Дөрес сүзле булыгыз, чынлыкта, дөреслек яхшылыкка илтә. Ә инде яхшылыклар җәннәткә китерә. Кеше хак сүзләр генә сөйләве белән Аллаһы каршында тугрылардан булып языла»[1].

Дөрес сүзле булу безнең бөтен калган гамәлләребезгә дә яхшы яктан тәэсир итеп, аларны төзекләндерә. Аллаһы Тәгалә «әл-Әхзәб» сүрәсендә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اتَّقُوا اللَّهَ وَقُولُوا قَوْلًا سَدِيدًا ﴿٧٠﴾ يُصْلِحْ لَكُمْ أَعْمَالَكُمْ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ

**«Ий иман китерүчеләр! Аллаһыдан куркыгыз һәм туры сүз сөйләгез. Шулвакыт Ул** [Раббыгыз] **сезнең гамәлләрегезне төзәтер һәм гөнаһларыгызны кичерер».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:70-71

Раббыбыз нәкъ менә туры, ялган булмаган сүз сөйләвебез сәбәпле, безнең тормышыбыздагы гамәлләребезне тәртипкә китерергә, әле шуның өстенә гөнаһларыбызны да гафу итәргә вәгъдә бирә.

Ялганнан кисәтеп, хәдисләренең берсендә расүлебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйтә: «Кемдә шушы дүрт сыйфат булса, ул чын монафикъ (икейөзле) булыр: 1) берәр сүз сөйләсә, ялганлый; 2) вәгъдә бирсә, вәгъдәсендә тормый; 3) аңа әманәт бирелсә, әманәтенә хыянәт кыла; 4) бер низаг чыкса, сүгенә башлый»[2].

[1] «Мөснәд» Имам Әхмәд, № 4108, «Сүнән» Әбү Давыд, № 4989.

[2] «Сахих» әл-Бохари, № 3178.

Игътибар итик – иң беренче итеп ялган искә алына. Шул сәбәпле, ялган сөйләү – динебез буенча иң катгый тыелган гамәлләрнең берсе. Бу дөньяви эшләргә карата булганда да иң олы гөнаһларның берсе булып санала, ә динебезгә берәр ялган кертергә тырышканга яки, тикшермичә, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтмәгән сүзне аңа нисбәт итсә, моның гөнаһы нинди булыр икән? Моның хакында бер мөбарәк хәдистә әйтелә: «Кем ялган булып исәпләнгән бер хәдисне минем (Мөхәммәд галәйһиссәлам) исемемнән сөйләсә, шул ялганчыларның берсе»[1].

Җәмәгать, игътибар итегез: ниятнең нинди булуының – изгеме, начармы – аермасы юк. Андый кеше ялгышлык белән уйлап чыгарылган сүзне хәдис буларак җиткерсә, ялганчы булып санала. Башка бер хәдистә исә болай диелә: «Кем минем исемемнән ялган сөйләсә, үзенә тәмугта урын әзерләсен»[2].

Һәрбер ишеткән нәрсәне сөйләү, аның белән уртаклашу кешене ялганга китерә. Бер хәдисендә Расүлебез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Кешегә ялганчы булу өчен һәр ишеткән нәрсәне сөйләп йөрүе җитә»[3].

Һәр ишеткән, аңлаган яки матур булып тоелган нәрсәне башкаларга сөйләргә ярамый. Тикшерергә кирәк. Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِن جَاءَكُمْ فَاسِقٌ بِنَبَإٍ فَتَبَيَّنُوا

**«Ий иман китерүчеләр! Әгәр фасикъ бер кеше сезгә хәбәр китерсә,** [аның асылын] **тикшереп белегез...»**

«Әл-Хуҗурат / Бүлмәләр», 49:6

Бу аятьтә мөһим нәрсәгә ишарә дә бар: дөрес сүз ышанычлы урыннан гына алына. Кызганыч, бүгенге көндә күпчелек кешеләр бик ышанычлы түгел.

1 «Сахих» Имам Мөслим.

2 «Сахих» әл-Бохари, № 107.

3 «Сахих» Имам Мөслим, № 5.

Шул сәбәпле бездән мәгълүматны берничә чыганактан тикшерү таләп ителә. Шуны да әйтеп узарга кирәк: әйтелгән сүздән язып калдырылган сүзләр күпкә хәтәррәк. Чөнки язып куелган сүз мәңгегә кала, аны күп кешеләр укып, ялгыш гамәлләр эшләргә мөмкиннәр.

Халкыбыз арасында таралган, әмма асылы булмаган ялган хәдисләргә мисал итеп кайберләрен искә алып узыйк: «Фәлән төндә укылган бер намаз бөтен каза намазларын каплый»; «Фәлән дога укысаң, җәннәткә керәсең». Бу сүзләр дингә күз алдына китерә алмаслык зыян китерә, чөнки алар Исламны гадәти лотерея кебек итеп күрсәтә: имеш, бер «җиңүче билет» табып, бөтен гөнаһлардан котылып була. Әмма дин лотерея түгел – ул көндәлек хезмәт, гыйбадәт, сабырлык һәм тырышлык.

Бу нигезсез «хәдис»ләрнең кайбер афәтләрен искә алып узыйк:

1. Бер намаз белән бөтен намазларны каза кылу мөмкин түгел. Моны Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә, бер галим дә беркайчан да әйтмәгән. Көн саен биш вакыт намазны вакытында укып барган кеше белән гомерендә бер тапкыр намаз укыган кеше бер дәрәҗәдә була аламы?

2. Бу ялган хәдис, кешеләрне намаз укудан ерагайту өчен, динсезләр тарафыннан уйлап чыгарылган хәдисләргә охшаган. Чөнки бу сүзне ишеткән гыйлемсез кеше: «Менә, вафат булганчы бу бер намазны укырмын да, өстемнән җаваплылыкны төшерермен», – дип хыяллана. Ә кайчан үләчәген беркем белми! Гыйбадәтне һәм гомумән хәтта дөньяви эшләрне дә кичектергән, калдырган кешенең эшләренең берсен дә башкармавын яхшы беләбез.

Җәмәгать, белегез, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте, мәрхәмәте иксез-чиксез. Ул бер намаз өчен дә санап бетергесез әҗер-савап бирә ала, монда шигебез юк. Әмма безгә җиңел юл эзләү түгел, ә дөрес юл белән бару мөһимрәк. Аллаһы Тәгалә әйтә:

وَأَن لَّيْسَ لِلْإِنسَانِ إِلَّا مَا سَعَىٰ ﴿٣٩﴾

**«Кешегә бары тик үз тырышлыгы белән (кәсеп иткәне) булачак».**

«Ән-Нәҗм / Йолдыз», 53:39

Димәк, бер төндә, бер дога белән бөтен гөнаһлардан котылу мөмкин түгел. Ә менә һәр көнне намаз уку, изгелек кылу, гөнаһлардан саклану – әнә шул чын юл, хак юл.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Аллаһыга иң сөекле гамәл – даими эшләнгән гамәл, хәтта аз булса да».[1] Димәк, Аллаһы каршында кыйммәтле булган гамәл – даими, ихлас һәм сабырлык белән эшләнгән гамәл.

Хөрмәтле җәмәгать! Дин – акыл, гыйлем, тырышлык юлы. Ул «бер дога укыдым да, хәзер җәннәтле булдым» дигән уен түгел. Безнең максат – чын гыйлем белән, тикшереп, хак хәдисләргә таянып, гыйбадәт кылу. Шуңа күрә, бер сүз ишетсәк, аның чыганагын сорарга өйрәник. Халыкка таратабыз икән, тикшерик. Чөнки Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм исеменнән ялган сүз әйтсәк, үзебезгә зарар китерәбез.

Аллаһы Тәгалә барчабызга да дөрес сүзле генә, изге колларыннан булырга насыйп итсен! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Нурислам хәзрәт Вәлиулла,*
*Биектау районының «Карадениз» мәчете имам-хатыйбы*

[1] «Сахих» әл-Бохари, № 6464. «Сахих» Мөслим, № 783.

# Ураза гаете хотбәсенең гарәпчә укылышы

خطبة عيد رمضان

بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ

اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ نَوَّرَ قُلُوبَ الْعَارِفِينَ بِنُورِ الْمَعْرِفَةِ وَالْإِيمَانِ وَشَرَحَ صُدُورَ الصَّادِقِينَ بِشَرْحِ الْهِدَايَةِ وَالْعِرْفَانِ وَأَكْرَمَ عِبَادَهُ الْمُؤْمِنِينَ بِصِيَامِ شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ سُبْحَانَ مَنْ فَتَحَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ الرَّحْمَةِ وَالْغُفْرَانِ وَزَيَّنَ قُلُوبَ الْمُحِبِّينَ بِتِلاَوَةِ الْقُرْآنِ وَغَلَّقَ عَلَى الصَّائِمِينَ أَبْوَابَ النِّيرَانِ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ۞ وَعَدَ لِلصَّائِمِينَ دُخُولَ بَابٍ مِنْ أَبْوَابِ الْجِنَانِ كَمَا أَخْبَرَنَا نَبِيُّنَا نَبِيُّ آخِرِ الزَّمَانِ: إِنَّ لِلْجَنَّةِ بَابًا يُقَالُ لَهُ الرَّيَّانُ لاَ يَدْخُلُهُ إِلَّا الصَّائِمُونَ فِي شَهْرِ رَمَضَانَ ، شَهْرُ رَمَضَانَ الَّذِي أُنْزِلَ فِيهِ الْقُرْآنُ هُدًى لِّلنَّاسِ وَبَيِّنَاتٍ مِّنَ الْهُدَىٰ وَالْفُرْقَانِ ۞ اَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ لَا إِلَهَ إِلَّا اَللَّهُ وَاَللَّهُ أَكْبَرُ اَللَّهُ أَكْبَرُ وَلِلَّهِ الْحَمْدُ ۞ وَأَشْهَدُ أَنْ لَا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ ذُوالْعَفْوِ وَالْغُفْرَانِ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ شَهَادَةً نَاطِقَةً بِالْحُجَّةِ وَالْبُرْهَانِ صَلَّى اللَّهُ تَعَالَى عَلَيْهِ وَعَلَى آلِهِ وَأَصْحَابِهِ صَلاَةً مُوصِلَةً إِلَى دَارِ الْجِنَانِ خُصُوصًا مِنْهُمْ عَلَى أَبِي بَكْرٍ الصِّدِّيقِ وَ عُمَرَ الْفَارُوقِ وَ عُثْمَانَ ذِي النُّورَيْنِ وَ عَلِيٍّ الْمُرْتَضَى الْأَئِمَّةِ رِضْوَانَ اللهِ عَلَيْهِمْ أَجْمَعِينَ ۞

أَمَّا بَعْدُ: أَيُّهَا النَّاسُ، أُوصِيكُمْ عِبَادَ اللهِ وَنَفْسِي أَوَّلاً بِتَقْوَى اللهِ ۞ أَعُوذُ بِاللهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ، بِسْمِ اللهِ الرَّحْمَنِ الرَّحِيمِ ۞ إِنَّ اللَّهَ مَعَ الَّذِينَ اتَّقَوا وَّالَّذِينَ هُم مُّحْسِنُونَ ۞ بَارَكَ اللهُ لَنَا وَلَكُمْ فِي الْقُرآنِ الْعَظِيمِ وَنَفَعَنَا وَإِيَّاكُمْ بِالْآيَاتِ وَالذِّكْرِ الْحَكِيمِ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ الْجَوَادُ الْكَرِيمُ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ السَّمِيعُ الدُّعَاءِ

## خطبة ثانية

إِنَّ الْحَمْدَ لِلَّهِ نَحْمَدُهُ وَنَسْتَعِينُهُ وَنَسْتَغْفِرُهُ وَنُؤْمِنُ بِهِ وَنَتَوَكَّلُ عَلَيْهِ وَنَعُوذَ بِاللَّهِ مِنْ شُرُورِ أَنْفُسِنَا وَمِنْ سَيِّئَاتِ أَعْمَالِنَا مَنْ يَهْدِهِ اللهُ فَلاَ مُضِلَّ لَهُ وَمَنْ يُضْلِلْهُ فَلاَ هَادِيَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لا شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ ۞ إِنَّ اللَّهَ وَمَلَائِكَتَهُ يُصَلُّونَ عَلَى النَّبِيِّ يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا صَلُّوا عَلَيْهِ وَسَلِّمُوا تَسْلِيمًا اَللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَيْهِ عَلَى جَمِيعِ الْأَنْبِيَاءِ وَالْمُرْسَلِينَ وَعَلَى مَلَائِكَتِكَ الْمُقَرَّبِينَ وَعَلَى عِبَادِكَ الصَّالِحِينَ وَعَلَى أَهْلِ طَاعَتِكَ أَجْمَعِينَ مِنْ أَهْلِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرَضِينَ ۞ اَللَّهُمَّ اغْفِرْ لِلْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ اَلْأَحْيَاءِ مِنْهُمْ وَالْأَمْوَاتِ وَارْحَمْنَا مَعَهُمْ وَاحْشُرْنَا مَعَهُمْ بِرَحْمَتِكَ يَا أَرْحَمَ الرَّاحِمِينَ ۞

# Ураза гаете хотбәсенең кириллицага транслитерациясе

## Беренче хотбә

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим

Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмде. Сүбхәәнә мән нәввәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти вәл-иимәән, вә шәрахә судүүрас-саадикыйнә би шәрхил-һидәәйәти вәл-гыйрфәән, вә әкрамә гыйбәәдәһүл-мү’миниинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Сүбхәәнә мән фәтәхә галәс-саа’имиинә әбүәәбәр-рахмәти вәл-гуфраан, вә зәййәнә кулүүбәл мүхиббәйни битиләәвәтил Куръәни, вә галләка галәс-саа’имиинә әбүәәбән-нииραани фи шәһри рамәдаан. Вәгадә лис-саа’имиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбииййүнәә нәбииййү әәхириз-зәмәән: иннә лил-җәннәти бәәбән йүкаалү ләһүр-раййәән. Ләә йәдхулүүһү илләс-саа’имүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһрү рамәдаанәлләзии үнзилә фииһил-Куръәәнү һүдәл-линнәәси вә бәййинәәтин минәл һүдәә вәл-фүркаан, Аллаһу әкбәрү, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу вәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, вә лилләәһил-хәмд. Вә әшһәдү әлләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһуу з̧үл-гафьүи вәл-гуфраан, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһуу. Шәһәәдәтән нәәтыйкатән билхүҗҗәти вәл бүрһәәни. Салләллааһу Тәгаалә галәйһи вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән. Хусуусан минһүм галәә Әби Бәкринис-Сыйддикый вә Гуммәрал-Фәәрукый вә Гус̧мәәнәз-з̧иннүрайни вә Галийинил-Мүртәдал ә-иммәти, ридъвәәналлааһи галәйһим әҗмәгыийнә.

Әммә бәгъде: әййүһәннәәс, үсыйкүм гыйбәәдәллааһи вә нәфсии әүвәлән-битәкъүәллааһ. Әгуууз̧у билләәһи минәш шәйтаанир-раҗиим,

бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгалләẓиинәт-тәкау вәлләẓиинә һүм мүхсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә вә ләкүм фил-куръәәнил-гаẓыйим, вә нәфәганәә вә ийййәәкүм бил-әәйәәти үәẓẓикрил-хәкиим, иннәһуу һүәл-гафуурур-рахиимүл-җәүәәдүл-кәриимүл-галийййүл-гаẓыйимү сәмиигуд-дүгаа'.

## Икенче хотбә

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһуу вә нәстәгыйнүһу вә нәстәгъфируһу вә ну'минү биһии вә нәтәүәккәлү галәйһи вә нәгуузү билләәһи мин шүруури әнфүсинәә вә мин сәййиәәти әгъмәәлинәә мән йәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү вә мән йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Вә әшһәдүән ләә иләәһә илләллаһу вәхдәһуу ләә шәриикә ләһ, вә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһуу вә расүүлүһ. Иннәллааһә вә мәләә-икәтүһү йүсаллүүнә галәннәбиййи. Йәә әййүһәл-ләẓиинә әәмәнүү саллү галәйһи вә сәллимүү тәслиимәә. Аллаһүммә салли вә сәллим галәйһи вә галәә җәмигыйль-әнбийәә'и вәл-мүрсәлиин, вә галәә мәләә'икәтикәл-мүкаррабиин. Вә галәә гыйбәәдикәс-саалихыйн, вә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйн, мин әһлис-сәмәүәәти үәл-арадыйн. Аллаһуммә-гъфир лилмү'миниинә вәл-мү'минәәт, вәл-мүслимиинә, вәл-мүслимәәт, әл-әхъйәәи минһүм вәл-әмъүәәт, вәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәәмәр-раахимиин.

# Ураза гаете хотбәсенең татарчага тәрҗемәсе

## Беренче хотбә

Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы Тәгалә исеме белән.

Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыга гына мактау. Аллаһы Тәгаләгә якынаючыларның (гарифләрнең) күңелләрен (калебләрен) мәгъфирәт (ярлыкау) һәм иман нуры белән нурландырган, тугрыларның (садыйкларның) күңелләрен һидаять һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына Рамазан ае уразасын бүләк иткән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт (гөнаһларны гафу итү) ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән Зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул (Аллаһы Тәгалә) ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез, ахырзаман пәйгамбәре, хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр, аңа «Райян» диелә. Ул ишектән Рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Рамазан ае кешеләргә туры юл күрсәтә, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллаһы бөек! Аллаһы бөек! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу Итүче һәм мәгъфирәт Иясе (гөнаһларны каплаучы) икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд – Аның колы һәм расүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сәхабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһы Тәгаләнең коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм.

Ташлар белән кыйналып, Аллаһының рәхмәтеннән сөрелгән шайтаннан Аллаһы Тәгаләгә сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы Тәгалә тәкъвалар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы Тәгалә безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта, Ул (Аллаһы Тәгалә) – гафу Итүче, Рәхимле, юмартлык Иясе, олуглык Иясе, бөек Зат һәм догаларны Ишетүче, кабул Итүче.

## Икенче хотбә

Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһы Тәгаләгә, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһы Тәгаләгә үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы Тәгалә һидаять бирсә – аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса – аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһы Тәгаләдән башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук Мөхәммәд – Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә – күк әһелләреннән һәм җир әһелләреннән булганнарының барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит. Йә рәхимлеләрнең иң Рәхимлесе.

*20 март вәгазе,*

*шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Ураза гаете вәгазе

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Газиз дин кардәшләрем, барыгызны да бар мөселман өммәте өчен бөек бәйрәмнәребезнең берсе – Ураза гаете (Гыйд әл-фитр) – белән тәбриклим! Көтеп алган гаетебез җир шарында яшәгән бар мөселманнарны берләштерә, һәм бу аның төп сыйфатларының берсе булып тора. Бу бәйрәмгә барчабыз бик сөенә, гаиләләр бергә табын артында җыела, сәфәрдә булучылар якыннары янына кайтып җитергә ашыга, эштәгеләр, эшләрен тәмамлап, гаеткә өлгерергә тырыша.

Беренчедән, бүген без бәйрәм (гает) намазын укырбыз. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм беренче тапкыр аны һиҗри икенче елда укыган һәм бер тапкыр да калдырмаган. Бу намаз вәҗиб булып тора.

Хәзрәти Габдуллаһ бине Габбас радыяллаһу ганһе тапшырган хәдистә болай диелә: «Ураза гаетенең иртәсе җиткәч, Аллаһы Тәгалә бар шәһәрләргә фәрештәләрен җибәрә. Алар, базар капкаларына урнашып, җеннәр һәм кешеләрдән кала бар мәхлуклар ишетә торган тавыш белән: «Ий Мөхәммәд өммәте! Зур әҗерләр бирүче һәм олы гөнаһларны ярлыкаучы Рәхимле Раббыгыз хозурына чыгыгыз!» – дип чакыра башлыйлар. Һәм кешеләр гает намазы укылачак урынга җыелгач, Аллаһы Тәгалә фәрештәләргә: «Эшен тәмамлаганнан соң, эшчегә нинди хак (әҗер) бирелә?» – дип мөрәҗәгать итә. Фәрештәләр: «Раббыбыз, аның хакы – Синең аңа тулы рәвештә әҗерен

бирүең», – диләр. Аллаһы әйтә: «Фәрештәләрем, шаһит булыгыз: Рамазан аенда тоткан уразалары һәм төнге намазлары өчен әҗер буларак Үземнең ризалыгымны һәм ярлыкавымны бирәмен!»

«Ураза бәйрәме» дигәндә, без аның башка, гади бәйрәмнәр кебек узмавын аңларга тиешбез. Ягъни башка бәйрәмнәрдә кешеләр гадәттә ял итә, ә без исә гает көнендә Аллаһыдан уразаларыбызның, изге гамәлләребезнең кабул булуын, җәһәннәм утыннан коткаруын сорап, догаларыбызны арттырырга тиешбез. Рамазан аенда Аллаһы Тәгалә һәр сәгатьтә 600 мең колын җәһәннәм утыннан азат итә, гәрчә алар бу җәзага лаек булса да. Кадер кичәсендә Аллаһы Тәгалә бар Рамазан аенда көн саен азат иткән кадәр колын азат итә. Ә Ураза гаетендә Аллаһы Тәгалә Рамазанның һәр көнендә һәм Кадер кичәсендә азат ителгән бар кешеләр санынча колларын азат итә.

Һәм сер түгел, нәкъ шушы мөбарәк көнне кайбер кешеләр, нәфесләренә бирешеп, артык күп ашыйлар, өстәмә гыйбадәтләре турында оныталар, намазларын кичектерәләр. Болар барысы да бер ай дәвамында богаулап тотылып, ниһаять иреккә чыккан шайтанның вәсвәсәләре.

Мәшһүр табигыйн Вәһб бине Мөнәббиһ рахмәтуллаһи галәйһи тапшырган: «Һәр гает саен иң зур иблис үзенә буйсынган шайтаннарны җыя. Алар: «Хуҗабыз, син ник ачулы?» – дип сорыйлар. Ул: «Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд өммәтен ярлыкады. Әмма без аларны ләззәтләргә һәм теләкләрен канәгатьләндерүгә юнәлтергә тиешбез», – дип әйтә».

Дин кардәшләрем, иблис өчен бер уенчык булмыйк! Бу көнне күп итеп зикер-тәсбихләр укырга киңәш ителә. Шулай ук дин кардәшләребезгә фитр садакасы турында искә төшерү киңәш ителә. Әгәр кемдер әле фитр түләмәгән булса, ашыксын. Хәдистә хәбәр ителгәнчә, хәзрәти Госман радыяллаһу ганһе бер тапкыр фитр садакасын вакытында бирергә оныткан, һәм аны гает намазыннан соң түләп, бер колын да азат иткән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янына барып: «Ий Расүлуллаһ, мин фитрны вакытында бирергә онытканмын, әмма шуның өчен бер колымны азат иттем», – дигән.

Ә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Хәтта бер мең кол азат итсәң дә, инде ычкындырган әҗер-савапны кайтара алмаячаксың», – дип җавап кайтарган.

Фитр садакасында яшерелгән хикмәтләрнең берсе шундадыр – ул ураза тотканда җибәргән кечкенә хата-кимчелекләрнең ярлыкануына, уразабызның кабул булуына сәбәп булып тора. Хәдистә болай диелгән: «Рамазан уразасы җир белән күк арасында эленеп торыр, һәм фитр садакасы түләнгәч кенә, ул күтәрелер».

Газиз дин кардәшләрем, бу көнне без мохтаҗ кардәшләребезне аеруча сөендерергә тырышырга тиешбез. Фитр гына түгел, аларга өстәмә садакалар бирик, күбрәк ярдәм итик.

Шулай ук бүген туганнарыбыз, якыннарыбыз белән күрешеп, бер-беребезне шушы бөек бәйрәм белән котлау күркәм булыр. Беркем дә кардәшләренә ачу, үпкә сакларга тиеш түгел. Әгәр арагызда аңлашылмаучанлыклар бар икән, бүгенге гает көне моны төзәтү өчен иң яхшы форсат. Беренче адым ясап, арада бәхәс, үпкә булган кешегезнең хәлен белешегез. Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы һәм ләгънәт кылынган шайтанга ачу итеп, бер-берегезгә кул сузыгыз. Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Үзе хаклы була торып та, бәхәсне калдырырга карар кылган кешегә җәннәттә йорт салыныр». Әбү Давыд рахмәтуллаһи галәйһи моңа охшаш хәдисне китерә: «Үзе хаклы булуына карамастан бәхәсне калдырган кешегә җәннәтнең тирә-ягында йорт вәгъдә ителгән. Һәм хәтта шаяртып кына да ялган сүз сөйләмәгән кешегә җәннәтнең уртасында йорт вәгъдә ителгән. Һәм әдәпле, югары әхлаклы кешегә җәннәтнең югары катларында йорт вәгъдә ителгән».

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бигрәк тә бүген туганнарыбызны игътибарсыз калдырмыйк. Кайбер бик якын туганнар да, еллар буе аралашмыйча, берәр кайгылы хәбәр килсә генә шалтыратыша. Әмма Раббыбыз, тормышта нинди генә хәлләр булуына карамастан, безгә туганлык җепләрен сакларга әмер итте:

وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالْأَرْحَامَ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا

**«Аның исеме белән бер-берегездән үтенә торган Аллаһыдан һәм туганлык җепләреннән** [аларның өзелүеннән] **куркыгыз. Һичшиксез, Аллаһы – сезне күзәтүче».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:1

Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый сүзләрен тапшыра: «Аллаһы Тәгаләгә һәм Кыямәт көненә иман китерүче туганлык җепләрен сакласын». Туганнар белән күркәм, гадел мөнәсәбәтләр булдыру һәм саклау, кешеләр белән дус-кардәш булу югары әхлакка ия булуның бер нәтиҗәсе булып санала. Шуңа күрә дә күркәм әхлакны һәм холыкны мактый торган күп кенә аятьләр, хәдисләр таба алабыз. Мәсәлән, бер хәдистә болай дип әйтелә: «Күбрәк кешеләр күркәм әхлак һәм тәкъвалыклары нәтиҗәсендә җәннәткә ирешә».

Дин кардәшеңне яратуның кыйммәтен һәм моның өчен вәгъдә ителгән әҗер-савапларны санап бетерү мөмкин түгел. «Бу дөньяда Аллаһы ризалыгы өчен бер-берсен кардәш буларак яраткан кешеләр Кыямәт көнендә Гарешнең күләгәсендә булырлар», – диелә хәдистә.

Хөрмәтле дин кардәшләрем, шулай ук шәүвәл аенда 6 көн ураза тотарга ниятлик. Бу шәүвәл ае уразасы – өстәмә ураза һәм Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте, аны үтәүчегә бихисап әҗер-саваплар бирелә. Хәзрәти Әбү Әюб әл-Әнсари радыяллаһу ганһе Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мондый хәдисен тапшыра: «Рамазан аенда ураза тотып, шуңа шәүвәл аенда 6 көн өстәгән кешенең уразасы бер ел дәвамында өзлексез ураза тотуга тиң».

Шәүвәл уразасын кайсы көннәрдә тотарга соң? Шәүвәлнең беренче көненнән кала, бу алты көнне айның теләсә кайсы көнендә тотарга ярый. Шәүвәлнең беренче көне Ураза гаетенә туры килә, бу бәйрәм көнне, ягъни бүген, ураза тотарга ярамый. Бу уразаны 6 көн рәттән тотарга да, тоташтан

тотмаска да мөмкин. Иң мөһиме – кешенең шәүвәл уразасын тотарга нияте булуы, һәм ураза көннәренең саны алтыга тулуы.

Газиз кардәшләрем, Рамазан ае узгач, элеккеге чорда яшәүче мөселман кардәшләребез ярты ел дәвамында Аллаһы Тәгалә уразабызны, изге гамәлләребезне кабул итәрме икән, дип борчылганнар. Һәм гыйбадәтләрен тагын да арттырырга тырышканнар. Ә елның калган яртысын киләсе Рамазанга әзерләнеп үткәргәннәр. Кардәшләрем, без дә гафил, ваемсыз булмыйк, Аллаһы Тәгалә турында Рамазанда гына искә төшерүчеләрдән булмыйк!

Аллаһы Тәгалә тоткан уразаларыбызны, зәкятләребезне, барча изге гамәлләребезне кабул кылсын! Раббыбыз киләсе Рамазан айларына исән-сау ирешеп, бу изге айдан файда һәм бәрәкәт алырга насыйп итсен! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*ТР МДН Дәгъват бүлеге*

*20 март вәгазе,*

*шәүвәл аеның 1 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Пәйгамбәребезнең 10 сөннәте

Әгуузү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барлык галәмнәрне юктан бар кылып, шунда булган мәхлукларны тәрбия кылучы, Кыямәт көненең Хуҗасы Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә барлык мактау-олуглауларыбыз булса иде. Безгә Коръәни Кәрим белән гамәл кылырга өйрәткән пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның әһле бәйтенә, барча сәхабәләренә һәм дә аларга Кыямәт көненәчә изгелектә иярүчеләргә дә чын күңелдән чыккан дога-сәламнәребез, туктаусыз салават-шәрифләребез булса иде.

Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә болай ди:

لَّقَدْ كَانَ لَكُمْ فِي رَسُولِ اللَّهِ أُسْوَةٌ حَسَنَةٌ لِّمَن كَانَ يَرْجُو اللَّهَ وَالْيَوْمَ الْآخِرَ وَذَكَرَ اللَّهَ كَثِيرًا ﴿٢١﴾

«**Сезнең өчен** [бигрәк тә] **Аллаһыга һәм Соңгы көнгә өмет баглаган һәм** [курку, теләү, муллык һәм тарлык кебек бөтен хәлләрендә] **Аллаһыны күп итеп искә алган кешеләр өчен Аллаһының Расүлендә салләллаһу галәйһи вә сәлләм күркәм үрнәк бар».**

«Әл-Әхзәб / Гаскәрләр», 33:21

قُلْ إِن كُنتُمْ تُحِبُّونَ اللَّهَ فَاتَّبِعُونِي يُحْبِبْكُمُ اللَّهُ وَيَغْفِرْ لَكُمْ ذُنُوبَكُمْ ۗ وَاللَّهُ غَفُورٌ رَّحِيمٌ ﴿٣١﴾

«[Расүлем!] **Әйт: «Әгәр сез Аллаһыны сөясез икән, миңа иярегез, шулвакыт Аллаһы да сезне сөячәк һәм гөнаһларыгызны гафу итәчәк. Аллаһы –** [гөнаһларны күпләп] **Гафу итүче, Рәхимле».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:31

Алда искә алынган аятьләрдән аңлашылганча, әгәр дә без ике дөнья бәхетенә ирешергә теләсәк, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә буйсынырга һәм иярергә тиешбез. Аны гыйбадәтләребездә генә түгел, көндәлек тормышыбызда да үзебезгә күркәм үрнәк итеп алырга кирәк.

Газиз дин кардәшләрем, бүген көн дәвамында башкарырга мөмкин һәм кирәк булган кайбер сөннәтләрне искә төшереп китәрбез. Кеше боларны тормышка ашырса, файдасы үзенә кайтыр һәм әҗер-савапка да ирешер. Аларның күбесе Аллаһы Тәгаләне искә алу (зикер итү) белән бәйле. Бу кешенең Раббысы белән элемтәсен ныгыта, нәтиҗәдә адәм баласының тормышы җиңеләя, ул саклау астында була, җан тынычлыгына ирешә.

## 1. Йокыдан уяну

Имам әл-Бохари һәм имам Мөслимдә килгән хәдистән беләбез: йокларга ятканда, адәм баласын каты йоклату өчен, шайтан аның башы артында өч төен төйнәп куя. Уянгач та, кеше Аллаһы Тәгаләне зикер итсә (мактап теле белән искә алса), аның беренче төене чишелә. Тәһарәт алгач – икенчесе, ике рәкәгать намаз укыгач, өченче төене чишелә. Шуннан соң кешенең тәненә көч-дәрт керер, кәефе дә яхшы булган хәлдә иртәсен каршы алыр. Әгәр боларны башкармаса, начар кәеф белән һәм ялкаулык баскан хәлдә уяныр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм йокларга ятарга җыенганда, болай дип әйтә торган булган: «Бисмикә Аллаһүммә әмүтү вә

әхйә» («Синең исемең белән, йә Аллаһым, мин үләм (йокы кече үлем дип атала) һәм тереләм»). Ә уянган вакытта: «Әлхәмдү лилләһил-ләзи әхйәнә бәгъдә мә әмәтәнә вә иләйһин-нушур», – дип әйткән («Безне үлемннән соң яңадан terелткән Аллаһы Тәгаләгә мактау булсын, һәм Аңа кәберләрдән кубарылып кайтарылачакбыз»)[1].

Хәдисләрдән билгеле булганча, «Аятел-Көрси»не иртәнге якта укыган кеше кичкә кадәр җен-шайтаннардан иминлектә булыр, ягъни алар аңа зыян китерә алмаслар, ә кичке якта укыган кеше иртәнгә кадәр саклау астында булыр[2].

## 2. Киенү

Мөселман кешесе Раббысы белән гел элемтәдә һәм Аны гел искә алып тора. Һәр гамәлен «Бисмилләһ» дип башлап җибәрә, киенгәндә дә, киемен салганда да бу сүзләрне әйтергә онытмый. Әҗер-савапка ирешәм дип, сөннәткә туры китереп, уң яктан киенә башлый, ә чишенгәндә яки аяк киемен салганда, киресенчә, сул яктан башлый.

Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм турында хатыны, мөэминнәрнең анасы Гайшә радыяллаһу ганһә, болай дигән: «Расүлуллаһ аяк киемен киюне, чәчләрен тарауны, тәһарәт алуны һәм барча шундый эшләрен дә уң яктан башлап җибәрергә ярата иде»[3].

Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Берәрегез аяк киемен кисә, уң яктан башласын, ә салса, сул яктан башласын. Я ике аягына да киелгән булсын, я икесе дә салынган булсын»[4]. Ягъни бер аягына аяк киеме киелгән, ә икенчесендә салынган килеш йөрмәсен.

---

[1] Имам әл-Бохари.

[2] Имам ән-Нәсаи.

[3] Имам әл-Бохари.

[4] Имам Мөслим.

## 3. Ашау-эчү

Ризыкка килгәндә, Ислам динендә аның белән бәйле булган билгеле бер әдәпләр бар. Беренче чиратта кулларны юу һәм ашый башлаганда Раббыбыз исемен искә алу.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Бисмилләһ» дип әйт, уң кулың белән аша һәм үз каршыңдагысын аша»[1]. Икенче хәдистә болай диелә: «Сезнең берегез дә сул кулы белән ашамасын һәм эчмәсен. Дөреслектә, шайтан сул кулы белән ашап-эчә»[2].

Күргәнебезчә, иң беренче чиратта Раббыбызның исемен искә алырга («Бисмилләһ» әйтергә) кирәк. Ашаганда һәм эчкәндә уң кул белән ашау хәерлерәк. Әгәр дә ризыкны барысы да бер зур савыттан ашыйлар икән, кеше үз каршысыннан ашый, савыт уртасыннан һәм башка кеше алдындагысын түгел.

Бәрәкәткә ирешер өчен, мөселман, ашаган савытында ризык калдырмыйча, мәсәлән, ипи кисәге белән савытын сыпырып чистартып, ашавын тәмамлый. Соңыннан Раббысына рәхмәтен белдереп, шөкер һәм мактау сүзләрен әйтеп куя.

Ашаганнан соң авызны чайкап алу сөннәт гамәлләрдән, бигрәк тә кеше ашауны тәмамлап, намазга басарга җыенган булса. Әгәр дә калаксыз ашалса яки ризык әсәрләре кулда калса, аларны шулай ук юарга кирәк.

Кешеләр төрле булганга, ошаткан-ошатмаган әйберләре һәм ризыклары төрле булырга мөмкин. Ләкин нindидер хәләл булган ризык ошамаса, аны гаепләргә яки ачуланырга ярамый. Бигрәк тә сине хөрмәт итеп аны каршыңа куйсалар. Хәзрәти Әбү Һөрайра радыяллаһу ганһе болай дигән: «Пәйгамбәребез саллэллаһу галәйһи вә сәлләм беркайчан да ризыкны гаепләмәде, ошатса, ашады, ошатмаса, калдырды»[3].

---

[1] Имам әл-Бохари, Мөслим.

[2] Имам Мөслим.

[3] Имам әл-Бохари, Мөслим.

## 4. Йорттан чыгып китү

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Әгәр дә кеше өеннән чыгып киткәндә: «Бисмилләһ, тәвәккәлтү галә Аллаһ вә лә хәүлә вә лә куввәтә иллә билләһ» (ягъни: «Аллаһы исеме белән, Аллаһыга тәвәккәлләдем, Аллаһыдан башка хәлне үзгәртүче һәм көч бирүче беркем дә юктыр»), – дип әйтсә, аңа (фәрештә тарафыннан) әйтелер: «Туры юлга бастырылдың (һидаятьтә булдың), теләгеңә ирештең, зыяннан сакландың», – дип, һәм шайтаннар, андый кешедән ерагаеп, бер-берсенә: «Һидаятьтә булган, теләгенә ирешкән һәм саклау астында булган кешене син нәрсә эшләтә аласың?» – дияр».[1]

## 5. Көн дәвамында

Йорттан чыгып киткәч, көн дәвамында без төрле кешеләр белән очрашабыз. Мөселманнарның бер-берсенә карата хаклары бар. Мәсәлән, «әссәламү галәйкүм» дип сәлам бирү, киңәшләшү һәм башкалар. Хәдистә болай килә: «Бер мөселманның икенче мөселманга карата алты хакы бар: әгәр аны очратсаң, сәлам бир; әгәр чакырса, чакыруына җавап бир; әгәр киңәш сораса, киңәш бир; төчкереп, «әлхәмдүлилләһ» дисә, «ярхәмүкәллаһ» дип әйт; авырса, хәлен белеш; үлеп китсә, соңгы юлга озат»[2].

## 6. Мәчеткә кергәч, мәчет намазы уку һәм сүтрә булдыру

Иман әһеле мәчеткә килеп кергәч, тыелган вакыт булмаса, беренче итеп мәчет намазы (яки тәхиятүл-мәсҗид намазы) укыр.

---

[1] Имам Әбү Давыд.

[2] Имам әл-Бохари, Мөслим.

Монда да игътибарлы булырга кирәк: зал уртасына басып түгел, ә бәлки читтәрәк басып, каршыңда сүтрә (ягъни киртә: дивар, пәрдә яки урындык кебек нәрсәләр) булдыру сөннәттер. Бу сүтрә кешеләр син намаз укыганда каршыңнан үтеп, гөнаһлы булмасыннар өчен, һәм кеше үтеп, намазың бозылмасын өчен кирәк. Кеше ялгыз укыса яки имам булып басса, һәр намазында сүтрә булдырса хәерле, кайда намаз кылуына карамастан.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Берәрегез намаз укыса, каршысында сүтрә булдырып, аңа якынрак бассын. Һәм каршысыннан беркемгә дә үтәргә рөхсәт итмәсен».[1] Ягъни кулын сузып, каршысыннан (үзе белән сүтрә арасында) узарга теләүчене туктатсын. Сүтрә алдыннан узучыга игътибар ителми.

## 7. Сөннәт намазларны уку

Фарыз булган биш вакыт намазларда фарыз рәкәгатьләрне генә түгел, сөннәтләрен укуда да дәвамлы булу кирәк. Иман әһеле, мәчеттә булсынмы, йортында булсынмы, сөннәт намазларын укымый калдырмас.

Хәдистә болай диелә: «Кем сөннәт намазыннан унике рәкәгатькә сабыр итсә (ягъни дәвамлы булса), Аллаһы Тәгалә аңа җәннәттә йорт (бөек сарай) төзер. Дүртесе өйлә намазы алдыннан һәм икесе аңардан соң, ике рәкәгать ахшам намазыннан соң, ике рәкәгать ястү намазыннан соң һәм ике рәкәгать иртәнге намаз алдыннан».[2]

## 8. Йортка кайтып керү

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: «Әгәр дә кеше, өенә кайткач, йортына кергәндә һәм ашый башлаганда Аллаһы Тәгаләне искә ала икән («Бисмилләһ» дип), шайтан иптәшләренә: «Сезгә

[1] Имам Ибне Мәҗә.

[2] Имам әт-Тирмизи.

монда йокы урыны да, ашау да юктыр», – дияр. Әгәр дә кергәндә Аллаһы Тәгаләне искә алмаса, шайтан: «Төн үткәрү урынына ирештегез», – дияр. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләне ашаганда да искә алмаса, шайтан дусларына: «Йокы урынына да, кичке ашка да ирештегез», – дияр»[1].

Хәзрәти Әнәс бине Мәлик радыяллаһу ганһе тапшыра: «Миңа Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай диде: «Әй углым, әгәр дә гаиләң янына кайтып кердең икән, аларны сәламлә, шул сәбәпле сиңа да, йорт әһелләреңә дә бәрәкәт булыр»[2]. Хәдистә сүз Ислам дине сәламе («Әссәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү») турында бара.

## 9. Кичке вакытта

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Савытларыгызны каплагыз, турсыкларны (бурдюк) бәйләгез, ишекләрегезне бикләгез, яктырткычларны (утларыгызны) сүндерегез. Дөреслектә, шайтан турсыкны сүтми, ишекне ачмый һәм савытның капкачын ачмый. Капларга агач чыбыгыннан кала әйбер тапмасагыз, «Бисмилләһ» дип шуның белән булса да каплагыз»[3].

Икенче хәдистә болай диелә: «Савытларны каплагыз, турсыкларны бәйләгез, дөреслектә, елда бер төн бар (кайбер риваятьләрдә бер көн дип килә), аңарда авыру (чир) төшә. Капланмаган савыт яки бәйләнмәгән турсык яныннан узса, шул авырудан аңа ирешер (төшәр)»[4].

1 Имам Мөслим.

2 Имам әт-Тирмизи.

3 Имам Мөслим.

4 Имам Мөслим.

## 10. Йокларга яту

Йокларга ятар алдыннан да мөселман кешесе тәһарәтен алыр, ятагын «Бисмилләһ» дип сыпырып куяр (киемен яки берәр тукыма кулланып), ә ятканда «Аятел-Көрси»не укыр. Боларның барысы да сөннәттә килә.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм ятканда уң ягына ята һәм уң кулын яңагы астына куя торган була. Эчтә (эч өстендә) ятуны тыя иде, шуңа күрә болай ятуны галимнәр мәкруһ диләр.

Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә барчаларыбызга ике дөнья бәхетенә ирешергә насыйп итсен! Бәла-казалардан, кайгылардан имин кылсын. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Дамир хәзрәт Әхмәтов,*

*Әлмәт районы Тайсуган авылы мәчете имам-хатыйбы*

*27 март вәгазе,*

*шәүвәл аеның 8 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# Тәкъва булуның вакыты кайчан?

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Барча галәмнәрне юктан бар кылып, безне шушы дөньяга китереп, һәрдаим безне ризыкландырып, тәрбияләп торучы, гадел Хөкем итүче, Кыямәт көненең Патшасы, безгә бу дөньяда туры юлдан бару өчен изге Коръәни Кәримне бүләк итүче Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләгә хәмед-сәналәребез, олуглауларыбыз булсын. Сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саләллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебез түрләреннән чыккан салават-шәрифләребез ирешсә иде һәм дә аның әһле бәйтенә, сәхабәләренә сәламнәребез, изге догаларыбыз ирешсә иде!

Раббыбыз Аллаһының әмерен үтәп, Аның рәхмәтенә ирешергә ниятләп, барлык эшләрне калдырып, җомга намазына килгән мөэмин-мөселман кардәшләрем, һәрберебезгә дә Аллаһы Тәгаләнен сәламе, ике дөнья рәхмәте һәм бәрәкәте булсын!

Раббыбызга чиксез шөкерләр булса иде: безне мөбарәк җомга көнендә, аякларыбыз йөргән хәлдә, күзләребез күргән, колакларыбыз ишеткән, үпкәләребез тулы сулыш ала алган, йөрәкләребез типкән хәлдә һәм, иң мөһиме, күңелебезгә иман биреп, Үзенең йортында тагын бер җомга намазында катнашу, Аның йортында кунак булып утыру мөмкинлеген биреп, тагын бер тапкыр безне күрештерде.

Хөрмәтле, мөхтәрәм җәмәгать. Без бүген һәрберебезне борчыган нәрсәләр – яхшылыкка омтылуыбыз, иманыбыз, тәкъвалык, Аллаһы Тәгалә ризалыгына һәм чын бәхеткә ирешү юлында безне нәрсәләр тоткарлавы турында сөйләшергә булдык.

Әле мәчетләрдән читтә йөрүче кардәшләребезне – намазга, инде җомга намазына йөрүчеләрне – биш вакыт намазга, биш вакыт намаз укучыларны мәдрәсәләргә кереп гыйлем алырга чакырганда, күпләребезнең күңелендә эчке каршылык, шик, хәтта курку барлыкка килгәнен күрәбез. Безнең нәфесебез безгә пышылдаган бу шикләр, акланулар, курку каян килә?

Раббыбыз Аллаһы «Әли Гыймран» сүрәсенең 29 нчы аятендә әйтә:

قُلْ إِن تُخْفُوا مَا فِي صُدُورِكُمْ أَوْ تُبْدُوهُ يَعْلَمْهُ اللَّهُ ۗ

**«**[Расүлем!] **Әйт: «Күңелләрегездә булганны яшерсәгез дә, аны ачык белдерсәгез дә, Аллаһы моны белеп тора».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:29

Бу куркуның тамырлары нәкъ менә безнең күңелләрдә, йөрәкләребезнең түрләрендә ята. Тәкъвалык бездән артык күпне таләп итәр дип куркабыз. Гадәткә әйләнеп, безнең тормышларыбызга үтеп кереп, тормышыбызның аерылгысыз бер өлеше булган ләззәтләрдән мәхрүм калудан куркабыз. Безнең Аллаһы юлындагы омтылышларыбызны уртаклашмаучылар тарафыннан гаепләнүдән куркабыз, безнең динебез Ислам куйган югары таләпләргә туры килә алмаудан куркабыз. Һәм, иң мөһиме, динебез белән килгән җаваплылыктан куркабыз.

Сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Синең иң көчле дошманың – синең эчеңдә урнашкан нәфесең», – дигән[1].

Безнең нәфес еш кына тәкъвалык юлында төп киртәгә әверелә. Чөнки, җәмәгать, ул уңайлылык ярата, тиз арада тормышка ашырыла торган

[1] Ибне Хиббән, Бәйһакый.

вакытлыча ләззәтләр ярата, ә тырышлыктан һәм үз-үзен чикләүдән, билгеле бер чикләргә кертүдән курка. «Нигә кирәк сиңа бу? Башкалар кебек яшә, мизгелдән ләззәт ал, киләчәк турында уйлама», – ди.

Әйдәгез, кардәшләрем, уйланыйк әле, тәкъвалыкка таба беренче адымны ясаудан безне нәрсә тоткарлый? Чөнки бу куркулар белән бәлки безнең һәрберебез кайчандыр очрашкандыр.

## 1. Гаепләүдән һәм җәмгыять басымыннан курку

Даими рәвештә намаз укый башларга, тыйнаграк киенергә теләгән яшь егет кешене күз алдына китерегез. Ләкин аның белән вакыт үткәрергә күнеккән дуслары аннан көләләр, аны «фанатик», «артта калган» дип атыйлар. Ул дусларын югалтудан курка, үз даирәсендә «ак карга» булып калудан курка. Бу курку аны тәкъвалыкка таба беренче адымнарыннан тыеп кала.

Имам әл-Газали (Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтендә булсын) кешеләрнең фикереннән курку Аллаһыдан куркудан көчлерәк булырга мөмкин, ди. Еш кына кешеләр, аларның гамәлләрен Аллаһы Тәгалә ничек бәяләвенә караганда, башка кешеләрнең нәрсә әйтүе турында күбрәк борчыла.

## 2. Гөнаһка күнегү һәм тәүбә итүне кичектерү

Мәсәлән, кеше исерткеч эчемлекләр куллана яки тыелган, харам булган әйбергә карый. Ул моның гөнаһ икәнен белә, вөҗдан газабы кичерүен сизә, ләкин үз-үзенә: «Мин бүген булдыра алмыйм, ләкин иртәгә ташлыйм. Хәзер бик авыр. Минем әле вакытым күп, үләр алдыннан тәүбә итәрмен», – ди. Бу начар гадәтләр шулкадәр көчле ки, кеше яхшыга үзгәрүен кичектереп торганда, алар аны алдый, куркынычсызлык иллюзиясен тудыра, ягъни кеше үзен имин дип уйлый.

Имам Мөслим җыентыгында килгән хәдисендә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ий кешеләр, тәүбә итегез, чөнки мин көненә йөз тапкыр Аллаһы каршында тәүбә итәм», – ди. Бу хәдис хәтта иң тәкъва кешенең дә һәрвакыт Аллаһыга тәүбә итеп мөрәҗәгать итүен күрсәтә. Һәм бу безгә тәүбәне кичектерергә кирәкмәвен янә бер искә төшерә.

## 3. Иман байлыгың камил дип алдану

Кеше Исламның төп нигезләрен башкара – намаз укый, ураза тота, зәкят түли... Ул моны җитәрлек дип саный һәм алга таба рухи үсешкә омтылмый. Ул өстәмә тырышлык күрсәтергә кирәк булган гамәлләрне – Коръән укуны, зикер кылуны, хәйриячелекне, Ислам фәннәрен өйрәнүне – артык күп вакыт һәм көч таләп итәр дип курка. Һәм шул юнәлешләргә сарыф итәсе вакытны бу дөнья нигъмәтләренә сарыф итә. Чөнки ул болай да инде Аллаһы юлында җитәрлек дәрәҗәдә көч куям, дип уйлый. Үзен үзеннән түбәнрәкләр белән чагыштыра: «Әнә алар бит әле намаз да укымыйлар», – дип үзен тынычландыра.

## 4. Үз-үзеңне чикләүдән һәм ирегең югалтудан курку

Кайбер кешеләр Ислам кануннарын үтәү аларның ирекен чикли дип саный. Алар үзләренә ошаган, нәфесләре таләп иткәнне бернинди киртәләргә, чикләргә карамыйча эшләргә тели. Диндарлык, тәкъвалык аларга тормыштан ләззәт алырга, үзләре теләгәнчә яшәргә ирек бирмәячәк дип курку аларны дин кушканча яшәүдән тотып кала.

Әмма сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзе, барлык чикләүләргә карамастан, иң ирекле кеше булды. Җәмәгать, нәрсәдә чагылды аның иреклеге? Ул үз нәфесенең колы булып яшәүдән азат булды. Ә безнең күбебез, ни аяныч, бу дөньяда без ирекле дип, теләгән әйберебезне кылабыз дип, шул гамәлләрне кылдырган нәфесебезнең коллары булып яшәгәнебезне

сизмибез. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам кешеләрдән куркудан азат иде, әгәр Аллаһы кушканны эшләсәм, Аллаһы кушканны әйтсәм, кешеләр ничек карар, нәрсә дип әйтерләр дигән уйлардан азат иде. Начар теләкләрдән, хәерсез гамәлләрдән азат иде. Пәйгамбәрнең тормышы Аллаһыга буйсынуның кешегә чын мәгънәсендә хакыйкый ирек бирүенең үрнәге була.

## 5. Белем җитмәү һәм тәкъвалыкның чын асылын аңламау

Кеше тәкъвалык турында ишетсә дә, аны күңелсез, кырыс тормыш итеп күз алдына китерә. Дөреслектә, ул Аллаһыдан курку китергән матурлыкны һәм эчке төзеклекне, гармонияне күрми. Тәкъва тормышның ләззәте, Аллаһының аңа биргән нигъмәтләре турында белем җитмәү аны тәкъва тормышка омтылудан туктата.

Кеше тәкъвалыкның аны нәрсәдәндер мәхрүм итү түгел, ә аның өчен зур нигъмәтләр табышы булуын аңламый. Ә бу табыш үз чиратында – Аллаһының ризалыгы, күңел тынычлыгы, эчке көч һәм чын бәхет казану.

Димәк, без үзебезнең нәрсәдән курыкканыбызны, үзебезнең зәгыйфь якларыбызны, безне тәкъвалыкка таба беренче адым ясавыбыздан аяккулларыбызны бәйләгән күзгә күренмәгән яшерен җепләрне ачыкладык. Ә ничек бу куркулардан арынырга, зәгыйфь якларыбызны көчле якка үзгәртергә, безне адым ясаудан тотып торган бу җепләрне ничек кисәргә соң, җәмәгать?

1. Әлбәттә, иң беренче адым – ул Раббыбызга булган ихлас догаларыбыз. Аллаһы Тәгалә Үзе изге Китабында болай дип әйтә:

وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ ۖ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ إِذَا دَعَانِ ۖ
فَلْيَسْتَجِيبُوا لِي وَلْيُؤْمِنُوا بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ ﴿١٨٦﴾

«[Расүлем!] **Колларым синнән Минем турында сорасалар, һичшиксез, Мин бик якын. Дога кылучының догасын Миңа ялварган чагында ук кабул итәм. Миннән кабул итүне сорасыннар һәм Миңа иман китерсеннәр. Бәлки, алар** [дини һәм дөньяви мәнфәгатьләренә ирешеп] **туры юлдан барырлар».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:186

Аллаһы Тәгаләдән иманыгызны ныгытуын, сезгә көч бирүен һәм туры юлга юнәлтүен сорагыз.

2. Икенче адым, мөхтәрәм җәмәгать, Коръәнне һәм Сөннәтне өйрәнү. Чөнки белем – ул төрле шикләр һәм куркулар караңгылыгын таратучы яктылык, бер нур. Тәкъвалыкның чынлыкта нәрсә икәнен һәм тәкъваларга нинди нигъмәтләр әзерләнгәнен өйрәнү шарт.

3. Өченче адым – тәкъва булган хәерле кешеләр җәмәгатендә булу, алар белән күбрәк аралашу. Әбү Давыд һәм Имам әт-Тирмизи җыентыкларында килгән хәдистә Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кеше үзенең дустының диненә иярә, шулай булгач, сезнең һәркайсыгыз кем белән дус булуын карасын», – ди.

Хәерле дуслар сезгә бу юлда терәк-таяныч булачак, ярдәм итәчәк һәм сезгә максатыгыз турында искә төшереп торачак.

4. Дүртенче адым – нәкъ менә бу юлда әкренләп, кечкенә адымнар белән бару.

Барысын да берьюлы үзгәртергә тырышмагыз. Кечкенә адымнар, гамәлләрдән башлагыз. Бер максат куегыз: мәсәлән, бер генә намазны да калдырмаска, көненә бер бит Коръән укырга.

Имам Ибне Сирин (Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтендә булсын) болай дигән: «Әгәр сез яхшылыкка омтыласыз икән, аны аз булса да эшләгез, чөнки даими рәвештә башкарыла торган кечкенә эш вакыт-вакыт башкарыла торган зур эштән яхшырак».

5. Бишенче адым – бу тормышның бик тиз үтүен һәм Кыямәт көне турында искә төшереп тору. Бу дөнья тормышының ахыры булуын һәм Кыямәт көненең котылгысыз булуын аңлау безгә тәкъвалыкның чын кыйммәтен аңларга ярдәм итә.

كُلُّ نَفْسٍ ذَائِقَةُ الْمَوْتِ ۗ وَإِنَّمَا تُوَفَّوْنَ أُجُورَكُمْ يَوْمَ الْقِيَامَةِ ۖ فَمَن زُحْزِحَ عَنِ النَّارِ وَأُدْخِلَ الْجَنَّةَ فَقَدْ فَازَ ۗ وَمَا الْحَيَاةُ الدُّنْيَا إِلَّا مَتَاعُ الْغُرُورِ ﴿١٨٥﴾

> **«Һәрбер җан үлемне татыячак.** [Инкяр итүчеләр үлемнән соң җәзасыз калмаячак]**. Әҗерләрегез сезгә** [каберләрегездән кубарылганнан соң] **Кыямәт көнендә генә тулысынча биреләчәк.** [Шулвакыт] **Кем дә кем уттан ераклаштырыла һәм җәннәткә кертелә, һичшиксез, ул котылган булыр. Дөнья тормышы** [һәм аның ләззәт, ялтыравыклары] **исә – алданып** [шул ләззәтләрдән] **файдалана торган нәрсә».**
>
> «Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:185

Хөрмәтле җәмәгать, без аңларга тиеш: диннән, тәкъвалыктан курку – ул үзебез тудырган күләгә генә. Бу безнең нәфес һәм наданлыгыбыз тудырган алдану, иллюзия. Чын тәкъвалык – ул йөк, авырлык түгел, ә бүләк һәм нигъмәт. Ул чын иреккә, күңел тынычлыгына, Аллаһы Тәгалә ризалыгына, бу дөньяда һәм мәңгелек дөньяда уңышка юл.

Бу куркуны җиңеп чыгу белән, без Аллаһы Тәгаләнең чиксез мәрхәмәтенә ишек ачабыз, тормышыбыз үзгәрә. Без көчне авырлыкларда табабыз, зирәклекне сынауларда күрәбез, Аллаһы Тәгалә юлында булуыбыз белән бәхеткә ирешәбез.

Тәкъвалык – ул без барып җитеп, туктап калырга тиеш булган билгеләнеп куелган нокта түгел, тәкъвалык – ул юл. Һәм бу юлдагы һәр адым – үз-үзеңне, нәфесеңне җиңү, чын бәхеткә таба бер адым.

Йә Раббым! Үз юлыңнан барырга тәвәккәллегебезне ныгыт. Күңелләребезне, йөрәкләребезне тәкъвалыктан куркудан арындыр һәм безгә аны яра-

туны бүләк ит. Безгә зәгыйфь якларыбызны һәм нәфесебезне җиңәргә ярдәм ит. Безнең алда чиксез мәрхәмәтеңнең, рәхмәтеңнең ишекләрен ач һәм безне туры юлдан алып бар. Безне Үзең яраткан, Үзең разый булган кешеләр арасыннан кыл! Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым! Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Ильнур хәзрәт Вафин,*

*Казанның «Рауза» мәчете имам-хатыйбы*

*3 апрель вәгазе,*
*шәүвәл аеның 15 нче көне, һиҗри исәп буенча 1447 ел*

# «Күрше хакы – Аллаһы хакы»

Әгууҙү билләәһи минәш-шәйтаанир-раҗиим. Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Әлхәмдүлилләәһи Раббил-гааләмиин. Әссаләәтү вәссәләәмү галәә расүлинә Мүхәммәдин вә галәә әәлиһи вә әсъхәәбиһи әҗмәгыйн.

Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә:

وَاعْبُدُوا اللَّهَ وَلَا تُشْرِكُوا بِهِ شَيْئًا ۖ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا وَبِذِي الْقُرْبَىٰ وَالْيَتَامَىٰ وَالْمَسَاكِينِ وَالْجَارِ ذِي الْقُرْبَىٰ وَالْجَارِ الْجُنُبِ وَالصَّاحِبِ بِالْجَنبِ وَابْنِ السَّبِيلِ وَمَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ

**«Аллаһыга гыйбадәт кылыгыз. Аңа бернәрсәне дә ширек кушмагыз. Ата белән анага,** [бертуганнар һәм агалар кебек] **якыннарга, ятимнәргә, мескеннәргә,** [нәселдәшлек яки яшәгән урыны җәһәтеннән] **якын күршегә,** [нәселдәшлеге яки өе] **ерак күршегә,** [ир-хатын, юлдаш һәм сабакташ кебек] **янәшәдәге иптәшләргә, юлда калучыга һәм уң кулыгыз ия булган нәрсәләргә** [коллар, җарияләр һәм хезмәтчеләргә] **игелек кылыгыз».**

«Ән-Ниса / Хатыннар», 4:36

Хөрмәтле дин кардәшләрем, бу аять динебездә күршеләргә карата күркәм мөнәсәбәтнең зур әһәмияткә ия булуын күрсәтә. Аллаһы Тәгалә күрше хакын Үзенә гыйбадәт кылу белән бергә искә ала. Димәк, күрше белән мөнәсәбәт – ул иманның бер өлеше, ихлас мөселманлыкның билгесе.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күрше хакы турында күп хәдисләре бар, шуларның берничәсен искә төшереп китик.

Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип әйткән: «Җәбраил галәйһиссәлам миңа күрше турында шулкадәр нәсыйхәт бирде ки, мин күрше варислар исемлегенә дә кертелер дип уйладым»[1]. Бу хәдистән аңлашылганча, күршеләребез безнең туганыбыз кебек. Аларның хәлен сорашу, ярдәм итү, рәнҗетмәү – мөселманның бурычы. Күрше белән мөнәсәбәт – күңел көзгесе.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм шулай ук болай дип әйткән: «Аллаһыга һәм Ахирәт көненә иман китергән кеше күршесенә зыян кылмасын»[2]. Күршеңә матди яктан булсынмы яки хәтта тавыш күтәрү белән, әшәке сүз белән дә зыян салу – гөнаһ. Күрше хакын бозу – иман зәгыйфьлегенең күрсәткече. Хәзрәти Ибне Габбас радыяллаһу ганһе болай дип әйткән: «Әгәр кеше намаз укыса, ураза тотса, ләкин күршесенә зыян китерсә – иманы камил булмас».

Күршеңне ярату, аңа хөрмәт күрсәтү – Аллаһыга мәхәббәт билгесе. Чөнки Аллаһы Тәгалә, кешеләрне сынау өчен, аларны бер-берсенә күрше итеп куя. Берәү – бай, икенчесе – фәкыйрь; берәү – саулыкта, икенчесе – авыру... Аллаһы безнең сабырлыгыбызны һәм шәфкатьлелегебезне күрмәкче.

Бервакыт Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм янында ике хатын турында сүз чыга. Кешеләр болай дип әйтәләр: «Бер хатын биш вакыт фарыз намазлардан тыш күп итеп нәфелләр укый, фарыз уразадан тыш нәфел уразалар тота, ләкин күршеләренә начар мөгамәләдә». Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул җәһәннәмдә булачак», – дип әйтә. Шуннан соң кешеләр әйтәләр: «Ә менә икенче бер хатын фарыз булып йөкләнгән биш вакыт намазны гына укый, ләкин күршеләренә бик шәфкатьле». Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ул җәннәттә булачак», – дип әйтә[3].

---

[1] Имам әл-Бохари, Мөслим.

[2] Имам әл-Бохари, Мөслим.

[3] Имам Әхмәд.

Бу хәдис безгә күрше хакының никадәр зур икәнен искәртә. Кеше күп гыйбадәт кылса да, әгәр кешеләргә, бигрәк тә күршеләренә, авырлык китерсә, Аллаһы каршында аның дәрәҗәсе түбән булырга мөмкин.

Күрше хакын үтәү юллары бик күп. Күрше хакын үтәү – зур сүз генә түгел, ул гамәл белән исбатлана. Күршелек әдәпләренә кайбер мисаллар:

1. Сәлам бирү һәм хәлен сорашу. Күршеңне күргәч елмаю – үзе бер садака.

2. Авыр вакытта ярдәм итү. Авырган күршегә ризык алып керү, балаларын карашу – зур савап.

3. Зыян китермәү. Тавыш күтәрмәү, машинаңны күрше ишегалдына куймау – бу да күркәм әдәпләрдән.

4. Серне саклау. Күршеңнең гаилә серен тарату – хыянәт.

5. Бәйрәмнәрдә котлау, кайгыда юату – болар күршеләр арасындагы мәхәббәтне арттыра.

Күрше – безгә Аллаһының сынавы һәм рәхмәте. Күрше хакын саклаган кешедән Аллаһы разый була. Күршесенә зыян салучы Аллаһының рәхмәтеннән ераклаша.

Аллаһы Тәгалә каршында иң хәерле күрше булыйм дисәң, сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең киңәшен үтә: «Аллаһы Тәгалә каршында иң хәерле юлдаш – юлдашына иң яхшы мөнәсәбәттә булган кеше, ә Аллаһы Тәгалә каршында иң хәерле күрше – күршесенә иң игелекле булган кеше»[1].

Аллаһым! Безне күршеләребез белән татулыктан, шәфкатьтән, ихласлы мөнәсәбәттән аерма. Күңелләребезгә рәхмәт, сабырлык, юмартлык сал. Әмин.

* * *

Фузайл бине Гыяз: «Әгәр дә минем кабул була торган бер догам барлыгын белсәм, мин аны җитәкче өчен кылыр идем», – дип әйткән. Йә Раббым!

[1] Имам әт-Тирмизи.

Җөмһүриятебез өчен иминлек, тынычлык, бәрәкәт, муллык һәм киләчәктә дә рәисебез Рөстәм Нургали улының саулык-сәламәтлектә, иминлектә, күңел тынычлыгы белән хезмәт итүен, халкыбызның бәрәкәттә, җитеш, мул тормышта, бәхетле булып яшәүләрен, туган телебез, милләтебез өчен үсеш, камилләшү һәм аның киләчәк буыннарга кадерле ядкәр итеп тапшырылуын, милләтебезнең озын гомерле, имин булуын насыйп ит!

*Рүзил хәзрәт Ихсанов,*

*Әлмәт шәһәренең Р. Фәхретдин исемендәге Җәмигъ мәчете имамы*

# Нәрсә?
# Кайда?
# Кайчан?

# СЕНТЯБРЬ–НОЯБРЬ

## Әлки мөхтәсибәтендә капиталь төзекләндерүдән соң «Актай» мәчете ачылды

Рабигыль-әүвәл аеның 14 нче көнендә (6 сентябрьдә) Әлки районының Базарлы Матак авылында капиталь төзекләндерүдән соң «Актай» мәчетен ачу тантанасы узды. «Фин йорты» дигән төзелеш материалыннан 1993 елда төзелгән мәчетнең намаз залы — 86 квадрат метр.

Төзекләндерү вакытында диварлар эчтән тышланган, идәннәр җылытылган, барлык уңайлыклары булган тәһарәтханә корылган, сантехника һәм җиһазлар алмаштырылган һ.б. эшләр башкарылган. Төзекләндерү эшләрендә Илназ Борһанов гаиләсе зур ярдәм күрсәткән. Мәчет янында Мәгърифәтчелек үзәге эшли: анда мәчет каршындагы курслар уза.

Бүгенге көндә Әлки мөхтәсибәтендә 32 мәчет эшли.

## Казанның «Рауза» мәчетендә Татарстан Мөфтие катнашында Мәүлид узды

Рабигыль-әүвәл аеның 16 нчы көнендә (8 сентябрьдә) Казанның «Рауза» мәчетендә Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләм туган көнгә багышланган Мәүлид ән-Нәби чарасы узды.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Мәүлиднең фазыйләтләре турында сөйләде, аны билгеләп үтүнең мөһимлеге һәм зарурлыгы хакында бәян итте. Танылган башкаручы Динар Шәймәрданов һәм «Ислам кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә шәкертләре Мәүлид касыйдәсен башкарды, аннан Ватанны саклаучылар һәм илебез иминлеге өчен дога кылдылар.

## Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды Газзәдәге 800 дән артык кешегә гуманитар ярдәм күрсәтте

Татарстан Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Газзә секторында оккупантлар чолганышында калган гади халыкка гуманитар ярдәм күрсәтүен дәвам итә. Сентябрь башында фонд кабат булышлык итте: күпбалалы гаиләләргә азык-төлек җыелмалары өләште. Барлыгы 800 дән артык кеше азык-төлек белән тәэмин ителде. Азык-төлек җыелмаларында шикәр, югары сыйфатлы дөге, токмач, помидор пастасы, ит һәм балык консервалары, көнбагыш мае, чикләвек пастасы, тозлы сыр бар.

Шушы көнгә Газзәгә тапшырылган гуманитар ярдәмнең гомуми күләме 30 миллион сумнан артып китте. Моңарчы «Зәкят» хәйрия фонды Газзәдә гомер итүче гади халык өчен Диния нәзарәтеннән 60 тонна гуманитар йөк тапшырган иде. Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов йөкләмәсе нигезендә Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды бу юнәлештәге эшчәнлекне дәвам итә.

## «Ак Барс Арена» стадионында намаз бүлмәләре әзерләнде

Рабигыль-әүвәл аеның 17 нче көнендә (9 сентябрьдә) Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин «Ак Барс Арена» стадионында булды. Биредә «Рубин» (Казан) — «Динамо» (Махачкала) клублары уенына әзерлек кысаларында футбол караргa килүчеләр өчен 2 намаз бүлмәсе җиһазландырылды.

Намаз уку бүлмәләре, «Рубин» футбол клубы» автоном коммерциячел булмаган оешма идарәсе президенты Марат Әдип улы Сафиуллин башлангычы белән, «Рубин» футбол клубы һәм стадионның уртак тырышлыгы белән булдырылды. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Марат Әдип улына, намаз бүлмәләрен булдыручыларга һәм хәйриячеләргә ихлас рәхмәтләрен җиткерде.

Хәзер мөселманнар футбол уеннары барган вакытта уңайлы шартларда намаз укый ала. 12 шәр квадрат метрлы бүлмәләр көнчыгыш һәм көнбатыш трибуналарда урнашты. Янәшәдә үк уңайлыклар тудырылган тәһарәтханә бар. Намаз бүлмәләре «Рубин» футбол клубының Казанда үтә торган уеннарында барлык кешеләр өчен дә ачык.

## Казанда Коръән фәннәрен өйрәнүгә багышланган «Иманколый укулары» фәнни-гамәли конференциясе узды

Рабигыль-әүвәл аеның 18 нче көнендә (10 сентябрьдә) Казанда Коръән фәннәрен өйрәнү мәсьәләләренә багышланган «Иманколый укулары» Россиякүләм фәнни-гамәли конференциясе узды. Аны Татарстан мөфтияте, Россия Ислам институты, Казан Ислам университеты, Коръән хафизларын әзерләү үзәге оештырды. Конференция XX гасырның күренекле татар кадимчеләреннән саналган дин әһеле, «Тәсһил әл-бәйән фи тәфсир әл-Коръән» («Коръән тәфсирен аңлатуны җиңеләйтү») тәфсире авторы Мөхәммәдсадыйк хәзрәт Иманколый истәлегенә багышлап үткәрелде.

Укуларда катнашучылар Мөхәммәдсадыйк Иманколыйның рухи мирасы; Коръәнне татар теленә тәрҗемә итү тарихы; хәзерге заманда Коръән фәннәре үсеше; Коръән тәфсире буенча уку әсбаплары эшләү; гарәп телен (Коръән текстын) өйрәнү; тәҗвидне өйрәнүдә яңа ысуллар куллану һ.б. турында фикер алышты.

## Мирный бистәсендәге «Тынычлык» мәчетендә Мәүлид узды һәм тантаналы рәвештә чишмә ачылды

Рабигыль-әүвәл аеның 22 нче көнендә (14 сентябрьдә) Мирный бистәсендәге «Тынычлык» мәчетендә Мәүлид узды һәм тантаналы рәвештә чишмә ачылды. Әлеге чарада Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, җитәкчеләр, мәхәллә әгъзалары, эшмәкәрләр катнашты.

Бары Татарстанда гына мәчетләр янында эчәргә яраклы су чыганакларын булдыру тәҗрибәсе тормышка ашырылып килә.

## Питрәч мөхтәсибәтендә «Рамазан-Шәриф» мәчете каршында Мәгърифәтчелек үзәге ачылды

Мәчетләр каршындагы курслар башланыр алдыннан, Питрәч мөхтәсибәтенең Ленино-Кокушкино авылында «Рамазан-Шәриф» мәчете каршында Мәгърифәтчелек үзәге ачылды. Мәйданы 125 квадрат метр тәшкил иткән бина 70 кешегә

исәпләнгән. Анда шулай ук гардероб, җиһазландырылган кухня, ифтарлар һәм дини чаралар уздыру залы, ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханә урнашкан. Мәгърифәтчелек үзәге янында балалар мәйданчыгы бар, ә киләчәктә паркны төзекләндерү көтелә.

## Астанада тантаналы рәвештә Россиянең «Хозур ТВ» һәм Казахстанның «Мунара ТВ» мөселман телеканаллары арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды

Астанада дөньякүләм һәм традицион диннәр лидерлары съездында тантаналы рәвештә Россиянең «Хозур ТВ» һәм Казахстанның «Мунара ТВ» мөселман телеканаллары арасында хезмәттәшлек турында килешү имзаланды. Үзара хезмәттәшлек турындагы документларга «Мунара ТВ» генераль директоры Булат Какибаланов һәм Татарстан мөфтие урынбасары, Нәзарәтнең «Хозур» нәшрият йорты җитәкчесе Ришат Хәмидуллин кул куйды. Ул телевизион тапшырулар һәм һөнәри тәҗрибә алмашуны күздә тота.

## Казахстан Президенты Татарстан мөфтиенә бүләк тапшырды

Астанада дөньякүләм һәм традицион диннәр лидерларының VIII Съезды барышында Казахстан Республикасы бүләкләрен тапшыру тантанасы узды. Ил Президенты Касым-Жомарт Токаев динара тынычлыкны һәм җәмгыятьтә татулыкны саклауга зур өлеш керткән шәхесләрне бүләкләп узды. Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Президент кулыннан дөньякүләм һәм традицион диннәр лидерлары Съездының мактаулы медален алды. Бу бүләк дөньякүләм һәм традицион диннәр лидерларына, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклеләренә динара багланышларны ныгытуга керткән зур хезмәтләре өчен бирелә.

## Нәзарәттә «Затлы мәҗлес» проектының яңа сезоны башланды

Татарстан Диния нәзарәтендә хатын-кызларның «Затлы мәҗлес» дип аталган уникаль проектының яңа сезоны башланды. Бу сезонда «Затлы мәҗлес» Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең һиҗри буенча агымдагы 1447 елда 1500 еллыгы кысаларында уздырыла. Кичәнең төп темасы «Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә булган мәхәббәтебез эшләребездә, сүзләребездә һәм йөрәгебездә ничек чагылыш таба?» дип аталды.

Рухи-мәгърифәтчелек очрашуында төрле яшьтәге 80 нән артык мөслимә катнашты.

## Мөфти Камил хәзрәт Түбән Камада эш сәфәрендә булды

Рабигыль-әүвәл аеның 28 нче көнендә (20 сентябрьдә) мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Түбән Камада эш сәфәрендә булды. Биредә ул «Тәхфиз» пансионаты проекты белән танышты.

Түбән Камага кунаклар килү хөрмәтенә Мәүлид бәйрәме узды: балалар чыгыш ясады, Коръән укылды, нәшидләр әйтелде. Әлеге чара һиҗри исәп буенча 1447 елда билгеләп үтелүче Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгы кысаларында, шулай ук Түбән Кама шәһәре көне уңаеннан оештырылды.

## Казанда абыстайлар милли мәдәниятне һәм гаилә традицияләрен саклауның мөһимлеге хакында фикер алышты

Рабигыль-әүвәл аеның 29 нчы көнендә (21сентябрьдә) Казанда милли мәдәниятне саклауда хатын-кызларның вазифасы мәсьәләләренә багышланган абыстайлар җыелышы узды. Җыелышта мөслимәләр татар, иран, төрек, кытай милли ашларын тәкъдим итте. Алар шулай ук гаилә бәхете серләре белән уртаклашты: мәдәни аерымлыкларга карамастан, алар төрле илләрдә охшаш булып чыкты.

## Әлмәттә мөселман командалары арасында футбол буенча республика турниры узды

Рабигыль-әүвәл аеның 29 нчы көнендә (21 сентябрьдә) Әлмәт мөхтәсибәтендә мөселман командалары арасында футбол буенча республика турниры узды. Турнирда 15 команда катнашты. Бу ярышлар спорт мәйданында көч сынашу гына түгел, ә бердәмлек, дуслык һәм кардәшлек мөнәсәбәтләрен ныгыту урынына да әверелде.

## Диния нәзарәтендә Лекторий эшли башлады

Диния нәзарәтендә мөселман яшьләре өчен яңа Лекторий сезоны башланды. Ай саен анда катнашучыларны танылган спикерлар катнашында Ислам һәм өммәт тормышы турында мавыктыргыч ачык лекцияләр һәм фикер алышулар көтә. Хәзрәтләр, мөселман табиблары, икътисадчылары, юристлар һәм башкалар актуаль сорауларга җавап бирә. Беренче очрашулар социаль челтәрләрне алып барудагы үзгәрешләр, шулай ук җәннәт темаларына багышланган иде.

## Зәй мөхтәсибәтендә Ялчыгол укулары узды

Рабигыль-ахыр аеның 2 нче көнендә (24 сентябрьдә) Зәй мөхтәсибәтендә «Таҗетдин Ялчыгол мирасы буенча эзләнүләр һәм аларның тарихи әһәмияте» темасына республика фәнни-гамәли конференциясе үтте. Әлеге чара күренекле татар мәгърифәтчесе, дин эшлеклесе, галим, язучы Таҗетдин Ялчыголның (1768–1838) тормыш юлына һәм иҗатына багышланды. Конференциянең пленар утырышында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да катнашты.

Чара кунаклары Зәй районы Имәнлебаш авылында Таҗетдин Ялчыголның каберен зиярәт кылып, аның рухына дога кылды; Зәй шәһәрендәге «Билал» мәчетендә Таҗетдин Ялчыгол музеенда булып, күренекле мәгърифәтченең тормышы һәм эшчәнлеге белән бәйле экспонатлар һәм тарихи китаплар белән танышты; Зәй районы Куш-Елга авылы зиратында Таҗетдин Ялчыголның нәсел дәвамчылары каберен зиярәт кылды.

## Казанда XIV Якупов укулары узды

Рабигыль-ахыр аеның 3 нче көнендә (25 сентябрьдә) Казанның «Мәрҗани» мәчетендә XIV Якупов укулары узды. Фәнни җыен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм Россия Ислам институты тарафыннан Ислам мәдәниятенә, фән һәм мәгарифенә ярдәм фонды теләктәшлегендә оештырылды.

Быел Укулар һиҗри буенча 1447 елда Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгы, «Апанай» мәчетенә нигез салынуга 255 ел һәм «Иман» нәшриятының 35 еллыгы кысаларында үткәрелде. Ел саен узучы әлеге чарада сүз күренекле татар мәгърифәтчесе, галим һәм дин әһеле Вәлиулла хәзрәт Якуповның (1963–2012) бай рухи, дини һәм иҗади мирасы хакында барды.

Чараның пленар өлешеннән соң «Мәрҗани» мәчетендә «Вәлиулла хәзрәт Якуповның тормышы һәм мирасы» һәм Вәлиулла хәзрәт хезмәт иткән «Апанай» мәчете бинасында «Апанай» мәчете: тарих, хәзерге заман һәм киләчәккә юнәлешләр» дигән секцияләр эшләде.

## «Алга» һәм «Батыр» батальоннарында хезмәт итүче Нәзарәтнең полк имамнары МХО зонасының алгы сызыгында ике җир асты мәчетен ачты

Татарстан мөфтиятенең казые, Ютазы районы имам-мөхтәсибе Марат хәзрәт Мәрданшин җитәкләгән делегация махсус хәрби операция зонасындагы солдатларга чираттагы гуманитар йөкне илтеп кайтты. Хәрби часть командованиясе заявкалары буенча Татарстан мөселманнары туплаган әйберләрне турыдан-туры «Батыр» һәм «Алга» батальоннары хәрбиләренә, шулай ук фронттагы 3 госпитальгә тапшырдылар.

Хәзрәтләр «Алга» батальонының 72 нче бригадасында һәм «Батыр» батальонының 35 нче бригадасында җир астында мәчетләр ачылышында да катнашты. Төзелеш башында бригада командованиесе, Нәзарәтнең әлеге батальоннарда хезмәт итүче полк имамнары Руслан хәзрәт Әгъмәлов һәм Мөхәммәд хәзрәт Хәйрулаев, мөселман сугышчылары торды. Ике мәчет тә мөселман сугышчылары көче белән торгызылган.

## Казанда яшь мөслимә киленнәрнең «Яшь килен» курслары башланды

Рабигыль-ахыр аеның 9 нчы көнендә (1 октябрьдә) Казанда мөселман яшьләре арасында популярлык казанган «Яшь килен» проектының унөченче агымы башланды һәм 70 мөслимәне җәлеп итте.

2019 елда нигез салынган һәм һәр агым саен кызыклырак була барган киленнәр мәктәбе Аллаһы Тәгалә кануннары буенча бәхетле гаилә корырга һәм гаилә учагын саклап калырга теләүче 17 яшь һәм аннан өлкәнрәк булган, кияүдә булмаган, ярәшелгән мөслимәләр һәм кызларын кияүгә бирергә җыенган әниләр өчен оештырыла. Белем бирү курслары Коръән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте һәм дин галимнәре гыйлемнәренә нигезләнгән.

## «Мәрҗани» мәчетендә «Коръән дөньясы» Россия–Катар интерактив күргәзмәсе үтте

Рабигыль-ахыр аеның 11 нче көнендә (3 октябрь) Казан шәһәренең «Мәрҗани» мәчетендә тантаналы рәвештә «Коръән дөньясы» Россия–Катар интерактив күргәзмәсе ачылды. Проектны Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте һәм Катар Дәүләтенең Вакфлар һәм Ислам эшләре министрлыгы оештырды. Казанда күргәзмәне уздыруда Татарстан Диния нәзарәте ярдәм күрсәтте. Күргәзмә 6 октябрьгә кадәр эшләде: ул изге Коръәнгә кагылышлы бай мирас белән танышырга, аның буыннар һәм мәдәниятләрне берләштерүен күрергә һәм бөтен кешелек өчен мәңгелек әһәмиятен тоярга мөмкинлек бирде.

## Нәзарәткә «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбендә укырга 150 дән артык кеше килде

Рабигыль-ахыр аеның 12 нче көнендә (4 октябрьдә) Нәзарәттә «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбе — кыска вакыт эчендә намазга һәм Ислам нигезләренә өйрәтү курслары — башланды. Һиҗри исәп буенча Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу

галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгына багышлап уздырылган курсларда 150 дән артык кеше теләк белдерде.

Шәкертләр дәресләрдә госел һәм тәһарәт алырга, намаз укырга өйрәнәчәк, Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы белән танышачак, ураза тәртипләре буенча дәресләр тыңлаячак.

## «Зәкят» хәйрия фонды 750 гаиләгә 22 тоннадан артык гошер таратты

«Зәкят» хәйрия фонды, гошер садакасы җыю буенча кампания башланганнан бирле, барлыгы 750 гаиләгә Алексеевск, Балтач, Кайбыч, Балык Бистәсе, Теләче һәм Яңа Чишмә районнарыннан килгән 22 тоннадан артык гошер таратты.

## Казанда яшь мөселманнар өчен «Яшь кияү» курслары башланды

Рабигыль-ахыр аеның 16 нчы көнендә (8 октябрь) Казанда яшь егетләргә шәригать буенча ныклы гаилә корырга ярдәм итәчәк «Яшь кияү» курсының икенче агымы башланды. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгына багышланган курсларның ачылышы «Мәрҗани» мәчетендә узды һәм 50 яшь егетне җәлеп итте.

Белем бирү курслары Коръән, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте һәм Ислам дин галимнәренең гыйлемнәренә нигезләнгән. Яшьләр дәресләрдә никах турында белем туплый, шулай ук хәләл җефетен дөрес сайларга, аны эш-гамәле белән кызыксындырырга, гаилә тормышында хикмәт белән карарлар кабул итәргә һәм гаиләне хәләл юл белән тәэмин итәргә өйрәнә.

## Казанның 50 пенсионерына Нәзарәттән Өлкәннәр көне декадасы хөрмәтенә бәйрәм күчтәнәчләре өләштеләр

Рабигыль-ахыр аеның 18 нче көнендә (10 октябрь) Казанның 50 пенсионерына Өлкәннәр көне декадасы уңаеннан Диния нәзарәтеннән бәйрәм күчтәнәчләре

өләштеләр. «Зәкят» хәйрия фондыннан кучтәнәчләр алучылар арасында ялгыз, аз керемле һәм сәламәтлеге начар булган өлкәннәр бар.

Хәйрия фондының максатчан акчалары хисабына җыелган азык-төлек җыелмаларында үсемлек мае, дөге ярмасы, он, шоколад, балык консервасы, печенье, токмач, чәй, хөрмә җимешләре һәм тушенка бар.

## Донецкида «Хозур» нәшриятыннан мөселман сугышчысының кесә белешмәлеген тәкъдим иттеләр

Донецкида «Хозур» нәшрияты бастырып чыгарган мөселман сугышчысының кесә белешмәлеген — «Мусульманин на воинской службе» китабын — тәкъдим иттеләр. Кесәгә сыйдырышлы китап махсус хәрби операциядәге мөселман сугышчыларына рухи ярдәм күрсәтү өчен басылып чыкты һәм хәрби-кыр шартларында динне тоту мәсьәләләренә багышланды. Китапта катлаулы хәлләр вакытында (дошманнардан саклану өчен, борчылганда һәм хәтәр чакта) укыла торган догалар сайлап бирелгән, шулай ук авыр шартларда рухи тынычлыкны саклау буенча киңәшләр һәм хәрби хезмәттә гыйбадәт кылу тәртибе буенча кыскача күрсәтмәләр бар.

Брошюраны әзерләүдә 15 нче Александрия бригадасындагы һәм 90 нчы танк дивизиясендәге Диния Нәзарәте хәрби имамы Мөхәммәт хәзрәт Хәйрулаев катнашты, ул 2024 елдан бирле МХО зонасында мөселман сугышчылары янында, хәрбиләрнең ихтыяҗлары һәм алгы сызыктагы хәлләр белән шәхсән таныш.

## Мөфти җитәкчелегендә нәзарәт делегацияләре МХО зонасына барып кайтты

Татарстан Диния нәзарәтенең өч делегациясе МХО зонасына гуманитар миссия белән барды. Татарстан мөфтияте вәкилләре мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Донецкида узган «Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен ныгыту, РФнең рухи суверенитетын саклау» конференциясендә катнаштылар. Җыелышны Донецк Халык Республикасы Диния нәзарәте оештырды. Сәфәр кысаларында Татарстан Диния нәзарәте делегациясе сугышчыларга

гуманитар йөкләр илтте. Татарстан мөселманнарыннан ярдәм турыдан-туры хәрбиләр кулына тапшырылды. Гуманитар йөк җыюда бөтен Татарстаннан мөселманнар, шулай ук битараф булмаган меценатлар ярдәм итте.

## Әлмәттә яңа «Тәскирә» мәчете ачылды

Әлмәт шәһәрендә Петуховка микрорайоны, Сәид Калмәтов ур., 1б адресы буенча яңа «Тәскирә» мәчете ачылды. Мәчетнең архитекторы — мәрхүм Искәндәр Насыйров. Мәчет төзелешне башлап җибәрүче Рәйханә һәм Фәрит Ханнановларның әниләре хөрмәтенә «Тәскирә» дип аталган. Төзелеш 2019 елда башланган, алга таба бу башлангычны битараф булмаган мөселманнар да күтәреп алган.

«Тәскирә» мәчете ике катлы, ике манаралы, гомуми мәйданы — 400 кв. м., 150–200 кеше сыйдырышлы. Мәчетнең имамы — Әлмәт мәдрәсәсенең кичке бүлеген тәмамлаган Фәрит хәзрәт Ханнанов.

## «Мәрҗани» мәчетендә Шәех Мәэмүн әр-Рави хәдис дәресләре бирә башлады

Казанда һиҗри буенча Мөхәммәд пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгы кысаларында Шәех Мәэмүн Шә’бән Хәлил әр-Рави белән хәдис дәресләре башланды. Лекцияләр «Мәрҗани» мәчетендә һәр дүшәмбедә ахшам намазыннан соң уза.

Шәех Мәэмүн Шә’бән Хәлил әр-Рави — дөньякүләм танылган дин галиме, Коръән хифзы буенча 10 кыйраәт белгече, Фарсы култыгы илләрендә Коръән буенча бәйгеләрдә баш хөкемдар һәм жюри рәисе, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең нәсел дәвамчысы, Казанда кулъязма Коръән әзерләү буенча комиссия әгъзасы.

## Чистайда Саматов укулары узды

Рабигыль-ахыр аеның 22 нче көнендә (14 октябрьдә) Чистай шәһәренең «Нур» мәчетендә Саматов укулары үтте. Диния нәзарәте һәм Чистай районы мөхтәсибәте

оештырган җыен татар халкының күренекле дин галиме, Татарстанның беренче казые, хөрмәтле дин әһеле Габделхак хәзрәт Саматовның тууына 95 ел тулуга багышлап оештырылды. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Габделхак хәзрәтнең татар-мөселман мәдәниятен саклаудагы бәяләп бетергесез өлешен билгеләп үтте һәм аны әһле сөннәт вәл-җәмәгать тарафдарларыннан, хәнәфи мәзһәбе һәм матуриди гакыйдәсе кыйммәтләрен саклаучы дип атады.

Быел Камил хәзрәтне Татарстан Диния нәзарәте бүләге — «Рухи мирас» медале — һәм премия белән бүләкләделәр. Әлеге бүләк дини һәм иҗтимагый эшчәнлектәге казанышларны бәяләү булып тора.

Кунаклар, Чистайның тарихи мөселман зиратында булып, анда татар дин галиме, ишан, Чулман-Урал төбәгендә суфичылык хәрәкәте мөршиде, Габделхак хәзрәт Саматовның остазы Мөхәммәдзакир Габделвахаб Камалов-Чистави каберен зиярәт кылып, Коръән аятьләре укып, дога кылды.

## Чистайда «Әмирхания» рухи-мәгариф үзәге ачылды

Чистайда тантаналы рәвештә «Әмирхания» рухи-мәгариф үзәге ачылды. Ул 2024 елда Чистай мөхтәсибәтенә тапшырылган «Әмирхания» хатын-кызлар мәдрәсәсенең тарихи бинасы базасында төзелгән. Мөхтәсибәт «Чистави» бизнес-клубы катнашында объектны төзекләндерү һәм реконструкцияләү буенча зур эш башкарды.

Хәзер «Әмирхания» рухи-мәгариф үзәгендә Ислам нигезләре буенча дәресләр уза, фикһ, гарәп теле, гакыйдәне тирәнтен өйрәнәләр, изге Коръәнне дөрес уку буенча иҗазәткә имтиханнар тапшыралар, фәнни очрашулар һәм конференцияләр, мөгаллимнәр киңәшмәләре уза.

## Мөслим мөхтәсибәтендә татар дин галиме Шаһиәхмәд әс-Симәки истәлегенә конференция узды

Рабигыль-ахыр аеның 23 нче көнендә (15 октябрь) Мөслим мөхтәсибәтендә татар дин галиме Шаһиәхмәд хәзрәт әс-Симәки тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган конференция узды. Аның кысаларында Шаһиәхмәд хәзрәт үзенең соңгы

сыену урынын тапкан Симәк авылы зираты янында имам истәлегенә монумент ачылды. Конференциядә катнашучылар анда Коръән укып, дога кылды.

## Бөгелмәдә «Милли моң» Россиякүләм мөнәҗәтләр фестивале узды

Рабигыль-ахыр аеның 22 нче көнендә (19 октябрьдә) Бөгелмәдә «Милли моң» X юбилей Россиякүләм мөнәҗәтләр фестивале узды. Татар мәдәнияте үзәге залындагы узган фестивальгә 250 гә якын талантлы мөнәҗәт башкаручы җыелды. Алар Чиләбе, Самара, Оренбург өлкәләреннән, Башкортстан Республикасыннан, Магнитогорск, Татарстан шәһәр һәм районнарыннан килде. Жюри катнашучыларның башкару осталыгына, образлы эчтәлекне хис белән тапшыруга, төгәл дикциягә, ачык аһәңгә, интонациягә һәм тышкы кыяфәткә игътибар итте.

## Татар хәзрәтләре «десанты» Ислам һәм әдәп-әхлак турында лекцияләр белән Татарстан районнарына чыкты

Халык арасында хөрмәт казанган хәзрәтләр «десанты» Ислам һәм әдәп-әхлак турында лекцияләр белән Татарстан районнарына йөри башлады. Дин кардәшләр белән очрашулар республиканың төрле почмакларында «Гыйлем мәҗлесләре» исеме белән уза һәм ул халыкның дини гыйлемен һәм әхлагын күтәрүгә юнәлдерелгән. Мөселманнар арасында танылган хәзрәтләр Ислам кыйммәтләре турында вәгазьләр укый һәм көнүзәк сорауларга җаваплар бирә: гаиләдәге вазифалар, иман ныклыгы, бала тәрбияләү, шәригать кануннарын үтәү һ.б.

## Казанда мөселман яшьләре «MuslimQuiz» акыл көрәшенең бишенче юбилей сезонын башлады

Рабигыль-ахыр аеның 28 нче көнендә (20 октябрьдә) Диния нәзарәтендә мөселман яшьләре өчен «MuslimQuiz» акыл уеннарының бишенче юбилей сезоны ачылды. Сезонның беренче уенында 25 команда катнашты.

Уен «акыл һөҗүме» форматындагы алты раундтан торды. Һәр раундта төрле халыкларның әдәбиятына кагылышлы алты сорау бирелде. Сораулар популяр китапларны һәм исемнәрне искә төшерергә генә түгел, уйланырга, хәтта таныш әсәрләргә дә башкача карарга мөмкинлек бирде.

## Чирмешәндә район Үзәк мәчете янында «Салкын» чишмә ачылды

Чирмешән районының Үзәк мәчете янында тантаналы рәвештә «Салкын» чишмә ачылды. Мәчетләр янында чишмәләр булдыру кебек матур традиция Татарстанда гына бар. Ә Чирмешәннең Үзәк мәчете янындагы чишмә — бу төбәктә беренчесе. «Салкын» чишмә район хакимияте, иганәчеләр һәм битараф булмаган мөселманнар ярдәме белән торгызылды.

## Казанда чит илләр катнашында «Россия мөселман мәгарифендә: традицияләр һәм инновацияләр» II Бөтенроссия симпозиумы узды

2025 елның 22–25 октябрендә Казанда чит илләр катнашында «Россия мөселман мәгарифендә: традицияләр һәм инновацияләр» II Бөтенроссия симпозиумы үтте. Җыен Россия Ислам институты Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте белән берлектә Ислам мәдәниятенә, фәненә һәм мәгарифенә ярдәм фонды теләктәшлегендә оештырды. Симпозиумда дин әһелләре, дини һәм дөньяви белем бирү оешмалары, хакимият органнары вәкилләре, галимнәр, журналистлар һәм җәмәгать эшлеклеләре — барлыгы 500 дән артык кеше Россиядә мөселман мәгарифен үстерүнең көнүзәк мәсьәләләре турында фикер алышу өчен җыелды.

## Казанның 50 мохтаҗ гаиләсе азык-төлек белән тәэмин ителде

Җөмәдәл-әүвәл аеның 2 нче көнендә (24 октябрьдә) Татарстан мөфтиятенең «Зәкят» хәйрия фонды 50 мохтаҗ гаиләгә азык-төлек җыелмалары таратты. Хәйрия

фондыннан әлеге ярдәмне берүзе балалар үстерүче аналар, күпбалалы гаиләләр, ялгыз пенсионерлар, авыру мохтаҗлар, инвалид бала тәрбияләүче гаиләләр алды. Фонд тарафыннан азык-төлек җыелмалары дин кардәшләребез күрсәткән садакалар, битараф булмаган кешеләрнең матди ярдәмнәре белән әзерләнде.

## Казанда Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин исемендәге I республика форумы узды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 3–4 нче көннәрендә (25–26 октябрьдә) «Әхмәдзәки» мәчете базасында Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин исемендәге беренче республика форумы узды. Фәнни җыелыш «Рухи куркынычсызлык архитектурасы: яшьләр мәсьәләсе» темасына багышланды. Форумда татар дини мирасын, аерым алганда, танылган татар дин галиме Әхмәдзәки хәзрәт Сафиуллин шәхесен популярлаштыруга мөһим урын бирелде.

Форумда яшьләр һәм дини традицияләр; төрле диннәр арасында тынычлыкны һәм үзара аңлашып яшәүне саклау һәм ныгыту мөһимлеге; теологик манипуляцияләр ысуллары (сәләфичелек мисалында); террорчылык һәм экстремизм идеологиясенә каршы тору өлкәсендәге законнар белән бәйле актуаль мәсьәләләр; интернет челтәрендәге куркынычсызлык; террорчылык һәм экстремизм идеяләрен кисәтүдә дини белем бирүнең роле һ.б. мәсьәләләр каралды.

## Түбән Кама мөхтәсибәте махсус хәрби операция зонасында «Чулман» блиндаж мәчетен җиһазландырды

Түбән Кама мөхтәсибәте махсус хәрби операция зонасында 430 нчы полкта хәрбиләр өчен блиндаж мәчете төзүдә ярдәм күрсәтте. Бу эштә Түбән Кама районы имам-мөхтәсибе Салих хәзрәт Ибраһимов һәм мөхтәсибәттә МХО өчен гуманитар ярдәм җыю өчен җаваплы Габделхәким хәзрәт Яруллин, волонтерлар катнашты. Аерым алганда, район мөселманнары һәм мөхтәсибәт активистлары диварга һәм түшәмгә баннерлар ясады, идән өчен келәм, люстра һәм электр җиһазлары сатып алып бирде.

Мосаллә булдыру бурычы хәрби часть командованиесе тарафыннан рота командирының сәяси мәсьәләләр буенча урынбасары, шушы районнан мобилизацияләнгән «Мөслим» атамалы офицерга йөкләнгән иде. Ул барлык кирәкле материалларны үз машинасында полк урнашкан урынга илтеп куйды. Полк командованиесе чокыр казыды, анда мөселманнар өчен дә, христианнар өчен дә дини йолалар үткәрү өчен җиһазландырылган бүлмәләр булдырылды. Ремонт тәмамланганнан соң, блиндаж мәчетне ачып, аңа «Чулман» исемен бирделәр. Унике квадрат метрлы мосаллә 10 кешене сыйдыра. Имамы — Чистай районыннан мобилизацияләнеп килгән офицер (капитан).

## Татарстан мәчетләрендә Коръән укырга өйрәнү курслары башланды

Татарстан мәчетләрендә Рамазан алдыннан Коръән укырга өйрәтү курслары башланып китте. Дәресләр Татарстан мөфтияте һәм Казан Ислам университетының Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизлар әзерләү үзәге төзегән махсус программа нигезендә алып барыла. Мөгаллимнәр ике ай дәвамында гарәп алфавитын һәм кагыйдәләрен төшендерә.

Курслар Казанның «Рәшидә», «Гаилә», «Әниләр», «Иман нуры», «Казан нуры», «Әхмәдзәки», «Әмәт», «Нурислам» мәчетләрендә, шулай ук Питрәч районы Званка авылының «Рамазан» мәчетендә, Яңа Шигали авылындагы Габдрахман бине Гауф исемендәге мәчеттә һәм Мамадыш мәдрәсәсендә уза. Ә «Апанай» мәчете бинасында хатын-кызлар өчен курслар оештырыла.

## Мөфти Казан шәһәренең — 2 нче һәм 19 нчы, Әлмәтнең 8 нче төзәтү колонияләрендә булды

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең социаль мәсьәләләр буенча киңәшчесе, нәзарәтнең Россия Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең Татарстандагы идарәсе белән хезмәттәшлек координаторы, Казан шәһәренең Киров һәм Мәскәү районнары имам-мөхтәсибе Илдар хәзрәт

Баязитов белән Казан шәһәренең — 2 нче һәм 19 нчы, Әлмәтнең 8 нче төзәтү колонияләрендә булды.

Татарстан мөфтие 2 нче колониядә «Касыйм» мәчетендә иректән мәхрүм ителгәннәр белән аралашты. Әлеге мәчет биредә 2008 елдан бирле эшли. Камил хәзрәт үзенең вәгазен харам һәм хәләл темасына багышлады — Исламда рөхсәт ителгән һәм тыелган гамәлләргә кагылышлы мәсьәләләрне җентекләп аңлатты. Ул иң башта — Коръәнгә, ә аннан соң хәдисләргә таянырга өндәде. Бу мәчеткә даими рәвештә 15–20 ләп кеше йөри, җомгалар укыла, Ислам нигезләре буенча дәресләр, рухи әңгәмәләр үткәрелә. Рамазанда 30–40 кеше, ураза тотып, тәравих намазлары укый. Ураза гаете һәм Корбан гаетләренә 40–50 кеше җыела.

Камил хәзрәт 19 нчы колониянең «Ихлас» мәчетендә иректән мәхрүм ителгәннәр белән очрашты. Мәчет монда 2007 елдан бирле эшли. Мөфти иректән мәхрүм итү урыннарында намазны берләштереп уку, хәләл туклану белән бәйле сорауларга җавап бирде. Камил хәзрәт хәнәфи мәзһәбе буенча гыйбадәт кылырга чакырды: ураза тоту, намаз уку буенча мәсьәләләрне тәфсилләп аңлатты. Бу мәчеткә даими рәвештә 40 лап кеше йөри, җомгалар укыла, Ислам нигезләре буенча дәресләр, рухи әңгәмәләр үткәрелә. Рамазанда 60 кеше, ураза тотып, тәравих намазлары укый. Ураза гаете һәм Корбан гаетләренә 40–50 кеше җыела.

Мөфти хәзрәт Әлмәттәге 8 нче колониянең «Йосыф» мәчетендә иректән мәхрүм ителгәннәр белән аралашты. Әлеге мәчет биредә 2005 елның ноябреннән бирле эшли. Очрашу сорау-җавап форматында узды. Камил хәзрәт җәзага тартылган мөселманнарга үгет-нәсыйхәтләрен ирештерде һәм дини мәсьәләләргә кагылышлы сорауларга җавап бирде. Бу мәчеткә 15–30 кеше йөри, җомгалар укыла, даими рәвештә Ислам нигезләре буенча дәресләр, рухи әңгәмәләр үткәрелә. Рамазанда 30 кеше, ураза тотып, тәравих намазлары укый. Ураза гаете һәм Корбан гаетләренә 60 лап кеше җыела. Җәзага тартылганнар арасында ел саен Коръән укучылар һәм азан әйтү бәйгеләре уздырыла.

## Балтач мөхтәсибәтендә капиталь төзекләндерүдән соң мәчет ачылды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 10 нчы көнендә (1 ноябрьдә) Балтач районы Бөрбаш авылында капиталь төзекләндерүдән соң тантаналы рәвештә мәчет ачылды. Анда мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашты һәм өйлә намазында имам булып торды.

Төзекләндерү эшләре иганәчеләр ярдәме һәм җирле халык катнашында алып барылган: түбә, тәрәзәләр, ишекләр, баскычлар, җылыту системасы, электр үткәргечләре алыштырылган, идәннәр җылытылган. Мәчет, интернетка тоташтырылып, видеокүзәтү системасы куелган. Намаз залында, уку сыйныфларында һәм тәһарәтханәдә уңайлыклар тудырылган. Кухня һәм 40 кешелек ашханә булдырылган.

## «Мәрҗани» мәчетендә шәкертләр арасында республикакүләм Коръән бәйгесе узды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 14 нче көнендә (5 ноябрьдә) «Мәрҗани» мәчетендә Татарстан мөселман уку йортлары шәкертләре арасында республикакүләм Коръән укучылар бәйгесе узды. Аны Татарстан Диния нәзарәте, Россия Ислам институты, Казан Ислам университеты һәм Госман бине Гаффан исемендәге Коръән хафизларын әзерләү үзәге оештырды.

Бәйгедә катнашкан 12 команда арасында Казан Ислам университеты, Россия Ислам институты, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, Әлмәтнең Ризаэтдин Фәхретдин исемендәге Ислам мәдрәсәсе, Буа мәдрәсәсе, «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә, Яр Чаллының «Ак мәчет» мәдрәсәсе, Урыссу бистәсенең «Фәнис» мәдрәсәсе шәкертләре, Казанның «Госмания» урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары һәм Бөрбаш балалар пансионатында тәрбияләнүчеләр бар иде.

## Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты буенча комитеты Кытай һәм Тайваньдагы сертификацияләү органнары белән килешүләр имзалады

Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты буенча комитеты Кытайдагы «Шаньдун провинциясенең «Хәләл» хезмәте» сертификацияләү органы белән килешү имзалады. Ике як та бер-берсенең сертификатларын тану, хәләл стандартлаштыру һәм сертификацияләү өлкәсендә хезмәттәшлек итү, шулай ук хәләл продукция белән бәйле мәгълүмат алмашу турында килеште. «Шаньдун провинциясенең «Хәләл» сертификацияләү хезмәте» Кытайда Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты буенча комитеты биргән сертификатларны таныган өченче оешма булды.

Үзара тану турында меморандум шулай ук Нәзарәтнең «Хәләл» стандарты буенча комитеты һәм «Тайваньның Хәләл намуслылык үсеше ассоциациясе» сертификацияләү органы арасында имзаланды.

## Казанда Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча халыкара олимпиада узды

12–13 ноябрьдә Россия Ислам институтында Россия мөселман мәгарифе тормышында мөселман уку йортлары студентлары арасында Ислам фәннәре һәм гарәп теле буенча XVIII халыкара олимпиада узды. Бәйгедә Россия, Үзбәкстан, Азәрбайҗан, Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Иран, Һиндстан, Төркия, Малайзия, Индонезия һәм Пакстан студентлары — барлыгы 150 студент катнашты. Россия исеменнән Татарстан, Башкортстан, Дагыстан, Чечня, Ингушетия, Кабарда-Балкария, Карачай-Чиркәс Республикалары һәм Мәскәү шәһәре уку йортлары шәкертләре чыгыш ясады.

Россия Ислам институтыннан Ләйлә Низамова Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның махсус бүләгенә лаек булды.

## Чаллыда Нәзарәт кубогына татарча көрәш һәм кул көрәше буенча XVI Россиякүләм турнир узды

Җөмәдәл-әүвәл аеның 24 нче көнендә (15 ноябрьдә) Яр Чаллы шәһәрендә мөселман яшьләренең Татарстан мөфтияте кубогына татар милли көрәше һәм кул көрәше буенча XVI Россиякүләм турниры үтте.

Чараны Татарстан мөфтияте, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты, Россия һәм Татарстанның Татарча көрәш Федерацияләре һәм Яр Чаллы шәһәре мөхтәсибәте оештырды. Анда Татарстан, Башкортстан, Удмуртия, Чувашия, Самара, Дагыстан, Таҗикстан һәм Азәрбайҗан вәкилләре — барлыгы 103 спортчы катнашты. Татарстан данын Казан, Яр Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Әлмәт, Чистай, Кукмара, Нурлат, Зәй, Буа, Менделеевск, Яңа Чишмә, Саба, Балтач, Балык бистәсе, Мөслим, Арча, Әгерҗе, Лаеш һәм Ютазы районнары мөселманнары яклады.

Кул көрәше һәм милли көрәш буенча беренче урын яулаучылар хаҗга юллама уйнатуда катнашты. Юллама Түбән Камадан Азат Җәләевкә чыкты, ул кул көрәшендә 85 килограммга кадәр авырлык категориясендә җиңү яулады. Татарстан мөфтияте кубогына Яр Чаллы командасы лаек булды.

## Нәзарәт «Каһарманнар елы»на нәтиҗәләр ясады һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларга, актив имамнарга һәм волонтерларга хөрмәт белдерде

Җөмәдәл-әүвәл аеның 28 нче көнендә (19 ноябрьдә) Казанда Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән Каһарманнар елы, Россиядә һәм Татарстандагы Ватанны саклаучылар елы кысаларында алып барылган эшчәнлек нәтиҗәләренә багышланган тантаналы Хисап җыелышы узды. Анда республиканың барлык почмакларыннан махсус хәрби операциядә катнашучылар, имам-мөхтәсибләр, сугышчыларга һәм аларның якыннарына ярдәм күрсәтүдә актив катнашкан имамнар һәм волонтерлар катнашты. Тантана Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды теләктәшлегендә оештырылды.

Кунаклар «Каһарманнарга мөселманнардан» күргәзмәсендә Татарстан мөфтияте һәм мөселманнарның махсус хәрби операциядә катнашучыларга күрсәткән ярдәме белән танышты. Анда куелган экспонатлар мәчет каршындагы 104 волонтерлык пунктында ясалган.

2025 елда махсус хәрби операция алгы сызыгына 55 тән артык гуманитар йөк җибәрелде. Махсус хәрби операция башланганнан бирле, аларның саны 100 дән артып китте. Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе дә МХО зонасына 9 тапкыр гуманитар вазифа белән барып кайтты. 2025 елда озатылган гуманитар йөкнең гомуми бәясе 73 млн сумнан артып китте. Аларны МХО зонасына 35 имам һәм мөфтият хезмәткәре илтеп кайтты. УАЗ (буханка) машинасында 3 күчмә мәчетне җиһазландырып җибәрү дә бик мөһим булды. Моннан тыш, 2025 елда фронтка 6 автомобиль һәм 5 мотоцикл җибәрелде. Ә махсус хәрби операция башланганнан бирле, 15 машина һәм 9 мотоцикл тапшырылды. 2025 елда Татарстан мөфтиятенең тагын бер уникаль тәҗрибәсе булып фронтта блиндаж мәчетләр ачу торды. Диния нәзарәте хәзрәтләре фронтта 5 блиндаж мәчет ясады.

## Нәзарәттә Тәлгать Таҗетдин җитәкчелегендәге делегация булып китте

Җөмәдәл-әүвәл аеның 28 нче көнендә (19 ноябрьдә) Татарстан мөфтиятендә Баш мөфти, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе, шәех әл-Ислам Тәлгать хәзрәт Таҗетдин җитәкчелегендә Уфа делегациясе булып китте. Кунаклар Казанга Тәлгать хәзрәтнең 45 еллык дини эшчәнлегенә багышланган чараларда катнашу өчен килде. Алар арасында Россия төбәкләреннән һәм чит илләрдән традицион диннәр җитәкчеләре, дәүләт хакимияте органнары, белем бирү оешмалары вәкилләре, фән һәм һәм җәмәгать эшлеклеләре бар иде.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин кунакларга мөфтият эшчәнлегенең төп юнәлешләре: Коръәнне өйрәнү, нәшрият өлкәсендәге казанышлары һ. б. турында тәфсилләп сөйләде. Аларның игътибарын Казан белгечләренең шәех Мәэмүн әр-Рави җитәкчелегендә әзерләгән кулъязма Коръән җәлеп итте. Камил хәзрәт

аның Россия мөселманнары өчен әһәмиятен ассызыклап үтте. Ә Рәфикъ хәзрәт Мөхәмmәтшин Татарстанда Ислам үсеше хакында сөйләде, дини мәгариф, мөселман уку йортлары эшчәнлеге һәм Ислам финанслары мәсьәләләренә тукталды.

## Тәлгать Таҗетдин мөфти Камил хәзрәтне Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең «Иман һәм намус» ордены белән бүләкләде

Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе, Баш мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинны «Иман һәм намус» ордены белән бүләкләде. Камил хәзрәт әлеге бүләккә җәмгыятьне рухи-әхлакый яктан торгызу эшендәге зур казанышлары һәм илебезнең борынгы рухи мирасын саклауга, Россиядә халыклар һәм традицион диннәр тарафдарлары арасында тынычлык һәм татулыкны ныгытуга зур өлеш керткән өчен лаек булды.

## Мөфти Камил хәзрәт Мәскәүдә динара татулыкны ныгыту буенча Татарстан һәм нәзарәт тәҗрибәсе турында сөйләде

Җөмәдәл-ахыр аеның 6 нчы көнендә (26 ноябрь) Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм аның урынбасары, РИИ һәм КИУ ректоры, Ислам мәгарифе советы директоры Рәфыйкъ хәзрәт Мөхәммәтшин Мәскәүдә милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр проблемалары буенча «Мәдәниятара һәм этноконфессиональ медиакоммуникацияләр» халыкара дәрәҗәдәге түгәрәк өстәлдә катнашты. Чараны Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе (Дәүләт хезмәте һәм идарә институты, журналистика факультеты) һәм Ислам мәдәнияте, фәне һәм мәгарифенә ярдәм фонды оештырды.

Мөфтият хәзрәтләре түгәрәк өстәл эшендә экспертлар буларак катнашты. Мөфти Диния нәзарәте һәм Татарстанның динара татулыкны ныгыту чараларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсе турында сөйләде. Ул моңа мисал итеп республика мөфтияте һәм митрополиясенең махсус хәрби операция зонасындагы уртак гуманитар миссияләре, бергә «Кеше приюты» хәйрия башлангычында катнашуын, Татарстан

Диния нәзарәте «Зәкят» фондының мөселман булмаган аз керемле кешеләр өчен социаль проектлары, ел саен үткәрелә торган «Кубок Дружбы — Дуслык» Бөтенроссия турниры кебек спорт ярышлары, Казан вузларында уртак лекцияләр, Мәскәү һәм бөтен Русь Патриархы Кирилл белән очрашулар, Митрополитның Республика ифтарында һәм мөфтинең Раштуа укуларында катнашуы һ.б. чараларны китерде.

Моннан тыш, мөфти республикада мәгълүмати сәясәт мәсьәләсенә дә тукталды. Ул Татарстан массакүләм мәгълүмат чараларының Ислам һәм православие турындагы мәгълүмати сәбәпләргә һәм мөселман һәм православие дин әһелләренең эксперт буларак төрле темага фикер белдерүенә тигез мөнәсәбәте белән бәйле тәҗрибәне федераль дәрәҗәдә таратырга чакырды.

## Казанда яшь мөселманнар өчен «Яшь кияү» курсының икенче агымы тәмамланды

Җөмәдәл-ахыр аеның 6 нчы көнендә (26 ноябрь) Казанда яшь егетләргә шәригать буенча ныклы гаилә корырга ярдәм итә торган «Яшь кияү» курсының икенчесе тәмамланды. Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең 1500 еллыгына багышланган курслар бу юлы 50 яшь егетне җәлеп итте.

## «Зәкят» фонды МХО сугышчылары әниләрен, хәләл җефетләрен һәм балаларын Әниләр көне белән котлады

Җөмәдәл-ахыр аеның 8 нче көнендә (28 ноябрь) нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фондында Әниләр көненә багышланган чара узды. Бер өстәл артына МХОда хезмәт итүче һәм һәлак булган сугышчыларның әниләре, хәләл җефетләре һәм балалары — барлыгы 25 кеше җыелды.

Алар кипкән җиләк-җимешләрдән тәмле кәнфитләр ясадылар, Казан Башкарма комитетының социаль сәясәт идарәсе башлыгы Ирина Смирнова белән очрашып, махсус хәрби операциядәге сугышчыларның гаиләләренә кагылышлы мөһим проблемалар турында фикер алыштылар. Кичә азагында хатын-кызларга чәчәкләр бүләк иттеләр, азык-төлек җыелмалары, ә балаларга татлы күчтәнәчләр өләштеләр.

## Мөфти Оман дәүләтенең Дин эшләре һәм вакфлар министры белән очрашты

Җөмәдәл-ахыр аеның 9 нчы көнендә (29 ноябрьдә), Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның «Мәрҗани» мәчетендә Оман дәүләтенең Дин эшләре һәм вакфлар министры шәех Мөхәммәд бине Сәид әл-Мамари белән очрашты. Очрашуда Татарстан Рәисе ярдәмчесе, «Россия — Ислам дөньясы» стратегик караш төркеме рәисе урынбасары Марат Гатин, РФ мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары, мөфти Рушан хәзрәт Аббясов һ.б. катнашты.

Камил хәзрәт кунакларга Диния нәзарәте проектлары турында сөйләде: мөфтиятнең Коръәнне өйрәнү эшчәнлегенә аерым игътибар бирде, кулъязма Коръәнне тәкъдим итте. Кунаклар Оманда Коръән белеме үсеше һәм традицияләре турында сөйләде. Мөфти һәм Министр бу өлкәдәге багланышларга һәм ике яклы элемтәләрне ныгытуга әзер булуын белдерде.

## «Ислам. Беренче адымнар»ның 16 нчысы тәмамланды: 20–85 яшьтәге 150 кеше намазга басты

Җөмәдәл-ахыр аеның 9 нчы көнендә (29 ноябрьдә) «Ислам. Беренче адымнар» проектының 16 нчы агымы төгәлләнде: кыска вакытлы курсларда укучылар намаз уку тәртипләрен һәм Ислам нигезләрен өйрәнде. Аларны 20 яшьтән алып 85 яшькә кадәрге 150 кеше тәмамлады.

«Ислам. Беренче адымнар» проекты — Ислам дине кушканча яшәргә теләүче, әмма 3 ел дәвамында мәчет каршындагы курсларга йөрергә мөмкинлеге булмаган кешеләр өчен махсус оештырыла. Ул Татарстан мөфтияте тарафыннан 2018 елда тормышка ашырыла башлады. Уналты сезон дәвамында әлеге курсларда 1750 гә якын кеше белем алды һәм намазга басты.

## «Мәрҗани» мәчетендә Оман дәүләтенең рухи һәм мәдәни мирасы турында Халыкара күргәзмә узды

Җөмәдәл-ахыр аеның 9–10 нчы көннәрдә (29–30 ноябрь) Казан шәһәренең «Мәрҗани» мәчетендә Оман дәүләтенең бай рухи һәм мәдәни мирасына багышланган «Гомумкешелек кыйммәтләре хакына: Оманда үзара аңлашу, татулык һәм тынычлык традицияләре» Халыкара күргәзмәсе эшләде.

Әлеге чара Казанның мәдәни тормышына истәлекле вакыйга булып кереп калды һәм әлеге илнең тарихы, мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән танышырга мөмкинлек бирде. Күргәзмәне карарга килүчеләр Оман дәүләте тарихы, аның дөнья мәдәниятенә керткән өлеше, дини тормыш үзенчәлекләре һәм архитектурадагы традицияләре хакында белде.

## Лениногорск мөхтәсибәтендә мөселман яшьләре арасында өстәл теннисы буенча ярышлар узды

Лениногорск шәһәренең «Татнефть-Кайгырту» спорт комплексында мөселман яшьләре арасында өстәл теннисы буенча ярышлар узачак. Турнирны нәзарәтнең Лениногорск мөхтәсибәте Лениногорск шәһәре хакимияте һәм «Татнефть-Кайгырту» спорт комплексы белән берлектә оештырды.

Ярышлар мөселманнар арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, спортны популярлаштыру, өстәл теннисы буенча иң көчле уенчыларны ачыклау максатыннан үткәрелде. Анда республиканың төрле районнарыннан 11 команда катнашты: беренчелеккә Азнакай районы мөхтәсибәте чыкты.

## Казанда Әниләр көне уңаеннан «Җәннәт әниләрнең аяк астында» чарасы үтте

Җөмәдәл-ахыр аеның 10 нчы көнендә (30 ноябрьдә) Казанда Әниләр көненә багышланган «Җәннәт әниләрнең аяк астында» чарасы үтте. Аны Татарстан мөфтиятенең хатын-кызлар белән эшләү бүлеге Татарстан Мөслимәләр берлеге Эшлекле хатын-кызлар шурасы теләктәшлегендә оештырды. Мәҗлескә бөтен рес-

публикадан 250 абыстай, остабикә һәм мөгаллимә җыелды. Кунаклар арасында уллары махсус хәрби операциядә хезмәт иткән аналар, язмыш сынавына дучар булган гаиләләр дә бар иде. Аларны мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменнән Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев сәламләде, вәгазь сөйләде һәм дога кылды. Күпбалалы гаиләләргә һәм солдат аналарына Татарстан мөфтиятеннән — Коръәннәр, ә Эшлекле хатын-кызлар шурасыннан чәчәкләр бүләк ителде.

## Татарстанда 1201 тоннадан артык гошер садакасы җыелды һәм мохтаҗларга өләшенде

Татарстан Республикасы Диния Нәзарәте башлангычы белән тормышка ашырылган гошер садакасын җыю һәм халыкның мохтаҗ катламнарын азык-төлек белән тәэмин итү кампаниясе тәмамланды. 2025 ел нәтиҗәләре буенча, әлеге акция кысаларында Татарстан Республикасында барлыгы 1201,5 тонна гошер садакасы җыелып, мохтаҗларга таратылды. Азык-төлекне зур күләмдә җыючы булып Буа (100 тонна), Балык Бистәсе (82 тонна), Әлки (76 тонна), Чирмешән (75 тонна) һәм Балтач (68,6 тонна) мөхтәсибәтләре тора. Шулай ук Чүпрәле (57,8 тонна), Мамадыш (55 тонна) һәм Әтнә (50 тонна) районнары зур активлык күрсәтте.

Татарстан мөселманнары, мохтаҗларга ярдәм итү йөзеннән, республика мәчетләренә бәрәңге, чөгендер, кәбестә, кишер, кабак, суган, ташкабак, алма, слива, шулай ук җиләк-җимеш кайнатмалары, тозлаган кыяр-помидорлар, бал алып килде. Кампания кысаларында җыелган азык-төлек хәйрия оешмаларына (Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды, «Ярдәм-Помощь» гомуммилли хәйрия фонды тернәкләндерү үзәге, «Приют человека» проекты), социаль учреждениеләргә (районнардагы картлар йортлары, балалар йортлары, интернат-мәктәпләр, мөхтәсибәтләр һәм мәчетләр каршындагы социаль ашханәләр), мөселман уку йортларына (мәдрәсәләр, мәктәпләр һәм балалар бакчалары, мәгърифәтчелек үзәкләре, Коръән хафизлар әзерләү үзәге һ. б.), шулай ук турыдан-туры мохтаҗ гаиләләргә җибәрелде. ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең «Зәкят» хәйрия фонды Казанның 750 аз керемле гаиләсен 22 тонна азык-төлек белән тәэмин итте.

## Мөфти Камил хәзрәт Катар делегациясе белән очрашты

Җөмәдәл-ахыр аеның 12 нче көнендә (2 нче декабрь) Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Катар Дәүләтенең Вакфлар эшләре һәм Ислам мәсьәләләре министрлыгы делегациясе белән очрашты. Кунаклар Казанга KazanForum-2026 уздыру мәйданчыгы белән танышу һәм Катарның форумда катнашу мәсьәләсе буенча фикерләшергә килде.

Камил хәзрәт очрашуда Диния нәзарәте һәм аның карамагындагы оешмалар эшчәнлеге, төп проектлар һәм өстенлекле юнәлешләр, шулай ук Татарстан мөселманнары тормышы турында җентекләп сөйләде. Катар Дәүләтенең Вакфлар эшләре һәм Ислам мәсьәләләре министрлыгы белән тыгыз һәм нәтиҗәле хезмәттәшлек мәсьәләсенә аерым игътибар бирелде. Мөфти кунакларның дәүләт һәм диннәр арасындагы бәйләнешләр, Татарстанда Ислам мәгарифе системасы, мәдрәсәдә белем бирү алымнары, дәгъват һәм башка темаларга кагылышлы сорауларына җавап бирде.

Кунаклар, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дә булып, шәкертләргә үгет-нәсыйхәтләр бирде һәм уку-укыту барышы белән танышты.

Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте

# ШУРА

## ДИНИ АЛЬМАНАХ

1908 елдан бирле нәшер ителә

2007952696051